ГӨЛФИЯ ГАЙНУЛЛИНА

# 1940-1980 ЕЛЛАР ТАТАР ПРОЗАСЫНДА МИЛЛИ ЯШӘЕШ НИГЕЗЛӘРЕН БАРЛАУ

КАЗАН, “ИХЛАС”, 2012

**Фәнни мөхәррир**
Филол. фән. докторы, профессор Д.Ф.Заһидуллина

Гайнуллина Г.Р. 1940-1980 еллар татар прозасында милли яшәеш нигезләрен барлау. – Казан: Ихлас. – 100 б.

Бу китап 1940-1980 елларда милли яшәеш нигезләрен тәкъдим иткән проза әсәрләрен шәрехләү-бәяләүгә багышлана. Хезмәттә милли нигезләргә кайту чоры әдәбиятын яңа күзлектән анализлау аша бу дәвер прозасындагы яңалыкларны билгеләү, бәяләү омтылышы ясала. Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев прозасының энҗеләрен яңадан укып, сюжет-композиция өлкәсендәге эзләнүләр, бу дәвер татар прозасындагы стиль тенденцияләре хәрәкәтен күзәтү игътибарга алына.

Китап студентлар һәм әдәбият белеме белән шөгыльләнүче фән кешеләренә, укытучылар һәм мәктәп укучыларына, гомумән, әдәбият сөючеләргә тәкъдим ителә.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз 4

Әмирхан Еникинең Бөек Ватан сугышы чоры хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсе 6

XX гасырның 60 нчы еллар тәнкыйди юнәлешле татар прозасында милли яшәеш фәлсәфәсе 24

XX гасырның 70- 80 нче еллар татар прозасында милли яшәеш фәлсәфәсен тәкъдим иткән лирик-эмоциональ юнәлеш 49

XX гасырның 70-80 нче еллар татар прозасында милли яшәеш фәлсәфәсен билгеләгән буыннар өчен җаваплы булу турындагы хакыйкать белдерелеше 65

## Кереш сүз

Мәгълүм булганча, 1960-80 еллар – татар әдәбиятының милли нигезләргә кайту чоры – татар прозасында яңа эзләнүләр, яңа сукмаклар, психологизмның, тәнкыйди башлангычның көчәюе, лирик-эмоциональ башлангыч алга чыгуы, публицистик башлангычның урын алуы кебек сыйфатларның алга алынуы, стиль тенденцияләренең, сәнгати алымнарның байлыгы белән билгеләнә. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина билгеләп үткәнчә, XX гасырның икенче яртысы, бигрәк тә 60 нчы еллардан соңгы чорларга бәянең әле катгый яңгыраганы юк. XX гасырның икенче яртысы прозасы – Ә.Еникиләр, А.Гыйләҗевлар, М.Мәһдиевләр чоры бүгенге әдәбият гыйлемендә үзгә якын килеп өйрәнүне таләп итә.

“Әгәр язучы татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән – ул инде татар әдәбияты түгел”, – дип яза “әдәбиятның нигезендә миллилек ята” дип кабатлаган әдипләрнең берсе Аяз Гыйләҗев.

Әмирхан Еники – XX гасыр башы татар фәлсәфи прозасында милләт мәсьәләсенә игътибар иткән күпмәгънәле, күпкатламлы текстлардагы алым-принципларны сугыш чоры прозасында тергезеп, дәвам иттерүче. Аның яшәеш фәлсәфәсен тәкъдим иткән хикәяләрендә символлар ярдәмендә үлем, өметләр өзелү, яшәүнең мәгънәсен табуга килү хакында сүз бара.

Прозада бер тармакның соцреализм кысаларын үтеп, классик, традицион реализмга якынаюы, реализм юнәлешен тәнкыйди башлангыч белән баетуы күзәтелә. Тәнкыйди катлам милли эчтәлекле мәсьәләләргә – рухи бәйләнешләр өзелү, традиция-гадәтләрнең, телнең югала баруы, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе, туган җир, туган нигез кадеренең кимүе, татар авылларының юкка чыгуы кебек проблемаларга игътибарын юнәлтә, дип билгели галимә Д.Заһидуллина. 80 нче еллар татар прозасында тәнкыйди башлангычның милли проблемаларны калкыту юлыннан китүе төп тенденцияләрнең берсе булып оеша. Яшәп килүче идеология шартларында системаның нигезен билгеләгән якларны ачуны күздә тоткан тәнкыйди юнәлеш 1955-1957 елларда Ә.Еникинең “Саз чәчәге”, 1962 елда Ә.Еникинең “Рәшә”, А.Гыйләҗевның “Өч аршын җир”

повестьлары язылу белән калыплаша. XX гасырның 60 нчы елларындагы әлеге юнәлеш гасыр ахыры прозасында фәлсәфи катламлы текстларның катлаулы формаларын әзерли. З.Хәким, М.Кәбиров прозасында фәлсәфи шартлылык әлеге дәвердә тәкъдим ителгән милли яшәеш фәлсәфәсенең тәнкыйди башлангычына тоташа.

XX гасырның 70-80 нче еллар татар прозасында калыплашкан икенче юнәлешне милли рухның асылын, аның буыннардан килгән эчтәлеген сөйләп биргән әсәрләр тәшкил итә. Ә.Еникинең "Әйтелмәгән васыять", "Гөләндәм туташ хатирәсе", А.Гыйләҗевның "Җомга көн, кич белән..." М.Мәһдиевнең "Торналар төшкән җирдә" әсәрләре татар кешесенә васыять сүзе кебек яңгыраган текстлар. Һәр татар кешесенә бәхетле, хөр, иркен яңа тормыш кору өчен буыннар хәтерен – аң төпкелендә тупланган горур-сабыр яшәү тәртибен табу һәм саклау зарур, диләр А.Гыйләҗев, Ә.Еники, М.Мәһдиев буыннар хәтерен үзендә туплаган Бибинур, Акъәби, татар авылы кешеләре образлары аша.

Милли яшәеш фәлсәфәсенең Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиевләр тәкъдим иткән укылышы яңа гасыр татар прозасында кабатлана, көчәйтелә. Бүгенге прозада бу әсәрләр югарылыгында кабул ителгән, аңланган, хәтердә уелган текстлар булу турында әйтү иртәрәк булыр. Әлеге юнәлеш татарда милли үзаң үсешенең яңа дәверен көтә. Әдәби тәнкыйтьтә, әдәбият теориясендә алгарыш, шулай ук хәзерге прозадагы интеллектуаль тенденция бу юнәлешнең дәвамы булачагына ышаныч тудыра.

## Әмирхан Еникинең Бөек Ватан сугышы чоры хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсе

Бөек Ватан сугышы елларында (1941-1945) татар прозасы нигездә ике төп юнәлештә үсә.

***Беренче*** – әйдәп баручы ***юнәлеш***не 1917 елдан соң сәяси тормыштагы үзгәрешләр һәм иҗтимагый вазифаларның эчтәлеге яңаруы нәтиҗәсендә яшәп килүче идеология шартлары әзерли. Билгеле булганча, әлеге вәзгыять кешене иҗтимагый тормышта һәм көнкүрештә тасвирлауны алга ала, үзара дуслык һәм ышанычка корылган мөнәсәбәтләр тәрбияләү бурычын куя. XX йөз башы татар әдәбиятындагы халык азатлыгы, милли үсеш идеяләре, шулай ук мәхәббәт, әхлак төшенчәләре урынына пролетариат мәнфәгатьләренә хезмәт итәрлек, социалистик җәмгыять үсешендә таяныч булырлык идеяләр алга сугарылуы мәгълүм. Пролетариат сыйныфының “социологик” идеалы калка, Й.Нигъмәтуллина әлеге күренешне мәдәниятнең семантик-синтаксик төренең өстенлек алуы белән нигезли.

Әдәбият галиме Д. Заһидуллина яңа концепциянең нигезенә революцион сәнгатьтә революциянең үзе чагылу, чынбарлык материалы сәнгать әсәренә күчерелгәндә, коммунизм идеалы яктылыгында бәяләп күчерелү; әсәрнең тормышка яңадан актив тәэсир ясавы – хезмәт ияләрен коммунизм идеяләре рухында тәрбияләүгә булышу принциплары салына, дип билгели. XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләрдәге рухи башлангыч, мәхәббәт фәлсәфәсе марксистик теориядә кире кагыла, яшәү көчен символлаштырып, яшәешнең нигезендә яткан субъективлык, эчке дөнья белән бәйләнгән мәхәббәткә алмашка позитивистик төшенчәләр килә. Инкыйлабтан соң башланган “тигезләү” нәтиҗәсендә җәмгыять үсешенә “массалар сәясәте” үтеп керә, фәлсәфи фикердә бу күренеш “массалар күтәрелеше” исемен ала. З.Фрейд күзаллаган иҗтимагый төзелеш – хакимият вәкилләрен күккә чөйгән, калганнарны үз-үзләрен бәяли алмаучы, агымга ияреп яшәүче, тотрыксыз халәттә яшәүче кебек бәяләгән “юлбашчы – элита – масса” структурасы тормышка ашырыла. Әдәбиятта “толпа” “масса кешесе” төркеменә кертелә. Шул рәвешле, XX гасыр башындагы идеалларны

социалистик җәмгыять төзүче бөеклек, гаделлек, олылык символы буларак күтәрелгән Ленин, Сталин образлары алыштыра.

Агымдагы шартларда татар әдәбиятында яңа тормышны социалистик идеяләргә нигезләнеп төзү мәсьәләсен үзәккә куйган әсәрләр языла – соцреализм агымы формалаша (1917–1932). Татар әдәбиятында ул – коммунизмның җиңәчәгенә чиксез ышаныч, оптимизм белән сугарылган әдәби агым. Кешедәге героизм, корбанчылык сыйфатларын данлап, яңа тормыш хакына үзен корбан итүчеләргә сокланып мәйданга килсә дә, 1932 елдан соң соцреализм агымы җәмгыять үсешенең бер юлы булган марксистик-ленинчыл концепцияне бердәнбер хакыйкать итеп исбатлуга кадәр үсә. 1934 елны рәсми рәвештә расланган соцреалим иҗат агымы 1940-50 еллар әдәбиятының бер юнәлеше булып тора. Бу юнәлештә язылган эпик әсәрләр арасында сәнгатьчәлек җәһәтеннән камил хикәяләр арасында М.Әмирнең «Сыерчык» нәсерен, И.Газинең «Малай белән эт», «Ана», Ф.Хөснинең «Түбән оч», «Солдат хикәясе»н, А.Шамовның «Дустым кабере янында» һ.б. ларны билгеләп үтәргә мөмкин.

***Икенче юнәлеш*** XX гасыр башы татар фәлсәфи прозасында милләт мәсьәләсенә игътибар иткән күпмәгънәле, күпкатламлы текстларның сугыш чорында әдәби иҗат эшенә аңлы рәвештә алынган яшь язучыларга йогынтысы нәтиҗәсендә калыплаша. Бу юнәлеш Әмирхан Еники (1909-2000) исеме белән бәйле. Әдип иҗатында “гомумкешелек – милләт – шәхес” чылбыры алга куела. Яшәеш фәлсәфәсен күрсәтүче хикәяләрдә үлем, өметләр өзелү, яшәүнең мәгънәсен җую хакында сүз барганда автор бер төркем символларга мөрәҗәгать итә. Ә.Еникинең сугыш чорында язылган хикәяләреннән “Бала” (1941), “Ана һәм кыз” (1942), “Бер генә сәгатькә” (1944) хикәяләрендә, “Мәк чәчәге” (1944) нәсерендә шартлы сурәт, хикәяләүче сөйләме “автор тавышын” ишеттерү вазифасын башкара. Психологик тасвирга төреп бирелгән яшәеш фәлсәфәсе милли төсмер ала. Автор укучының яшәү/үлем каршылыгы белән бәйле эчке кичерешләрен буыннардан килгән милли яшәеш фәлсәфәсе белән нигезли.

***Ә.Еникинең “Бала” хикәясе (1941)*** сугыш чоры прозасының иң матур үрнәкләреннән санала. Текст “сөекле кызым Резедага багышлыйм” дигән эпиграф белән башланып китә. Бу өлеш әсәргә куелган исемне, әсәрдәге кыз персонажны автор мөнәсәбәте белән бәйләп килә.

Хикәяләүче укучыны “лейтенант Иванов ротасы” белән сынаулар аша үтү юлы кебек шәрехләнгән урман юлына алып керә. Биредә хикәяләүче исеменнән авторның укучыны “зур саклык белән алгы позициягә” алып бару омтылышы әйтелә. Юл хронотобы урман пространствосы белән янәшә бирелү сынау юлының катлаулы булуын искәртә. М.Бахтин аңлатуына караганда, геройның билгеле бер вакыттагы хәрәкәтен тәэмин итүче шәхси юлы булырга тиеш: “Юл ат, арба, машина эзләре белән тулы. Җәяүлеләр дә күп үткән булса кирәк: дымлы комда солдат итекләреннән, хатын-кыз ботинкаларыннан калган эзләр дә ярылып ята”. Геройның хәрәкәте күпмедер дәрәҗәдә алдан билгеләнгән: юл буш түгел, димәк, шәхси дип кабул ителгән сынау юлы кабатланган, аны үтү өчен канун-кагыйдәләр дә табылган. Шуңа күрә юл хронотобы геройның шәхси юлы булудан өстен: “Бу юл – бүгенге мәхшәрнең бердәнбер телсез шаһиты. Ике туганның бер үк эзгә басканын бары ул гына белә”. Укучы да, хикәяләүче белән беррәттән, шул юлга – геройны гөнаһсыз сабый белән очраштырган эзгә баса.

Биредә гөнаһсыз сабый образына салынган эчтәлекне билгеләп үтү зарур. Әсәрнең исеменә, эпиграфка – көчле позициягә чыгарылган бала геройны сынау алдында калдырган персонаж. Теләсә кемне уйланырга мәҗбүр итә алган бердәнбер хакыйкать белдерелеше булган бала белән очрашу кешенең үз намусы, вөҗданы белән очрашу, бер эзгә басу эчтәлеген ала. Автор кешедәге шәхси юлның башы – үз намусыңа, гармониягә – күңел тынычлыгына омтылуга ихтыяҗ туу, ди. Хикәяләүче укучыга тулы дип тасвирлаган юл әлегә “мәкерле тыныч, буш” икән. Димәк, буыннар сызган юлның кайтавазы кеше күңелендә яңгыраш тапканчы шәхси тормыш юлы буш һәм яшәү тәртипләре турындагы мирасны кабул иткәнче ул мәкерле тыныч, ягъни бер сынауны үткәндә кылган ялгыш икенче – күпкә катлаулырак сынауны әзерли.

Урман пространствосын тасвирлау – сынау юлының эчтәлеген ачу кебек укыла. Сынау юлы – “урман, үз-үзен тыңлагандай, хәрәкәтсез һәм тып-тын”. Бу – кешенең уйлану, олы гамь алдында калу мизгеле. Үз-үзен – намусын тыңларга чакырылган укучы әлеге хәрәкәтсезлек, ягъни гамьсезлек халәтенең сурәтен укый. Хикәяләүче укучыга бу халәтне тынлык – нәрсәдер көтү мизгеле дип тасвирлый: “Кояш чыккан вакыт. Мәһабәт төз наратларның очлары җылы нурга манчылып, рәхәт бер талгынлыкка бирелгәндәй, шылт та итмичә, тик

кенә торалар...” Илаһи мәхәббәт символы кебек кабул ителгән нур образын кояш чыккан вакыт – таң вакыты образы белән янәшә куеп, хикәяләүче укучыга кеше күңелендә уяну, үзгәрешләр булачагы, бу халәтне мәхәббәт хисе билгеләргә тиешлеген искәртә. Укучыны шул яңа халәтне тоярга әзерләү дәвам итә: “Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле, җилфердәшәләр...” Көмеш яфракларның сөенә-сөенә уйнавы укучыны тынлык артында көтелгән илаһи серле рәхәтлек барлыгына ышандыра. Әлегә “ачык урыннарда, җиргә таба сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята”, “тән ниндидер бер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән гамьсез бер рәхәтлек тоя...” Гамьсез бер рәхәтлек – хәрәкәтсезлекнең эчтәлеге, ягъни кеше күңелендә әлегә гамь булып оешмаган, аның гамәлләренең башлангычы булып тормаган, ниһаять, кешенең күңел төпкеленә яшерелгән, ләкин әлегә табылмаган үз асылы.

Шул рәвешле, укучыны төп геройның үзе белән таныштырганчы, автор иң элек аның эчке халәтен сөйли. Укучы геройның әлеге халәтен үзе аша үткәрә, хәтта уйлана ук башлый. Автор хикәяләүчесе исеменнән уй-гамәлләрнең һәркайсы алдагы гамәл белән сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә икәнлеген гел искәртеп тора бит: “...эзләр, яшькелт-кара тасмадай, артта сузылып кала”.

Укучы Зариф янына хәзер инде “ротаның арткы рәтенә” урнаштырыла. Зариф йөзендәге “тыныч ваемсызлыкны” укучы гамьсезлек чагылышы дип бәяли, шуны төгәлләштерү өчен бирелгән портрет детальләренә, хәрәкәт аталышына салынган эчтәлекне укый: “...кызылармеец Зариф, алдан баручы иптәшләренең тигез генә тирбәлгән аркаларына карап, салмак кына атлап бара. ... Бары тик кысыла төшкән күзләре генә аның эчке уйларына йотылып баруын күрсәтә”. Зариф уйларының эчтәлеген сөйләр алдыннан хикәяләүче гамьсезлекнең җимергеч олы көч икәнлеген искәртә: “Бу иртәнең җылы тынлыгы, урманның өлкән гамьсезлеге каядыр якында гына мәрхәмәтсез сугыш, кан һәм үлем барлыгын онытып торырга мәҗбүр итә, гүя сөттәй ак томан ул дәһшәтләрне үз эченә яшерә һәм кешедән ераклаштыра. Бу тыныч һәм сөенечле хисләр белән сулый торган табигатьтә кеше ничектер, үзе дә теләмәстән, алданучан була”. Авторның фикер юнәлеше гамьсезлекне яшәеш юлы дип кабул иткәннәргә борыла. Гамьсез-вафасыз яшәү, башкалар артыннан салмак кына атлап бару – күпләрнең тормыш-юлы, яшәеш кагыйдәсе. Алар

аны бәхетле булу юлы дип саный, чөнки башкалар дөньясында үзеңне шулай табу уңайлы, җайлы,  кемнеңдер чынбарлыгына үтеп кергән башка сыймас хәсрәтләр борчымый, бүгенгесе һәм үзеңнеке кыйммәт. Гамьсезлекне яшәеш юлы иткәннәр алданучан, ди автор, биредә үлем төшенчәсе килеп керү дә очраклы түгел. Бу урында яшәү-үлем проблемасы куела,  хикәя шул проблеманы яктыртуга корыла.

Хикәяләүче тасвирлаган  бәхетле-тыныч тормыш сурәте – Зариф идеал иткән чынбарлык – кеше яшәешенең иң гади, әмма һәркайчан сагынып телəгән мәгънәсе икәнлеге белән укучы берсүзсез килешә: “Чыннан да, Зариф кая барганын онытмаса да, хәзерге минутта иң гади, шул ук вакытта күңеленең һәркайчан сагынып теләгән уйларына йотылган иде: менә киң кырлары, зәңгәр урманнары белән гел хыялында яшәгән туган иле, һәр читән казыгына кадәр таныш авылы, сәке йөзлегендәге киртләчләренә кадәр күзе алдыннан китми торган өе, исенә төшергән саен тавышы ишетелгәндәй тоелган хатыны, ниндидер сөйкемле гадәтләре белән йөрәгендә сакланган баласы...”. Яшәүне һәм үлемне мәгънәле итүче бердәнбер хакыйкать ул – туган ил, торган җир, сөйгән яр, бала. Әмирхан Еники иҗатын иңләгән  әлеге тема бу хикәядә шул хакыйкатьне аңлауга килү  проблемасы төсендә яңгыраш ала.

Автор биредә пространство үзгәртелү аша кеше күңелендә әзерләнгән үзгәреш турында сөйли. Туган ил сурәте – күңелнең иркен-рәхәт чагы тасвиры (зәңгәр урманлы, киң кырлы), авыл сурәте – таныш, димәк кадерле, үз, якын дигәнне белдереп килә. Урам күпере, басу юлы, иген кыры әлеге чынбарлыктан китү, башка – таныш булмаган чынбарлыкка күчү сурәте. Ләкин уйлары Зарифны үзе якын иткән чынбарлыкка тарта: “Тулы, тыгыз башакларын күтәрә алмыйча җиргә иелгән бодайлар... Быел нинди мул уңыш иде!... Хәзер инде көн-төн ашлык сугалардыр”.

Ә.Еники ике чынбарлык чиген төгәл билгели. Әлеге араны кеше үзенә таныш чынбарлыктагы кануннарга буйсынып үтә: “Менә Зарифның колагына кайдадыр якында гына ашлык суккыч машинаның гөрләве, эре көлтәләрне тартып алып йоткан чакта үкереп куюы ишетелгән кебек булды”. Командирның “Һава!” дип кычкыруы аны һич көтмәгәндә үзгә чынбарлыкны кабул итәргә мәҗбүр итә. Үзе өчен чит булган әлеге чынбарлыкта Зариф югалып кала, лейтенантның командасын ишетми, бары иптәшләре артыннан урыныннан кузгала. Димәк, Зарифта әлегә чит чынбарлыкта да үзе булып калырлык рухи

ныклык җитешмиме? Юк, ләкин таныш булмаган яңа дөнья кешедән күпмедер күләмдә буйсынуны таләп итә. Рухи ныклык, ышанычлы әхлакый нигез булу чит чынбарлыкта да үзеңне табу мөмкинлеген булдыра.

Вакыйгаларда Зариф идеал иткән чынбарлык хакыйкате – мәхәббәт  раслана. Төенләнештә укучы Зарифның кыз образына салынган илаһи матурлык белән очрашу мизгелен укый. Кызның ялгызлыгы, ярдәмгә мохтаҗ булуының укучыда кызгану хисе уятуы табигый.  Вакыйгаларда кыз түгел, яшәүне мәгънәле итүче бердәнбер хакыйкать туган ил, торган җир, сөйгән яр, бала, дип ышанган Зариф сынала. Димәк, ул тыныч-тигез тормышның нигезен белә, ләкин шул тормышны саклый-яклый белү – сынаулар килгәндә намусны алга кую ул.  Автор укучысына сүз һәм гамәл берлеге турында – намусның яшәү кагыйдәсе булырга тиешлеге хакында сөйләргә алына.  Шул рәвешле, бала-намус Зарифны яшәү юлына алып чыгачак, аның рухын какшамас итәчәк.

Укучы Зарифның юлда бала  белән очрашуын җентекләп күзәтә. “Өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, бер адым да атларга өлгермәгән килеш ихтыярсыз тукталган” Зариф кызның ялгыз булуына бик гаҗәпләнә. Укучы кызның портретына салынган эчтәлекне укый – “озак елаудан күз төпләре шешенгән, кечкенә кулына берничә бөртек каен җиләге учлаган, шуны кабарга хәзерләнгән җиреннән туктап, зур соры күзләре белән Зарифка исе китеп карап торучы бала” ярдәмгә мохтаҗ. Кызны тагын да матуррак сурәтләү мөмкин түгелдер: “аның өстендә зәңгәр сукнодан җәйге пальто, башында фетрдан тегелгән кара шапочка, аны кызыл тасма белән ияк астыннан китереп бәйләгән; аякларында озын сары ботинкалар һәм бер аягында галошы бар, икенчесен төшереп калдырган, ахрысы”. Ләкин авторның уе кызның матурлыгы аша укучыда хис тәрбияләүгә юнәлгән. Укучы Зарифның кызның камиллеге аша бирелгән матурлыкны һичшиксез коткаруын көтә. Ләкин герой ике юл чатында: “...аңарда кузгалган беренче теләк баланы тизрәк күтәреп аласы килү теләге булды. Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды.” Герой бурыч үтәү ягына борыла – буйсына: “беренче хәрәкәте аның ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылу булды”.  Ләкин хәрәкәт булмый кала: “...ул, бер адым да атламастан,  кинәт балага таба кире борылды, ашыгып кына янына барды да җитез генә күтәреп алды”. Дөресрәге,

Зариф әлегә үзе дә абайламыйча, алга юнәлгән кискен хәрәкәт ясый: “Зариф, баланы кысып тоткан килеш, аяк астында аунаган чыбыкларга, агач төпләренә абынмас өчен сикерә-атлый, ашыгып юлга чыкты”. Арткы рәттә салмак кына барган Зариф каршылык тудыручы башка шартларны сикереп үтеп (аяк астында аунаган чыбыклар, агач төпләре детальләре). Укучы Зарифның бу хәрәкәте эчке ярсу омтылыш белән бәйле икәнен сизә. Зариф  башкача булдыра алмаганга, үз җанын тыңлап, шулай эшли. Ләкин “сыңар кулы белән мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлавы”аның күңелендә борчу барлыгын сиздерә.

Баланың Зарифка мөнәсәбәте бирелеше аша укучы гүяки Зарифның эчке тавышы белән сөйләшүен укый. Алдан беркадәр ятсынган бала  (Зарифның битеннән этәреп, аякларын селкеп елавы) – Зарифның беренче хәрәкәтенең – ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылуының кабатланышы.  Алдагы “сөйләшү”дә Зариф баланы, бала Зариф биргән шикәрне күкрәккә кыса. Шул урында Зарифның үз кызы Фәридәгә мәхәббәте әйтелә. Газиз баласын уйлау Зарифта “дулкын булып күтәрелгән  сөенечле бер ярату” хисен көчәйтә, “бәлки ул шул минутта үз баласы белән бу бала арасында аерма таймыйдыр”. Димәк, автор Зарифтагы ярсу омтылышны нигезли. Бу адымга ирне йөрәгендә яшәгән ярату хисе этәргән икән. Мәхәббәтнең эчтәлеге булып торган җаваплылык хисе ирдә үзенә бәйсез рәвештә яши. Бу хисне бернинди шартлар да үзгәртә алмый. Ләкин бу хиснең киеренке шартларда өстенлек алуы кешене үзгәртә. Кеше үзендәге җаваплылык хисен аң төпкеленнән аң өлешенә күчерә, башка гамәлләрен шул хисне аңлы рәвештә алга куеп башкара. Хис торган саен көчәя – кешенең рухы ныгый, мәхәббәткә мөнәсәбәте алышына. Ярату дөньядагы иң олы көч буларак танылa һәм яшәү рәвешенә әверелә. Һәркем алдында торган бурыч әнә шул.

Укучы Зарифның яшәү ягына чыгуын аңлый, күз яшьләре ир күңелендә урнашкан мәхәббәтнең ныклыгын раслап куя: “Әтиең, әниең бармы? – дип сорады Зариф, һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланып китте.”

Зариф белән бала арасындагы алдагы сөйләшүдә укучы  ике туганның бер булып яшәвен күрә (“бала, тарсынмыйча, әүвәл бер кулындагы ике бөртек җиләген капты, соңра икенче кулындагы шикәрен суыра башлады.” Бала теле белән кеше өчен иң кадерле булган кыйммәтләр хакыйкать буларак кабатлана: “Әнием дә бар, әтием дә бар... безнең әле тагын кәҗәбез дә бар. Бәтиләре ап-ак.”

Соңгысы – кәҗә детале гаилә, тормыш бөтенлеген искәртеп килә. Тик тагын бер хакыйкать Зариф өчен әйтелгәндәй укучыга ишеттерелә. Әти кеше – баланың таянычы, горурлыгы, саклаучысы икән (баланың горурланып әтисенең лейтенант икәнлеген әйтүе). Димәк, ярата белү – якыннарың горурланырлык кеше була алу, ди автор.

Ләкин укучы Зариф күңелендә урнашкан, аңланган җаваплылык хисенең әле сыналачагын көтә. Чөнки Зарифны бәхетле иткән ярсу омтылышы аның киләчәк гамәлләренең дә башлангычы булып ныгырга тиеш. Иң мөһиме – Зарифның бу юлдан китмәячәгенә укучы ышанырга, ахыр килеп, бу юлны үз яшәү юлы итеп кабул итәргә тиеш. Артиллерия атышы пространствода шомлы тынлык урнаштыра. Укучыда геройларны борчыган сорау туа: нишләргә? Зариф та бала кебек менә-менә югалып калыр сыман: “Зариф аны үзенә кыса төште, һәм аңа икесенең дә йөрәкләре бергә типкән кебек тоелды.” Укучы хисләрнең киеренкеләнгәнен сизә, Зариф баланы юата алырмы? Иң мөһиме – Зариф моңа үзе ышанмый. (баланы юатканда аңа “үз тавышы баз эченнән килгәндәй тонык, саңгырау булып ишетелә”). Биредә автор укучыдан яратуны җиңә алырлык бердәнбер җимергеч көчне – курку хисен таптыра: “Бала, Зарифка сыена төшеп, бер кулы белән аның муеныннан урап алды. Зариф, белмим баланы юатыр өчен, белмим үзенең эчке бер уеннан: “Без кая барабыз?” – дип сорап куйды”.

“Без кая барабыз?” – хикәяләүче укучыга шулай эндәшә, юл башында гел куелырга тиеш сорау икәнлеген искәртә.

Бу өлештә бала образы тулысынча укыла. Баланың җитди итеп: “Әбиләргә кунакка”, – дип җавап бирүе укучыны елмаерга, шул ук вакытта уйланырга мәҗбүр итә. Юл башында җаваплылык хисе тора икән, бу сораугa җавап әзер, ул катгый, бер һәм үзгәрә алмый торган хакыйкать кебек. Бала бер юлны гына белә, намуслы кеше дә нәкъ шулай. Биредә автор кешенең эчке тавышын җитди яңгырата кебек: “Зариф хәзер чыннан да аптырашта калды. Нишләргә?” . Укучы Зарифны намусы кушканча эшләргә этәргән ярсу омтылышның салкын исәп белән алышынуын, Зарифның курка төшүен сизә: “Дөресен әйткәндә, ул һич туктамастан ротасын куып җитәргә тиеш.” Шул рәвешле, автор кешеләрне исәп-хисап колы иткән хисне атый – курку.

Укучы Зарифны башка юл сайласа, гафу итмәс иде. Әмирхан Еникинең осталыгы да шунда. Ул укучысын герое пространствосында

– аның күңел кичерешләре “тозагында” тота. Зариф әле җаваплылыкны аң өлешендә урнаштырып, яшәү кагыйдәсе итмәгән икән. Югыйсә, аңарда икеләнү булмас иде: “Ләкин кулында сыенып утырган бала аны ике юл чатында калырга мәҗбүр итте. Баланы ут эченә кадәр алып барырга мөмкин түгел. Ул соңгы өмет белән, хәтта чакырып тирә-ягына каранды”. Укучы Зарифның җаваплылык һәм курку хисе белән билгеләнгән ике яшәү юлында калуын укый. Мондый вакытта кеше соңгы өмет белән, чакырып илаһияткә, башкаларга мөрәҗәгать итә. Асылда кеше үз намусына – илаһи башлангычына эндәшә. Бу – кешенең гармониягә омтылышы мизгеле. Башкача, намусның эндәшүе: “Бала, Зарифның нәрсә уйлаганын сизенгән шикелле, зур булып ачылган күзләре белән аңа бик җитди карап тора.” Хәзер инде Зариф, никадәр авыр булса да борылмаячак, чөнки автор укучысына шулай гына тиеш икәнлеген раслады. Зариф илаһи башлангычын таба: “Бу караш Зарифның икеләнүен өзде...”

Станциянең платформасы – Зариф сайлаган юлның башы, тимер юл – аның турылыгы белдерелеше. Ана – кеше өчен намуслылык бизмәне. Әнисен тапкан бала кулыннан төшеп киткән шикәр деталенең мәгънәсе – рухи ныклык – тормыш юлында иң җитди таяныч дигән эчтәлек ачыла. Шул урында Зарифның күңелендә урнашкан какшамас хакыйкать укыла: ул “ана белән баланың кавышу мизгеленә соклану тулы караш кына ташлый алды.” Биредә Зарифның үз күңелендә гармония табу мизгеле тасвирлана. Шул халәттә автор аны чит тоелган дөньяга алып керә (ул мылтыгын иңеннән кулына ала), ул лейтенант белән сөйләшә.

Текстта кабатланган лейтенант образы җаваплылык хисен яшәү кануны иткән бердәнбер образ кебек укыла. Зариф тагын үз юлының дөреслеген тикшерү алдында кала. Тик бу юлы аңа кешедән өстен торган хакыйкать үзе эндәшә: “Сез зур изгелек эшләгәнсез”. Димәк, зур изгелекләр кыла алу – җаваплы була белү кешене гел алгы позициядә тота. Шуңа күрә автор әйткән, бала тарафыннан кабатланган яшәүне һәм үлемне мәгънәле итүче туган ил, торган җир, сөйгән яр, балага карата зур изгелекләр кылу турындагы бердәнбер хакыйкать лейтенант образына салынган эчтәлек аша төгәлләштерелә.

Соңгы өлештә авторның укучысына әйтергә теләгән сүзе укыла: “Биредә үлем никадәр әрсез, рәхимсез булса, тереклек шулкадәр үз-үзенә ышанучан, бирешмәс, мәгърур була белә”. Чын сугыш кыры дип рәхимсез яшәеш пространствосы атала. Димәк, кешенең яшәве үз-

үзенә ышанудан башланырга тиеш. Шул вакытта кеше Илаһиятнең – “олы алмазның бөтен сыйфатларын үзендә саклый. Ул каты… һәм нурлар чагылдыра”.

Укучы Зариф белән бергә тынлык артында яшерелгән илаһи серле матурлыкны – “аңлавы читен булган бер тынычлыкны тоя”. Гамьсез тынлыкны Зариф омтылган “кояшлы иртә тынычлыгы, нурлы иртә матурлыгы” кебек күңел тынычлыгы, гармония алыштыра. Хәзер ирнең муенында – җаваплы булырга чакырып торган мәхәббәт назы – кул җылысы. Үлем тормышың мәгънәле булганда куркытмый (“ул пуля тисә, бары тик чеметеп кенә алыр кебек”), дип фәлсәфи проблеманың чишелеше табыла.

Ә.Еники зур саклык белән укучыны мәхәббәтнең илаһи асылына төрә, җаваплылык хисенең кешене “алгы позициядә” тотучы, чит чынбарлыкта үзең булып калырга ярдәм итүче буыннар тарафыннан расланган бердәнбер юл икәнлегенә төшендерә.

***“Бер генә сәгатькә“ (1944)*** хикәясендә вакыйгалар барган урын “авылдан ике километр ераклыктагы сөзәк сырт буйлап үткән тимер юл” белән бәйле рәвештә бирелә. Хикәядә тимер юл – бер юнәлешле юл, сөзәк сырт сакраль үзәк буларак гел кабатланып килә. Хикәяләүче вакыйгаларны күзәтүче позициясендә торучы автор карашын – әдип күңелендәгесен әйтеп барачак “Галимҗан абзый тәрәзәсеннән” бәяләргә чакыра һәм укучыны аның “авыл очындагы йортына” алып керә. Укучыга кешенең барган җирдән тукталып уйланган мәле һәм шул мизгелдәге кичерешләренең хакыйкатьне аңлауга алып чыгачагы турындагы төп эчтәлек пространство бирелеше аша искәртелә: “... нәкъ каршыда карт юкә агачлары ышыгына яшеренгән кечкенә кызыл кирпеч станция бинасы һәм сарыга буялган кызыл түбәле җыйнак каралтылыр күренә.” Юл хронотобына кешедә күңелнең тулган чагы да, вафасыз, битараф чагы да булырга мөмкин дигән эчтәлек салына: “Станциядән ике якка сузылган берничә рәт юллар кайчан буш була; тик теге яки бу тупиктагы ялгыз вагон, онытылып калган шикелле, моңаеп тора... Кайчак бу юлларга озын-озын эшелоннар килеп туктый.” Бушлык – битарафлык хисе – кеше күңеленең “тупик”та икәнлеге, гүяки юлда барганда онытылып, югалып калганлыгы билгесе. Күңелдәге хисләр кешене ниндидер гамәлләр кылырга – хәрәкәт итәргә чакыралар, яшәешне шул хисләр бәйләме оештыра. Хисләрнең буталган чагы кешене барган җирдән тукталып уйланырга, борчылырга мәҗбүр итә: “Күп вакытта вагоннарның ишекләре ачык

була, һәм аннан кешеләр сикерешеп төшеп, арлы-бирле йөри башлыйлар.” Хисләрнең тәртипле хәрәкәте, уйланган-үлчәнгән белдерелеше генә тормышның чынлап та алга баруын билгелиләр: “Кайвакытта исә вагоннар ябык була, һәм алар җепкә тезгән уенчык вагоннар төсле булып күренәләр: гүя аларның кара тәгәрмәчләре бик юка, җиңел һәм чак җиргә тиеп, хәзер тәгәрәшеп китәргә торалар.” Хисне йөртүче “ерактан бик сылу, дәртле, кыю булып күренгән” чынбарлык (кара паровоз) яшәештәге кеше кылачак сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендәге һәрбер кечкенә генә тоелган гамәлне билгели (“һавага бер-бер артлы тезелешеп киткән кечкенә ак болытлар тарата”).

Хикәяләүче хакыйкатьне эзләү юлында калган Мәрьям абыстай белән таныштыра: “...Мәрьям абыстай өйнең кечкенә тәрәзәсеннән шул күренешкә – карт юкәләр ышыгындагы тәбәнәк кызыл станциягә һәм аңардан ике якка сырт буйлап “көмеш дилбегә” төсле сузылып киткән юлга карап торырга ярата иде”. Аның әлеге кичерешләре үзе өчен яңа, көтелмәгән, чөнки үзендә моңа охшаш теләкләр барлыгын ул хәтерләми: “...станциягә, поездларга күптән ияләшкәнгә күрә, аларны бар дип тә белми һәм тәрәзәдән карап тору теләге бервакытта да күңеленә килми иде”. Шул рәвешле, Мәрьям абыстайның кичерешләрендә үзгәрешләр барлыкка килүе “эчке һәм тышкыны, җирне һәм күкне, кешене һәм Илаһины тоташтыручы”тәрәзә символы аша билгеләнә. Хикәяләүче инде “тәрәзәдән карап торырга гадәтләнгән” ананың кичерешләрен хәзерге даими халәте итеп тасвирлый.

Хикәядә өч улын сугышка озаткан ана образы аша яшәү-үлем фәлсәфәсе аңлатыла. Элек “авылның башка хатын-кызлары белән бергәләшеп станция каршына йомырка, сөт, май алып барып, сатып кайтуны” яшәү тәртибе иткән Мәрьям абыстай исәбенчә, тормыш – бер үк хисләрнең үзгәрешсез кабатланышы: “алар кайчан да булса, шул ук юл белән, шундый ук вагоннарга утырып, шушы кечкенә станциягә кире кайтып төшәргә тиешләр иде.” Хикәя Мәрьям абыстайның әлеге “фәлсәфәсен” бәяләүгә, төзәтүгә корылган. Ананың хәзерге даими халәте – үз теләкләренең үтәлүен көтү, тормыш-яшәешкә шул теләкләрнең чынга ашу-ашмау ноктасыннан бәя бирү (станция буш вакытта, өметсезлеккә бирелеп, тәрәзәдән китүе, озын эшелоннарны күрүгә, өметсезлекнең шул ук дәрәҗәдәге өметкә алышынуы). Автор кешене ярсу теләкләре үтәлергә мөмкин булган мизгелдә тасвирлый. Кеше сагынып көткән теләкләрнең үтәлү

мизгеленә озак килә, шул сәбәпле аның күңеленә шушы өметләр һичшиксез дөрес, башкача булырга мөмкин түгел дигән ышаныч кереп урнаша. Теләкләрнең үтәлү мәленә якынлашу кичерешләрне киеренкеләндерә: “Кайвакыт ул сырт буйлап станциягә таба килгән озын эшелонны күрә. Сырт өстеннән караган кояштан кечкенә кызыл вагоннарның зур кыек күләгәләре авыл ягына таба төшкән, һәм бу бер-берсеннән тигез яктылык белән аерылган кыек күләгәләр яшел чирәм өстеннән бик кызу куып баралар, ә рельслар буйлап җиңел кара тәгәрмәчләрдән калышмыйча чуар яктылык йөгерә”. Өмет (кояш) кешене яшәтә, чынбарлык моделен алдан күрергә (вагоннарның зур кыек күләгәләре) корып куярга (тигез яктылык белән аерылган кыек күләгәләр), үзең тудырган чынбарлыкка ышанып сөенергә мөмкинлек булдыра (чуар яктылык йөгерә). Кешедәге хисләрнең, гамәлләрнең башлангычы шул ышаныч белән бәйле: “поезд өстендә һавада чак сизелерлек вак кына якты дулкыннар тирбәнеп кала...” Теләкләрнең үтәлү мизгеле якынлашкан саен кеше гүяки шул теләкләрендә эри, югала, аның теләсә кайсы гамәле шул максатка хезмәт итә башлый: “Ә бераздан Мәрьям абыстайның колагына сузып кычкырткан гудок тавышы килеп ишетелә. Бу тавышны ул салкын кан белән тыңлый алмый, бу тавыш аның йөрәгенә төшә, һәм ул, сихерләнгән кеше шикелле, поездан күзләрен аера алмый”. Чынбарлыкның үзе белән очрашу мизгеле – хисләрнең иң киеренке чагы (күз яшьләре мотивы): “Ул аның станциягә килеп җитүен, вагоннарның тавышсыз, салмак кына бәрелешеп туктауларын, поездан кешеләрнең төшүен һәм авыл янына кемнең дә булса килергә чыгуын көтеп, күзләренә җәелгән яшь томаны аша карап тора”. Ярсу (тавышлы) теләкләргә чынбарлыкның битараф (тавышсыз) булуы кешене өметсезлек чигенә җиткерә. Тормыш-яшәешкә үз теләкләренең чынга ашу-ашмау ноктасыннан гына бәя бирергә гадәтләнгән кеше өметсезлек хисенә бирелеп, еш кына шул теләкләренең колына әверелә, үз яшәешен ямьсезли. Теләкләрнең үтәлмәве гомернең бетүенә тиңләнә.

Укучы Мәрьям абыстайның яшәү мәгънәсен җуйган мизгелен укый: “Ул хәтта, гадәте буенча, тәрәзәгә барып, тимер юл буена карарга иренде. Аның йомык күзләре алдында нindидер танырга мөмкин булмаган күренешләр һәм кешеләр томан эчендә, еракта йөзәләр, ә колакларында бик ерактан ишетелгән буа тавышы шикелле, тонык кына гөжләү шаулый. Ләкин аның акылы тәмам оеган һәм сизгерлеге тәмам сүнгән иде”. Бу халәткә җиткән аң гадәтләнгән

бәхетле яшәү тәртибен шик астына куя. Иртә торып, “килене белән картының тышкы эшләрне бетереп керүләренә чәй урынын хәзерләп куярга” гадәтләнгән Мәрьям абыстай “кәефе ничек булуына карамастан” тәртипне бозмый, ләкин күңел биреп тә эшләми, өметсезлек китергән халәт аны тозакта тота: “ Уй юк, бернинди сизү юк, тик күз кабакларын авырайткан, гәүдәне һаман урынга сөйрәгән хәлсезлек кенә бар. Бу саңгырау хәлсезлек аның бөтен тән әгъзаларына, ниндидер бер чирнең ашыкмыйча килүе төсле, акрын гына җәелә бара һәм колаклары эчпошыргыч бер тоныклык белән туктаусыз шаулап тора иде”.

Ихлас чакырып теләгән теләк чынга аша, “саңгырау хәлсезлек шаулап торган” ананың колагына: “Әни!” – дигән тавыш ишетелә”. Тик бары шул теләкне генә идеаль чынбарлык сурәте кебек кабул иткән кеше аның чынга ашу мизгелен якынайтып арыган, йончыган хәлдә була. Улының тавышын ишетүгә сискәнеп куйган “Мәрьям абыстайның бөтен тәне буйлап кискен калтырау йөгерде, ниндидер бер саташулы төштән котылырга теләгәндәй, ихтыярсыз башын чайкап куйды һәм авырайган күз кабакларын ачты. Мәрьям абыстайның күзләрендә бер секундка саташулы курку кабынган кебек булды”. Ананың психологик портреты, елау – аның кичерешләренең иң киеренке ноктасына җитүен хәбәр итә: “Аның иреннәре кыз-кызу кыймылдый башлады: әллә ул шатлык авазы белән кычкырырга тели иде, әллә, кызу гына пышылдап, берәр дога укымакчы иде”.

Шул урында хикәяләүче чагыштыру өчен Галимҗан абзыйның психологик портретына игътибар иттерә: “Галимҗан абзыйның йөзе җыеп ала алмаслык бер елмаюга әйләнгән; ничек кенә тыныч булырга тырышмасын, аның да иреннәре агарган һәм акрын гына калтыраналар”. Ике портретның янәшә бирелүе очраклы түгел. Мәрьям абыстайның кичерешләре – ана кичерешләре дип кенә бәяләсәк, хикәя шул урында тәмамланырга тиеш иде. Кичерешләр үсеше әле дәвам итә. Галимҗан абзый портретына авырлыклар алдында югалып калмаска көч тапкан ир сыйфатлары салына. Карчыгын, киленен юатуы – башкаларны кайгыртуы Галимҗан абзыйның фәлсәфәсен ачып бирә: “Сабыр бул!”. Автор карашларын әйтеп бирүче ата улыннан күпмегә кайтуын белешә. Укучы яңа кичерешләр дулкынына кинәт керә. Һәркемгә шатлык алып килгән Гомәрнең кайту вакыты бер генә сәгатьлек икәнлеге ачыклангач, конфликт башлана. Геройларның кичерешләре – “ят, ямьсез бер

тавышка” – хәсрәтле, кырыс чынбарлыкка мөнәсәбәтләре төсендә яңгыратыла: “…алар бу тавыштан ничектер барысы берьюлы кинәт катып калдылар. Галимҗан абзый улына кызганыч елмаю белән, ышанмыйча карый, Мәрьям абыстай исә, бөтенләй таңга калып, бернәрсә аңламаган кыяфәт белән, күзләрен зур ачып, улына текәлгән иде. Алар шундый көтмәгәндә очрашу шатлыгы белән шундый тиз аерылышу авырлыгын бер үк вакытта аңлау, тоюдан гаҗиз иделәр. Алар бу бер-берсе белән сыеша алмый торган ике капма-каршы хиснең кайсын чынга алырга, кайсына ышанырга, кайсысы белән бу минутта яшәргә кирәклекне белмиләр иде”. Хисләрне үз урынына утырткан чынбарлык һәр геройның яшәешкә мөнәсәбәтенең белдерелеше кебек укыла. Гомәрне елап каршылаган Камилә аптырашта – “үзе дә сизмәстән елавыннан туктады”. Мәрьям абыстай тагын өметсезлек чоңгылына чумды – “яңадан хәлсезләнде, әлеге бушлык аны янә үз эченә йота башлады”. Бала Зәйнәп барысының да теләген кычкырып җиткерүче: “Юк, юк... Китмисең, абый, китмисең!”. Туктап калган вакытны Галимҗан абзый хәрәкәткә китерә: “...Кешенең минутлары санаулы”. Ә.Еники хакыйкатьне  яшеребрәк белдерергә ярата, укучыны сискәндереп куя:“Камилә каенатасының сүзеннән төртеп уяткандай сискәнеп куйды һәм уңган килен өлгерлеге белән, ике кулы түгел, дүрт кулы бар төсле, өй эчен бер итеп эшләргә кereште. Мәрьям абыстай да үзенчә нәрсәдер эшләргә тырыша иде”. Автор биредә кешегә санаулы минутлар – бер генә сәгать авыр хисләр колы булып яшәр өчен түгел, ә якты хисләрне үстерер өчен бирелә дигән хакыйкатьне җиткерә кебек. Камиләнең килен буларак нәсел утын саклау гамәлен җиренә җиткереп башкаруы соклану уята:“Ул иң элек Зәйнәпне читкә чакырып алып, колагына нәрсәдер әйтеп, каядыр йөгертте. Соңра самоварны җилтерәтеп алып идәнгә куйды, су өстәп, коры чыралар белән ут салып җибәрде. Учак алдына кечкенә тимер таган белән таба куеп, аның астына ут якты”. Нәсел-ыруны саклап тору билгесе кебек укылган учак образы Ә.Еникинең башка хикәяләрендә дә кабатлана. Биредә “улыннан ерак китәргә курыккан шикелле, һаман өстәл тирәсендә әйләнгән, кулына алган әйбере белән баскан урынында туктап калган, нәрсә эшләргә кирәклеген оныткан кебек, уйланып торган” ананың кичерешләре Галимҗан абзый тарафыннан бәяләнә, ул “үзе торып чәй хәзерләргә керешә”. Автор авыр хисләр белән яшәп, кеше үзе кылырга тиешле гамәлдән ераклаша, ди. Иң мөһиме – авыр хисләр колы булып яшәү якыннарны

уңайсызлый, читкә этәрә, бәхетсез итә, гомерне кадерсез итә дип кабатлый авылга “этиемне, әниемне, барлык туганнарымны шатландырырмын, бәхетле итәрмен” дип “ашыгып, тирләп-пешеп, йөгерә-атлый кайткан” Гомәр бәясе аша: “Гомәргә әнисенең бу гаҗизлегенә карау бик авыр иде. Аның йөрәге әнисен кызганудан сызлана башлады...”. Автор сабырлык фәлсәфәсен татар кешесенең яшәеш фәлсәфәсе кебек тамгалап куя, соңрак ана белән ул күрешеп саубуллашу вакыйгасында кабатлый (“татар улларына хас тыйнаклык белән, бары күрешмәкче” генә булса да, “әнисенең шундый тирән бер газаплы мәхәббәт белән сүзсез караган яшь тулы күзләрен очраткач, ирексездән аның кечкенә, җиңел гәүдәсен күкрәгенә кыса”) .

Сабыр булырга чакырган тирәлек кешенең ярдәмчесе дә, шатлыкны бүлешергә килгән авыл малайлары-кызлары арасында туган бәхәс шул хакта. Биредә Мәрьям абыстайның улына ышаныч белдерүе, аның белән горурлануын сиздерүе үзен кулга алуы турында сөйли. Бу халәттә ана улына чиксез көч өсти, аны мәхәббәт дөньясына алып чыга: “Мәрьям абыстайның шулай улым кайтты дип балаларны сөендерергә тырышуыннан Гомәр әнисенең үзенә булган мәхәббәтен аеруча бер тирәнлек белән сизеп алды һәм ана мәхәббәтен мондый тулылык белән сизү аның өчен кинәт бие авыр булды”. Биредә Гомәрнең күз яшьләре аның хисләре яктыруы турында хәбәр итә. Димәк, чын мәхәббәтне һәр мизгелдә тоеп яшәү генә кешене авыр хисләрдән алып чыга, коткара ала, ди автор ана һәм ул образлары эчтәлегенә салып. Ә.Еники хикәяләрендә еш кабатланган бергәләп чәй эчү – автор, хикәяләүче, укучы, геройлар хисләренең бер дулкынга урнашуы турында сөйли. Биредә Гомәр гадәтләнгән сөенечле чынбарлыкка кайта (әтисе белән әнисенең таныш бәрелешүләре, аңа аларны килештерелек сүз табарга кирәк булуы, әтисенең халыкара хәлләр белән кызыксынуы, әнисенең гаиләнең эчке сәясәтенә күбрәк игътибар бирүе). Ләкин, “санаулы минутларның үтеп китүе” һәммә кешене борчуга сала. Автор Галимҗан абзыйдан әлеге кырыс дөреслекне әйттерә дә, геройларның шул аерылу мизгеленә мөнәсәбәтен яшәешкә мөнәсәбәте кебек тамгалый. Гомәр “тыштан ничек тә тынычлыгын сакларга тырыша”, Мәрьям абыстай исә елый башлый, Галимҗан абзый сабыр булырга чакыра, Мәрьям абыстайның агасының улы Шәрифулла солдат барысын да киләчәккә ышанырга – көтәргә чакыра. Бу мизгелдә һәркем елый. Ана күз яшьләренә мәхәббәт мәгънәсе салына һәм әлеге мәхәббәт тудырган илаһи хис –

матурлыкны тою тамгалана: “ Яшьләре аның, ана йөрәгендә изге бер чишмә ачылган шикелле, туктаусыз агалар. Бу яшьләрдә газаплы хәсрәт ачысы юк, бу энҗедәй саф яшьләрдә тик ана мәхәббәтенең мәңге сүнмәс җылысы гына бар”. Димәк, ана мәхәббәтенең мәңге сүнмәс җылысы матурлыкны тою өчен изге бер чишмә булып тора. Мәрьям өч тапкыр елый. Соңгысында аның мәхәббәт белән тулы эчке дөньясы ачыла.

Гомәрне озату – шул хисләрне сынау вакыйгасы буларак тәкъдим ителә. Автор гүяки тормыш кешене каршылау – килү, кунак итү – кунак булу, озату – китү кебек бер сәгатькә исәпләнгән өч вакыйгадан тора, дип искәртә кебек. Автор Гомәрнең иңбашына юл капчыгы аса, ул капчыкта “оекбашлар, сөлге, яулыклар, азык-төлекләргә” төреп салынган хакыйкать – мәхәббәтнең мәңге сүнмәс җылылык бирүе буыннардан килгән мирас икәнлеге тамгалана. Кешенең гомере дәвамында шул хакыйкатьне аңлауга килүе – “торып киткән җирләренә кайтып, йөргән эзләренә яңадан басып йөрүе үз гомерендә кабатлана торган нәрсә” икәнлеге әйтелә. Хисләре үзгәргән Галимҗан абзый (иске кырпу эшләпәсен бүрегенә алыштырып кигән) бу хакыйкатьне раслап куя. Кара сатин тышлы билле бишмәтен киеп, кечкенә мамык шәлен беләгенә салып Мәрьям абыстай шул хакыйкатьне кабул итәргә әзерләнә. Е.Н.Бохонная фикеренчә, шәл-яулык халык авыз иҗатында ике дөнья арасындагы чик мәгънәсендә укыла. Ак яулыгын кулына алып поезд артыннан баргшан Заһидә дә ике дөнья чигенә куела.

Җиңел тарантаска җигелгән туры ат образы ярсу хисләрне йөгәнләү мәхәббәтне тоюга алып килә, дигән эчтәлекне укырга ярдәм итә. Шул урында автор укучысын яңа рухи үргә әзерли. Яңа сулыш белән яши башлар өчен ярсу хисләрне тыю, мәхәббәтне тою кирәк: “Менә хәзер аның алдында туган авылы тоташы белән ачылды. Бер караш ташлау белән ул авылның бөтен тыкрыкларын, таныш өй түбәләрен, авыл каршындагы сөзәк тауны, тау астындагы вак куаклыклар арасыннан боргаланып, яшеренеп аккан кечкенә елгачыкны, чәчәкле тар тугаен һәм авылның ике очыннан башланып киткән тигез, киң иген кырын күреп алды”.

Бер сәгатьлек гомерне мәхәббәт кенә илаһи матур, мәгънәле итә, дип автор шул хакыйкатьне солдатлар, Заһидә образы аша да раслап куя. Станция платформасында очраган солдатлар “әти-әниләре белән бәхетле күрешүгә өмет итүчеләр кебек” – шуны аңлаган кешеләр

буларак тамгалана: “бу солдатлар чал кергән түгәрәк кара сакаллы, таза бәдәнле Галимҗан абзый белән ак йөзле, кечкенә буйлы Мәрьям абыстайга олы кызыксыну һәм эчке уйчанлык белән карыйлар иде”. Майор исеменнән хакыйкатьне аңлаганнар – горурланырлык кешеләр, дигән фикер җиткерелә. Биредә Мәрьям абыстайның ана буларак эчке кичерешләре – тынычлануы әйтелү дә әлеге карашны раслап кую өчен кирәк.

Аерылышу мизгелендәге иң авыр хисләрне кичерүгә укучы инде әзерләп куелды. Һәркемгә газаплы булган бу мизгел гүя кыска вакытлы тормышның кадере, шуңа күрә гел алга карарга, “бирешмәскә кирәклеген” искәртә кебек. Ана “бөтен сыны белән вагон ишегенә йотлыгып карый”. Гүяки Гомәргә бәйле чынбарлык “тоташ кызыллык эчендә югала”. Ахырда бу кызыллык, сыегаеп, чуар бер шәүләгә әйләнү, поезд артка таба чапкан кебек тоелу – мәхәббәт матурлыгы белән тудырылган яңа хисләр чынбарлыгы ул.

Мәхәббәт матурлыгы кешене яшәү юлына алып чыга, аны ярсу теләкләренең колы булудан азат итә. Кеше өмет белән яши башлый, ләкин бу өметне башка беркайчан да өметсезлек алыштыра алмый. Ана бу хакыйкатьне башкаларга җиткерергә бурычлы икәнен аңлый. “Җәйге пальтосының югары төймәләрен ычкындырган, башындагы ак яулыгын кулына алган, кыска толымнары сүтелә төшеп, чәч бөртекләре җилдә очкалаган, кыр җиленнән һәм кояштан янып каралган киң маңгаена, борын очына тир бөртекләре чыккан” Заһидә бу хакыйкатькә килү юлына чыгарыла. Әлегә ул ярсу теләкләре белән көрәшә, чынбарлык тудырган хисләр аның гамәлләрен билгели: “ Ул поездның киткәнен белә. Ул аның тавышын ишете. Кызыл эшелонның сырт артына яшеренүен күрде. Гомәрне алып киткән поездның ак төтеннәре, вак болытлар булып, станция өстеннән акрын гына йөзеп үтәләр – ул шуларны күреп бара. Ләкин бара, Гомәрнең китүен, аны күрми калуын бик яхшы белсә дә, юри тукталырга теләмичә, тыеласы килмәгән бер ярсу белән аскы иренен тешләп һаман бара”. Шул мизгелдә очраган туры ат детале кызны яңа юлга алып чыгачак яңа хисләр әзерләнүе турында искәртә. Бу хисләр дөньясына кызны “йомшак тавыш белән ата булып” Галимҗан абзый алып керергә тели: “Кызым, Заһидә, утыр безнең янга!” Ләкин Заһидә әле җир белән якынлыкны тою кирәклеген белә (юл буена чирәмгә утыра), чынлыкны аңлауга килү өчен хисләрнең дөрес түгелен алып ташлау кирәклеген сизә: “Ул беркемгә үпкәләми дә, беркемгә ачуланмый да иде. Ул бары

йөрәге төбеннән күтәрелгән, бөтен тәне буйлап йөргән тиле ярсуны баса алмыйча газаплана. Ул тырыша, ачу белән башын селкеп куя, аскы иренен тешләп тоа, ләкин юк – төер һаман бугазына килә. Ахырда ул башын кинәт тез өстенә сала һәм һичбер нинди тыелусыз, юка пальтосы аша түгәрәкләнеп, тыгызланып торган иңбашларын калтырыта-калтырыта елап җибәрә”. Елау аны башка хисләр дулкынына күчәргә әзерләнгәнен хәбәр итә.

Хикәяләүче өметле яңа чынбарлык хөкем сөргән пространствога игътибар итә. Мәрьям абыстай улыннан калган портсигарны һәркемгә күрсәтеп, исән кайтуга өмет тудырганнан соң, яшереп куя, берөзлексез матур мизгелләрне хәтерендә яңарта. Галимҗан абзый “буе-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән, чын ир булыр күренгән” улының киләчәге, гаилә корачагы турындагы хыялларны күңел төпкеленә яшерә. Камилә исә “өзелеп сагынган Фатихын ничек каршы алуы, нинди сый-хөрмәт күрсәтүе, нинди назлар белән куштанланып сөюе турында уйлаудан тыела алмый иде”. Шул рәвешле, һәркем күңеленә мәхәббәт тудырган матур, якты, бераз хыялый, серле, әмма шулкадәр бәхетле чынбарлык кереп урнаша. Ана бу чынбарлыкны җуюдан курка, чөнки хыялда тудырылган хисләр кешене яшәтә, юлга алып чыга, тынычландыра бит. Аның “Кайтыр, күз нурым, кайтыр!” дип үзалдына әйтүе “өметләнергә кирәк, өмет хыялдагы хисләрне чынбарлыкка күчерә” дигән авторның укучыга мөрәҗәгате кебек укыла. Пейзаж кабатланышы мәхәббәтнең идеаль чынбарлык тудырырга сәләтле көчен хакыйкать итеп раслап куя. Станция буш, тимер юл тыныч. “Һәм күңел әнә шул нурлы томан артына китеп югалган яшел кырлар түреннән ерактагы поездның дәртле кычкыртып килеп чыгуын тоеп тора”. Автор кешенең яшәешен аның хисләр бәйләме билгели дип кабатлый һәм әлеге хисләрнең һичшиксез якты булырга тиешлеген дәлилләп уза. Мәхәббәт яңа чынбарлыкка – өметле, бәхетле, ышанычлы хисләр дөньясна алып чыга, курку катыш ярсу теләкләрне юк итә, кыска вакытлы гомерне мәгънәле итә, ди Ә.Еники.

Ә.Еники хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсе тәкъдим ителү бу дәвер татар прозасын яңа юлга алып чыга.

Әдәбият

1. Бахтин М.М. Формы времени и хронотопа в романе //Вопросы литературы и эстетики. – М., 1975.– С.391.

2. Бохонная Е.М. Функции цветообозначения единиц с семантикой “одежда” в лирической песне (на метериале сибирского фольклора). – library.krasu.ru. – С.159

3. Еники Ә. Әсәрләр, өч томда. III том: Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

4. Заһидуллина Д. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004 .– Б.248.

4. Нигматуллина Ю. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур.– Казань: Фэн, 1997.– С. 47.

5. Сверигин Р., Хатипов Ф. Әмирхан Еники (1909-2000) / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда – 6 том: 1960-1990 еллар татар әдәбияты – Казан: “Раннур” нәшр.., 2001. – Б. 97-122.

6. Топоров В. Миф. Ритуал. Символ. Образ: Исследования в области мифопоэтического: Избранное . – М., 1996. – С.279.

## *XX гасырның 60 нчы еллар тәнкыйди юнәлешле татар прозасында милли яшәеш фәлсәфәсе*

Яшәп килүче идеология шартларында системаның нигезен билгеләгән якларны ачуны күздә тоткан тәнкыйди юнәлеш 1955-1957 елларда Ә.Еникинең “Саз чәчәге”, 1962 елда Ә.Еникинең “Рәшә”, А.Гыйләҗевның “Өч аршын җир” повестьлары язылу белән калыплаша. Әдипләр иҗтимагый проблемаларны алга куеп, татар кешесенең милли йөзе турында уйланалар. Психологизм алымнары, символлар бирелеше ярдәмендә автор тавышы тагын да ачыграк яңгыраган бу әсәрләрдә укучы күңеленә курку хисе кешедәге иң матур тойгыларны җимерә алучы, аны түбән тойгыларга таба боручы көч, дигән хакыйкать урнаштырыла.

***Ә.Еникинең “Рәшә” повестена (1962)*** карата язылу-басылу дәвереннән башлап һәм әдәбият белгечләре, һәм тәнкыйтьчеләр әледән-әле мөрәҗәгать итә. 1964 елгы мәкаләсендә Ф.Миңнуллин болай яза: “Әмирхан Еники әсәрләре безнең тәнкыйтькә кызу бәхәсләр, капма-каршы фикерләр кузгатып килде. Аның фикеренчә, “Рәшә” – Зөфәрләр турындагы повесть. Ә.Еники үзе Зөфәр Сабитовны

Сез кайдан, ничек табып алдыгыз? дигән сорауга болай җавап бирә: “Зөфәр Сабитовны табуы читен булмады. Алар бар иде һәм хәзер дә беткәннәре юк, минемчә. Ләкин Зөфәр кебек кешеләр бары сәүдә-тәэминат тирәсендә генә йөриләр дип уйламаска кирәк... Хикмәт бит профессиядә түгел, ә кешенең фәлсәфәсендә...”.

Повесть тирәсендә 60 нчы елларда барган бәхәсләр “норматив тәнкыйть тарафдарлары һәм иҗади тәнкыйть вәкилләре арасындагы фикер һәм караш аермалыклары” формасын ала. “Задача Амирхана Еникеева – не просто разоблачить жулика и тунеядца, ловко скрывающего свое истинное лицо. Он ненавязчиво, с терпеливой обстоятельностью вскрывает истоки эгоистической философии сабитовых и выносит им бескомпромиссный приговор. Повестьта “чын совет кешесе образын” эзләүче К.Фасеев. Р.Мостафинга җавабында болай яза: “Получилось не разоблачение, не “вынесение приговора”, а искуственное раздувание темных, мрачных сторон жизни и морально уродливых персонажей, отсуствие образов, олицетворяющих цвет нашего общества, определяющих сущность социалистических отношений.

Әсәр текстында вакыйгалар вакыты 1945 елның тугызынчы мае дип тарихи билгеләнеш ала. Хикәяләүче укучыга Бөек җиңү иртәсендә “уяныргa” тиешле Зөфәр Сабитовны тәкъдим итә. Геройны эчке халәтен сөйләп бирү өчен кулланылган төш алымы белән автор укучыны сюжетка керергә әзерли. Геройның ят бер дала буйлап ялгызы каядыр китеп баруы аның күңел кичерешләренең үзе өчен таныш булмаган билгесезлек халәтенә керүен хәбәр итә. Укучы Зөфәр күңелендәге битарафлык, гамьсезлек халәтенең аның даими халәте икәнлеген аңлый: “Дала буш, дала тын, үзе тип-тигез, очсыз-кырыйсыз”. Бу хиссезлек шулкадәр озакка сузылган ки (“үләннәре саргаеп кипкән”), хәтта кеше тормышында үзгәреш китерә алырлык кичерешләрнең нигезе юк (“кара туфрагы, чатнаган чуендай, яргаланып беткән”). Геройның тормышында аңа таныш түгел башка хакыйкать белән очрашу әзерләнә: “Бик эссе, бик коры, төпсез күктән кызган тимердәй ап-ак кояш аның күзенә туры карый...” Укучы Зөфәр күңелендә туган ят халәтнең аңлатылышын таба: ирне үзгә чынбарлык белән очрашу котылгысызлыгы борчый икән ( тере кояш... берөзлексез яндыра, көйдерә, имеш. Шул ук вакытта ул бу халәтеннән (“котсыз дала”) котылуны тизләтергә ашыга: “Кая бара ул, мәгърипкәме, мәшрикъкәме – ачык кына белми дә, имеш, ләкин барырга кирәк,

бармыйча ярамый, чөнки монда туктап калу һич мөмкин түгел”. Хикәяләүче бу урында аның ялгыз гына чыгып китүенең сәбәбен үз бәхетен табу омтылышы белән бәйли, Зөфәрнең үз фикер-халәте буларак җиткерә. Шул урында авторның һәркем үз бәхетенә юлны үзе эзли һәм таба дигән карашы укыла: “Һәм берәүгә дә әйтмичә, берәүне дә ияртмичә ялгызы гына чыгып китүе дә бары шуның өчен генә, имеш”.

Хикәяләүче укучы Зөфәр халәтендәге әлеге үзгәрешнең инде озак вакытлар әзерләнеп килүен кояш образының эчтәлегенә салып сөйли. Зөфәр әлеге үзгә чынбарлыкны таный ( ул аңа “юлдашка эт шикелле ияргән гамьсез кояш” кебек), ул хәтта шул пространствода хәрәкәт итмәсә дә, гамәл кыла, гамьсез генә яши дип бирә : “Баштарак аңа тигез дала буйлап атлавы бер дә күңелсез, авыр булып тоелмады. Киресенчә, бу иркенлектә, бу тынлыкта бару рәхәт тә кебек иде”. Гамьсезлек – кешенең матур хисләрен үле хәлгә китерергә сәләтле халәт, тора-бара ул шом тудыра, ди автор Зөфәр сайлаган юлның дәвамын тасвирлап (“Ләкин тора-бара очы-кырые күренмәгән үлек дала аны борчый, шомландыра башлады”). Хакыйкатьне кабул итәргә Зөфәр әлегә әзер түгел. Үзе битараф булган булган чынбарлыкның тик торганда күңелен борчый башлавы Зөфәрне нәфрәтләнергә мәҗбүр итә: “Тагын шоп-шома күктән шым гына ияреп барган “юлдашы да” бик мәкерле, явыз булып чыкты. Хәзер ул Зөфәрнең нәкъ менә баш түбәсен кыздыра, шундый кыздыра, әйтерсең, юри кайнатып чыгарырга тырыша...” Автор ирнең чарасызлык хәлендә калуын – сусавын тасвирлый: “Атлаган саен көчәя барган бу сусауга һич кенә дә түзәрлек түгел иде, коточкыч авыр иде, чатнап кара янган иреннәре бертуктаусыз: “Су... су... су... !” – дип үзлегеннән кыймылдый иде”. Димәк, яшәү символы  кебек укылган су элементы ярдәмендә автор Зөфәрдә туган яңа омтылышны – башкача яшисе килү теләген тасвирлап бирә. Күл – “шашарга җиткән” Зөфәр каршында пәйда булган, ул теләп чакырган яңа чынбарлык гәүдәләнеше: “ ... кинәт җем-җем уйнаклап яткан түп-түгәрәк, зур бер күл ачылды... Бу шулкадәр чын иде, шулкадәр якын иде, гүя менә суның йомшак дымы аның йөзенә килеп тигәндәй булды”. Биредә автор гел тәкъдим итеп килгән яшәү фәлсәфәсе укыла: өметсезлек алдында калган кешегә тормыш-яшәеш һәрчак үзгәрү, дөрес юлга чыгу мөмкинлеге бирә. Хикәяләүче ирнең бу чынбарлыкка сусаган, аңа кабул итәргә әзер икәнлеген психологик портрет алымы аша көчәйтә (чатнап кара көйгән

иреннәре, томаланган, шашарга җиткән күзләре, салкын суны көлә-көлә, елый-елый –- үз, якын ( “күл бик якын кебек иде”), торган саен матурая баручы (“тигез җирдән үк башланып киткән сай читләре агарып, ә эчтәрәк, тирәнрәк урыннары зәңгәрләнеп тора кебек”), ләкин иң матур серләрен тирән яшергән “сихри дөнья” (“Тик аның аргы чите генә ачык күренми; анда биек камышлармы, текә ярлармы бар кебек, ләкин алар барысы да күз үтә алмаслык күгелҗем томан белән өретелгән иде” ).

Кешегә табигать тарафыннан идеаль чынбарлыкны кору мөмкинлеге бирелгән, көч салынган, ләкин әлеге потенциалны эшкә җигәргә комачалаучы җимергеч көч тә бар, дип автор сүзне сюжет сызыгына бора, укучы күңеленә урнашырга тиешле хакыйкатьләрне вакыйгалар үстерелешендә раслый. Бередә өн/төш оппозициясе төп геройга мөнәсәбәтле чынбарлык/хыял, идеаль каршылыгы кебек оеша, укучы Таибә абыстай образына салынган эчтәлекне табуга вакыйгаларны “алдан укый”: “Төш кинәт өзелде, Зөфәр сискәнеп күзен ачып җибәрде. Бу ни хикмәт, кем болай дөнья җимерә? Ул ни дә булса уйлап өлгергәнче, залда яткан әнисе Таибә абыстай торып тәрәзәгә барган иде инде.” Шул рәвешле хикәяләүче Зөфәрнең гармониягә омтылышында Таибә абыстай юлын дәвам итәчәген алдан сиздереп куя. Әни кешегә бәя бирү өчен җиңү иртәсенә абыстайның карашы җиткерелә: “...Тордылар да бәрелә-сугыла чыгып чаптылар. Күк капусы ачылганмыни, – диде Таибә абыстай, азрак сукранып...” Билгеле, ана шартын китереп улы каршында абыстайлыгын мондый очракта гадәти әйтелә торган сүзләр белән раслап куярга да онытмый: “Йа рабби мәүләм, бу көннәрне дә күрергә насыйп иттең, рәхмәтеңнән ташламадың бәндәләреңне...”

Укучы Зөфәр Сабитов белән шулай таныша. Зөфәрнең җиңү бәйрәменә сөенүен аның сугыш башланганнан бирле “сәүдә кешесе, сәүдә бүлегенең мөдире” булып торуы билгели , “бу көнне көтеп складларда саклап тоткан” азык-төлекне чыгарыр вакыт җитте бит, “сәүдә точкаларына шалтырата башлауга” “ бәйрәм настроениесе гүя тышта торып кала”. Шунда ук ул сайлаган кием укучыны үз эчендә каршылык яткан яңа эчтәлекне кабул итәргә әзерли: “Эшкә барса да, бәйрәмчә булсын дип, чиккән якалы ак күлмәген, элүдә генә торган соры костюмын, җәйге туфлиләрен киде. Барысы бер төстән, бер иштән диярлек, тик менә зәңгәр кепкасы гына күренешне боза иде. Ярый инде, баштанаяк бертөследән киенер вакытлар алда әле...” Зөфәр

күңеле белән нидер көтә. Ләкин үз рухы, җаны белән бәйле түгел, күбрәк тышкы дөнья белән бәйле үзгәрешләргә өметләнә.

Укучы Зөфәр дөньясының икегә – үзенеке һәм “капкадан чыкканнан” соңгыга бүленгәнен аңлый. Шул рәвешле чит/үз бинар оппозициясе Зөфәр чынбарлыгының асылын билгели. Зөфәр ягымлы матур сеңлесе Хөршидне ярата, Зариф абыйсын, аның хатыны Сәкинә җиңгине якын итә. Хикәяләүче Зөфәрне бәйрәм иртәсендә “капкадан чыккач” якын кешеләре белән очраштыра. “Сыңар кулы белән кочып алып” абый кеше сеңлесенә карата күңеленең бер өлешендә яшәгән кайгыртучанлыгын сиздерә. “Хатыннар уртасында иңенә шәлен салып, башын кагып басып торучы”, ире Зарифның исән кайтуын ышанып көтүдән “йөзе тәмам нурланып, алсуланып киткән” Сәкинә җиңгине ихтирам итүен хикәяләүче Зөфәр теле белән сөйли. Чит дөнья дип билгеләнгән башкалар дөньясына ирнең мөнәсәбәте ачык: “бүгенге көннән ул берәүдән дә шүрләмичә, һәркемнең йөзенә туры карап йөри алачак”. Димәк, Зөфәрнең күңел халәтен билгеләү өчен кирәк булган эчтәлек табыла. Укучы ирнең башкалар дөньясыннан “шүрләвен”, үзенекләрне ихлас кайгыртуын белә. Куркуның сәбәбе – “бөтен кеше тегендә, ут эчендә, ә ул тап-таза килеш монда йөргәнгә” “башкаларның ят итеп, дошман итеп караулары”. Кешеләр “кыю, бәйсез” кулсыз майор Симаковны якын итә, “мәтәлдереп чөя”, “аңа авып китә”. Зөфәрдәге курку аны әлеге “кулсыз”ларны үз итә торган чит тирәлек белән сак булырга өнди, ул үзенә (киеменә) төс булмаган “зәңгәр кепкасын күтәрә төшеп, баш иеп узуны” мәслихәт күрә яисә “кулсыз майор белән очрашуларны яратмаганга” (дөресе, кирәк санамаганга), әйләнеп уза (соңрак Курамшин карт белән исәнләшкәндә кул бирмәве дә шул мәгънәне көчәйтеп килә). Кабатлау композицион принцибы ярдәмендә хикәяләүче Зөфәр Сабитов “түбәнчелек белән кулын сузган” чынбарлык турында әйтеп уза. Ләкин әлеге чынбарлык аның өчен әлегә ышанычлы түгел. “Таза гәүдәсенә иркен кара пальто, башына яхшы хәрби фуражка кигән завод директоры” “кулын бирсә дә”, Зөфәргә “тиешле” игътибар күрсәтми: “Менә директор да аның белән рәсми коры гына исәнләшкән булды. Ә бит ул Зөфәрсез – сыңар кулсыз!” – дип ризасызлык белдерә заводның эшчеләр тәэминаты бүлеге идарәсендә “үз исәбе” булган Сабитов.

Укучы Зөфәрдәге куркуның тирән кереп оялаганын аның кичерешләрен күзәткәндә ачачак. Хикәяләүче “кешегә ияреп кабынырга, очынырга, ...экстазга бирелеп китәргә яратмый торган,

хиссият мәсъәләсендә дә үлчәү-чаманы” белә торган Зөфәр теле белән кешедәге чын шатлык хисен сурәтләп, аны башка кичерешләр дулкынына күчерә: “... зур урамга чыккач, Зөфәр тагы да ныграк гаҗәпләнә калды... Бу чыннан да халыкның бернинди чакырусыз, өндәүсез, үзеннән-үзе туган, шуңа күрә сафларга тезелмәгән шатлык демонстрациясе иде”. Биредә “сафларга тезелмәгән шатлык” детале Ә.Еникинең яшәп килүче идеологиягә карашын тамгалый.Әдип идеологиянең “кулдан язган лозунглар, юлбашчыларның май демонстрациясеннән калган портретларын күтәргән” халыкның аңына үтеп кергән чынбарлык булуына борчылуын сиздерә.

Халык агымына иярүне тиеш тапкан Зөфәргә ихлас сөенә белү халәте ят: ир “бу мәхшәрдән тизрәк ычкынырга теләде”. Шул халәттә автор Зөфәрне үзгә дөнья – бик үз дә, шул ук вакытта чит итү дөресрәк тоелган Рәшидә белән очраштыра. Укучы Зөфәрне ихлас яратучы икенче бер “балаларча чын гаҗәпләнә белә торган” беркатлы чынбарлыкның “егетнең муеныннан кочып алуын” аңлый. Биредә автор уртак саналган шатлыкка ике капма-каршы мөнәсәбәтне тасвирлый. “Бәхетеннән бөтенләй онытылган” Рәшидәне әлеге олы шатлык үз гамәлен тагын да җаваплырак башкарырга канатландыра (“без бүген халыкка җырлап йөрибез”), ә “үзенә артык рәхимле, юмарт булып чыккан” – “башын да аяган, малын да биргән, өстәвенә сөйгән ярлы да иткән” тормыш бетү бәйрәмен күңеле аша үткәрә алмаган “акыллы” Зөфәр өчен бу – түбән хисләр уятучы “мәхшәр” генә (“Көне, көне – шатлыгын, мәхәббәтен, рәхәтен дигәндәй, икәүдән-икәү генә татый торган көн ич бу!..”). Зөфәрнең “бәйсез, иркен, мул” булырга тиешле киләчәк тормышына мөнәсәбәте ачыклана: аны “...акчаны малга әйләндерү ягъни йортмы-квартирамы сатып алу; ... аңа тәрәк һәм теләктәш булырлык әйбәт кенә кызга өйләнү” борчый. Кыскасы, аның максаты – үз чынбарлыгын сакларлык тыл булдыру. Шул рәвешле укучы күңеленә курку хисе кешедәге иң матур тойгыларны җимерә алучы, аны түбән тойгыларга таба боручы көч, дигән хакыйкать урнаша.

Икенче бүлектә хикәяләүче укучыны яңа яшәешкә – якты күңелле Рәшидә Сафина дөньясына алып керә. Сөйләү Зөфәрнең бу хакта искә төшерүе кебек оештырыла. Вакыйгалар башланган вакыт 1943 нче елның үтә салкын гыйнвар ахырлары дип тарихи вакыт буларак тамгалана. Зөфәр-Рәшидә очрашуын кабул итәргә әзер укучыга Зөфәрнең “салкын, караңгы, котсыз, буш” пространствода –

вокзал эчендә очраткан дүрт кешегә мөнәсәбәте инде гайре табигый тоелмый. “Яхшы пальто, күн түбәле каракүл бүрек, эт тиресеннән озын кунычлы унты кигән һәм бер беләгенә зәңгәр тышлы бәрән толыбын салып, икенче кулына кара чемодан тоткан, бик тук кыяфәтле, таза егетнең” “өсләре бик чуар, бик иләмсез”, тәпән шикелле юан, сырган чалбарлы, киез итекле, кайсы шәл уранган, кайсы малахай бүре кигән бу кешеләрне  чит итүе – “нәфрәтләнеп кул селтәве” укучыга гаҗәп түгел. Берсе түгәрәк, икенчесе какча битле кызларның балаларча беркатлылыгы һәм аларның “башында эче-тышы мех малахай бүрек, өстендә калын тышлы, сырган эчле, каракүл якалы пальто, аягында зур соры итек кигән, бүрегенең колакларын төшереп бәйләгән, якасын торгызган, билен тар каеш белән ныгытып буган” хуҗаларының дәртле-көчле булырга тырышуы “бер читтәрәк торган” Зөфәрне аптырашта калдыра. Автор бик төрле кешеләрне берләштергән яктылык, матур тойгылар читтән күзәтеп, шүрләп яшәргә күнеккән кешеләргә ят икәнлеген кабатлый. Буш пространствода очрашкан “кием-салымнары таза гына” әлеге ике ирне: “Юк, бирешмибез әле!” – дигән ышану берләштерә. Ләкин Яруллин бу халәткә кешеләргә якты мөнәсәбәт аша ирешсә, Сабитов исә кешеләрдән качу, саклану юлын өмет китерә дип саный. Ләкин Зөфәрнең ямьсез, катып калган, гамьсез, үзгәрергә теләмәгән чынбарлыгының сурәте кебек кабул ителгән “шадраланып тайгак-шома, пычрак кар каткан” бусагалы, “ярыкларына бәс утырган” тупсалы пространствоның юньләп ябылмый торган зур ишеге артында очраган дүрт кешеле пространствоны хикәяләүче бер якка бора. Турайга бару турында һәркем кабатласа да, егет “кечкенә коңгырт күзле, олырак, озынрак, өс-башы пөхтәрәк”Рәшидәне генә “ишетә”: “Зөфәр бер мизгел аңардан күзләрен ала алмыйча торды. Әллә ничек менә, кызның бер үк вакытта диярлек бик туры-җитди каравы һәм матур-сөйкемле итеп елмаюы аны гаҗәпләнеп югалып калырга мәҗбүр итте”. Зөфәр Рәшидәнең “беренче караштан ук бик самими һәм бик табигый тоелган” дөньясын  үз итә. Монысы укучы өчен беркадәр яңа эчтәлек. Зөфәр кебек кешеләрдә иң кимендә кызгану катыш көлке хисе уятырга тиешле чынбарлык матур дип бәяләнә, якын ителә. Димәк, күңеленә курку хисе кереп оялаган кешеләр асылда үзләрендәге бу хисне күралмый, аның табигый түгеллеген белә, хөрлеккә, бәйсезлеккә ирешү юлларын эзли. Зөфәр сайлаган “матди һәм рухи бәйсезлек” юлын автор яклый. Ләкин күңелендә  курку хисе йөрткәннәр  матди һәм рухи бәйсезлеккә ирешә

алмый, үзләре туплаган малның колына әверелә, дигән хакыйкатьне җиткерә.

Хикәяләүче Зөфәргә "ат табу вазифасын" йөкли, аның мөмкинлеге бар, ди. Хәрәкәт асылда Зөфәр күңелендә, аның чынбарлыгында булырга тиеш, ул ярсу хисләрен – түбән теләкләрен йөгәнләү өчен көч табарга тиеш. Автор Рәшидә исеменнән кешегә үзгәрер, дөрес юлга чыгар өчен бирелгән мөмкинлек турында кабатлап әйтә: "Сез табарсыз, әгәр теләсәгез". Рәшидә образына салынган матурлык эчтәлеге авторның фикерләре кебек кабул ителә. Кызның беркадәр катгый, көтелмәгән, шул ук вакытта үтә дә гади сүзләреннән гаҗәпкә калган, уйланырга мәҗбүр булган Зөфәрнең беренче уе гадәти: "...кирәк микән болар белән юлдаш булырга? Үзе дә аңлап җитмичә, нәрсәдәндер, ни өчендер бераз гына шүрли кебек..." Янында торган күшегеп беткән җаннарга караш ташлап, Рәшидә биргән кыюлыкны, ышанычны тотып алып, ир кеше борыла, үз юлына чыга: "Әйдә, миннән бер изгелек булсын! Эш белән йөриләр ич, мескеннәр!.. Һәм аңарда кинәт гаҗәеп бер энергия, кыюлык уянган кебек булды.". Димәк, кеше үзенә салынган көч, энергия, кыюлыкны изгелек юлына чыккач таба.

Хикәяләүче Зөфәр күңелендә башкалар турында ихлас кайгырту хисе тудырган үзгәрешне пространство алышынуы белән дә тамгалый: "...Киң, буш урамнан салкын карны шыгырдатып атлый-атлый, Зөфәр вокзалда көтеп калган артистлар турында уйлап барды". Ир әлегә аларның "җыр кайгысы" белән йөрүләрен бәяли алмый, укучы төп герой хакында ашыгып нәтиҗә ясарга тиеш түгел. "Сыкрау-сыктануны" белмәгән кешеләрне аңлавы – изгелекнең башы. Димәк, изгелек үзең кебек түгелләрне аңлаудан башлана, ди автор.

Иң үкенечлесе – юлга чыкканда ике ат таба алган Зөфәр гадәтләнгән яшәеш тәртибен үзгәртә алмаячак, борылачак. Повесть үзләрендә изгелек юлына чыгарлык көч тапканнан соң аңардан аңлы рәвештә баш тартканнарның фаҗигасе турында. Хикәяләүче сөйләмне шул дулкынга көйли. "Берсе җиңел кошевка, икенчесе киң үрәчәле чана" ирне яңа хисләр дөньясына алып бара. Артлы чанада ул Рәшидә янында шул чынбарлык тудырган җылылыкка сихерләнеп, аны югалтмас өчен бар көчен куеп тырышып бара ("аның өчен борчылып, әледән-әле башын сузып, алга карый"). Укучы төш эчтәлегенә кертелгән күл образына бәйле таныш текстны укый: "Бик якын, янәшә генә бит!.. Бу тою аңа тансык, рәхәт, ул аны гүя эчтән җылыта һәм

кызга отыры якынайта кебек...”. Ләкин аңын томалаган курку хисе күңелен “җилбегәй ачып җибәрергә” мөмкинлек калдырмый (көне буе “валчык та капмаган” артистларга “валчыгы да калмаячак” дип чемоданындагы ризыгын чыгармый), әлеге хис ирне гел сыный, богауда тота – “астыртын суык битне-борынны өшетеп ташлар дип курка”.

Зөфәр торган саен үз итәчәк чынбарлыктагы күңел җылысын автор детальләп тасвирлый (кунакларны каршы алырга тәрәзәсе сап-сары Гыйззәт картларның йорты, кара-каршы салынган өйләр).

Өченче бүлек Зөфәрдәге хисләрнең гомумәһәмиятлелеген раслап килү өчен аерып куела. Пространство бирелешенә (“клуб дигәннәре урамга кырынрак утырган, манарасы киселгән иске мәчет бинасы”) автор яшәп килүче идеологиянең Зөфәрләр фаҗигасе өчен җаваплылыгы эчтәлеген сала, проблема иҗтимагый яссылыкка күчерелә.

Гыйззәт картның болдырлы өе белән чагыштырмача бирелгән болдырсыз клуб ике дөнья – күңелендә бабаларыбыздан килгән җылылык хисен йөртүче кайгыртучан кешеләр һәм саксыз кагылып юкка чыгарырга әзер торган миһербансыз чынбарлык бирелеше кебек укыла. Күңелләрдә сакланган җылы шулкадәр көчле ки, иң рәхимсез чынбарлык та аны сүндерә алмый – “бозланып катткан кечкенә тәрәзәләрдә зәгыйфь яктылык, сары тап булып, тонык кына чагыла”, “түрдәге тәбәнәк кенә сәхнәнең нәкъ алдында бердәнбер асылмалы калай лампа яна”. Шул яктылык берләштерә, хәсрәтне киметә, шатлыкны зур итә, тормышны гамьле итә. Кешеләрнең артист чыгыш ясаганнан соң кул чапмаулары шул гамьне тою белән бәйле. Авыл көе тексты – кешеләр өчен уртак булган хәсрәт хисе бирелеше. Әлеге чынбарлык белән килешергә теләмәгән, ләкин килешергә мәҗбүр һәм яшәү тәртибен җайга салырга омтылганнар хәсрәте гомумәһәмиятлелек төсен ала: “Җыр бетте. Караңгыда утырган халык бер мизгел тып-тын булып торды. Әйтерсең алар хыяллары белән бу иске мәчет эченнән бик еракка иң кадерле якыннарын, өметләрен, бәхетләрен эзләп киткәннәр иде. Һәм гүя әнә шул ерактагы фронтның карлы далаларына, бозлы сазлыкларына, кара урманнарына барып тапкан, кавышкан газиз якыннарыннан аерыла алмыйча, кире бу салкын ялгызлыкка кайтырга кодрәтләре җитмичә утыралар иде. ...Әйе, мондый хәлдә ду килеп кул чабу мөмкин дә түгел иде”.

Җыр текстының эчтәлеге төрле халык биюләре деталендә кабатлана. Автор бу хиснең барлык кешеләр өчен уртак булуына басым ясый. Шул рәвешле фәлсәфи проблеманы иҗтимагый мотивлаштыра.

Текстта Зөфәр хисләре укучыны сәхнәгә Рәшидә алып менәчәк серне кабул итәргә әзерли. Хикәяләүче укучыга әлеге "караңгы, салкын" дөньяны оныттырырлык матурлыкны көттереп кенә, ләкин бик җентекләп "күзләрен аера алмаслык" итеп тәкъдим итә. Зөфәрне "хисләр чагылышының" кызның һәрбер хәрәкәтендә сизелүе гаҗәпкә калдыра. Автор Рәшидәдәге матурлыкны татар кешесенең күңелендә сакланган серле моң белән бәйли. Кыз башлап татар халык көе "Тәфтиләү"не башкара, гүя кешедәге илаһи матурлыкның аһәңен – башлангычын эзли: "Рәшидәнең күзләре берьюлы уйчанланып, ничектер эчкәре киткәне кебек булды, йөзенә моңсу җитдилек чыкты – һәм менә һичкемне, һичнәрсәне күрмәс булып, саф, нечкә тавыш белән җырларга тотынды... ...Бу көйнең моңын һәм бу сүзләрнең мәгънәсен телдән генә әйтеп биреп бетерерлек түгел иде. Бу көйгә, бу сүзләргә бөтен бер зур халыкның гүя барлык йөрәк зары, саф вөҗданы, ачы нужасы, авыр хезмәте, кара бәхете, якты өмете, кырлары-яланнары, таулары-урманнары, күлләре-сулары, сандугач-былбыллары, караңгы көзләре, язгы таңнары – барысы-барысы бергә җыелган, бергә үрелгән, бер киң дәрьяга әверелеп ага да ага иде...". Укучы ихтыярсыздан шул көйне ишетә, "дөнья читлегеннән каядыр бик биеккә, бик еракка оча" кебек. "Гади елау түгел" дип бирелгән күз яшьләре "яшәешне камилләштерергә ихлас омтылыш символы" кебек укыла: "... бу күңелләр төбеннән күтәрелгән бик изге, бик кадерле олы бер хиснең саф чишмәдәй саркып чыгуы иде". Димәк, автор татар кешенең иң изге, матур, серле моңы – яшәешне камилләштерергә, яшәү тәртибен җайга салырга омтылышы ул, дигән хакыйкатьне үзең аша үткәрергә чакыра. Авторның, хикәяләүченең, Зөфәрнең һәм укучының "күңелләре ни белән тулганын бик ачык әйтеп" була. Күңеле ачылган – моң серенә төшенгән кеше "рухлана, дәртләнә", "тавышы көчәя, иркенәя" дип кабатлый автор Рәшидә җырлары аша соңрак.

Әлегә кыз башкарган икенче җыр Зөфәрне (укучыны) дулкынландырырга тиешле хис – "соңгы вакытларда халык арасына таралган һәм бик тиз арада күңелләрне биләп алган" юксыну турында. "Юксыну" җыры аша бирелгән потенциаль эчтәлекне Зөфәрләрнең үз рухларын юксынуы кебек кабул итү дөрес булмас микән? "Вакытның

рухын, кешенең күңеленә тулганын әйтеп бирә белгән җыр” дип автор бәясе килеп керү дә шуны раслый кебек. Зөфәрнең хисләрен тасвирлау асылда имплицит укучыга мөрәҗәгать ителгән текст кебек укыла: “Хәтта Зөфәрне дә бу җыр тетрәтмичә калдыра алмады. Дөрес, аның юксыныр кешесе юк иде, сугыш китергән михнәт-газап аның күңеленә авыр таш булып ятмаган иде, әмма шулай да янындагы кешеләрнең тирән кичерешләре аңа да күчте булса кирәк – берара бугазы төбенә каты төер килеп тыгылды”. Башкаларны тетрәткән әлеге хис һәркемнең аң төпкелендә яши, тик аны башка хис тыйган: “Ләкин бу төерне ничек тә йотарга тырышты” .

“Иң соңгы җырны аеруча бер ялкынлану белән башын артка чөя биреп, кулларын җәеп, аяк очына күтәрелә төшеп җырлап бетергән” Рәшидә кичерешләре әлеге хисләрнең укучы күңеленә һичшиксез кереп урнашачагына авторның ышанычы кебек укыла. Зөфәр хисләренә төреп, автор кешегә салынган гаҗәеп рухи көчнең ачылуы турында, шул көчне тоюдан туган шатлык, җаваплылык хакында сөйли: “Халык гүя ач булуын, ялангач булуын, нинди авыр михнәттә яшәвен тәмам онытты; елады, көлде ул, һәм иң гаҗәбе – тирән рухи бер канәгатьләнү алып, гүя эчләренә тагы да зур бер сабырлык, чыдамлык, батырлык җыеп таралды ул”. Табигать тарафыннан идеаль чынбарлык кору өчен салынган көчне тою кешене бәхетле итә – гармониягә якынайта, ди автор: “Чалт аяз күктә түп-түгәрәк һәм ап-ак тулган ай тора. Шундый якты-якын ул – өстендәге әлеге көянтә-чиләкле кызны хәтерләткән күксел шәүләсе ап-ачык күренә һәм, бик теләгәндә, шуңа ничектер менә барып җитеп булыр иде кебек тоела... Шыгырдап торган коры салкын... Авыл өсте зәңгәрсу-якты... Чатнап бүрәнә шартлаганны ишетеп кала... Салкын тешкә тия, өскә сылана, әмма эчкәре үтәргә бик ашыкмый кебек... Атлавы җиңел, аяклар үзләреннән-үзләре йөгерергә тотыналар”.

Гармониягә омтылыш кешене тормышны ярату юлына алып чыга. Хәсрәте-михнәтенә карамый кеше үзенә бүләк ителгән гомерне кадерли башлый. Идеаль чынбарлыкны кору өчен тормышны ярату кирәк, ди автор Яруллин теле белән: “Халыкта тормышка мәхәббәт бик зур, менә аның сере нәрсәдә...”.Текстта автор фикере Рәшидә исеменнән җөпләнә: “...нинди генә җырны алма, ул барысыннан да бигрәк кеше күңелендә тормышка мәхәббәт уята, кешедә яшисе килү теләген көчәйтә...” Табын артында әйтелгән тормышны ярату гына хәсрәт-михнәтне кичкәндә юаныч була ала дигән әлеге хакыйкатьне

Мәликә әби раслап куя: “Авыл кешесенең юанычы ни шул җыру инде, белеп сөйлисез”. Үз тормышын хикәя иткән гомер кичкән карчык исеменнән “тормышның үзе кебек чын, гади” киңәше дә билгеләнеп куела: “ Көн итү авырга булса да, барына шөкер итеп торабыз әле, мондый чакта зарлану язык булыр, нишлисең инде!” .

Биредә хикәяләүче-укучы, автор-укучы бер дулкынга көйләнә. Рәшидә чынбарлыгы белән Зөфәр чынбарлыгы арасында аерма югала, ике матурлык бер-берсен тулыландыра. Кавышу мизгеле – шул матурлыкны тоюдан туган омтылыш, якынаю түгелме? Һич югында, үзеңдәге матурлыкны башка берәүдә күреп, рухи игезәгеңне табу мизгеле ул. Автор бу сүзләрне Рәшидәдән әйттерә: “Мин гүя кеше таптым, кешегә сокландым, шул кешенең үзе, җылы-йомшак мөнәсәбәте миңа тансык иде, миңа кадерле иде...” Ләкин түгел икән. Рәшидәнең күз яшьләре ялгышуы – камиллеккә омтылып та, берара кешелек горурлыгы өчен җаваплылык хисен югалтканга көчсез хәлдә калуы турында сөйли: “Кинәт үземне кызганудан күземә яшьләр килде, һәм йөрәгемә авыр бер төер утырып калды”. Чөнки, ни кызганыч, Зөфәр бары Рәшидә янында гына беренче һәм соңгы тапкыр илаһи башлангычына якыная: “...бүтән бервакытта да татырга туры килмәгән, бары чын матурлыктан, якты уйлардан гына килергә мөмкин булган аеруча тирән, олы бер бәхет кичергән кебек тә була иде ул...” Ирен югалткан, ачлы-туклы яшәү михнәтен өстендә тойган, ләкин матурлыкның үзе булып гомер итүче Рәшидәнең сынау алдында калачагын сизү тагын да кызганыч (алар аңлашып саубуллашкан көн “кояшлы, коры салкын көн иде”). Рәшидә чынбарлыгы өчен җаваплы Зөфәр чигенәчәк, кыз тормышта артлы чана булып торган ышаныч хисен югалту ноктасына җитәчәк. Укучы биредә тагын күл образына салынган эчтәлекне укый.

Алдагы бүлек Зөфәрнең үзенең искергән-тузган тормыш-яшәеш кануннарын үзгәртергә теләп башка йорт алырга исәпләп йөрүе – үзгә чынбарлык-кичерешләр эзләве турында сөйләү белән башланып китә. “Ниндидер бик вак купецтан калган”, “нигез өстендәге бүрәнәләре черегән” Сабитовларның Суконныйдагы йорты – Зөфәрнең исәп-хисапка корылган чынбарлыгыннан китәргә омтылышы сурәте. Зөфәрнең эчке кичерешләре хикәяләүче сөйләменә күчерелә. Ул сайлаган яңа чынбарлык “борынгы өяз шәһәрендәге шикелле аулак, тын һәм тыныч”. Төп герой әлеге “билгесез-ят, шуңа күрә дә тансык-мавыктыргыч матур бер тормышны” күргәндә “көнчелек, уфтану аша

гаҗәп бер ләззәтләнү хис иткәндәй була”, чөнки “заманында бу урамнарда зур чиновниклар, бай интеллигентлар һәм шәһәрдә кыш уздыручы помещик-дворяннар торганнар. Гайсә карт сайлаган йорт сурәте Зөфәрнең гармониягә омтылышын тулаем гәүдәләндерә. Зөфәр Илаһи башлангычын сизә-тоя (“тәрәзәләре дә зур, якты, эче дә бик иркен”). Татар иренең аң төпкелендә язылган тыйнак-горур, заман шаукымына буйсынмас асылы ачылырга тиеш, Зөфәрнең эчке омтылышы әнә шул: “...Күптән салынган булуына карамастан, ул, нәкъ яңа йортлардай, ничектер балкып, горур кыяфәт саклап, бик төз, туры утыра. Аннары йорт художество элементларыннан да мәхрүм түгел икән: кәрниз буйлары, тәрәшзә башлары, артык чуарланмыйча гына, челтәр өлге белән бизәлгән, ә болдыр баганалары нечкә билләп, гөмбәз чыгарып эшләнгән – болар һәммәсе дә йортка тыйнак бер нәфислек биреп тора...” Шул горур-буйсынмас холыкны саклаган хәлдә һәр буын яшәеш кагыйдәләренең замана шаукымы белән үзгәрә башлаган хасиятенә төзәтү кертә, Зөфәр аң төпкелендә моңа да әзер: “Аннары вакытында бик таза эшләнгән капка-койма да хәзер шактый тузган инде; капкасы бөтенләй артка таба авышып тора. Димәк, болар барысы да яңартуны сорый” . Йорт янәшәсендәге бакча – Зөфәрнең “күптән хыял иткән” мохите. “Балачактан ук табигатьне, үсемлекләрне белмичә үскән” Зөфәргә бакчаның “бик тансык, бик кадерле” булуын белү укучыда иргә карата ихтирам, ышаныч уята: “Һәм менә хәзер өйнең үзеннән дә ямьлерәк, кадерлерәк төсле булып аның алдында карт бакча күкрәп тора”. Традицион символик укылышта Космос (тәртип) үзәге бакча – татар кешесенең гасырлардан килгән яшәү тәртибе – Зөфәр омтылган чынбарлыкның аталышы. Үз асылын табуга якынлашкан Зөфәр күңелендә буталган кичерешләр өермәсен тәртипкә кертергә әзер, ярдәмгә “чын бакчачы” – тәртип булдыручы гына кирәк: “Ләкин Зөфәр моны белми иде әле... Ул бары карт бакчаның шигърияген генә күрде”. Автор проблеманы иҗтимагый мотивлаштыра, Зөфәрнең үз асылына кайта алмаячагында яшәп килүче системаны да гаепли: “Шушы искергән, картайган, ташландык хәлгә килгән тын бакчадан аңа ничектер борынгы дворян интеллигентының инде мәңге кире кайтмас тормышы аңкыгандай булды. Беркадәр моңсу сагыш белән шул тормышның югалуын кызганып куйды”. Ләкин кеше үзе теләп кенә үз асылыннан китә, бары курку хисен яшәү тәртибе иткәннәр өчен генә замана үзгәрү – әхлак алышыну ул, дип кабатлый Ә.Еники.

Зөфәрнең тормышын тәртипкә салырлык Рәшидә, ни кызганыч, ир өчен рәшә генә, ди автор: "Тип-тигез дала түрендә менә бервакытны ялтырап яткан күл ачыла. Чын күл бу, хәтта җем-җем уйнаклаган вак дулкыннарына кадәр күренә. Менә шуңа карап барасың, барасың, ләкин барып җитә алмыйсың. Чөнки ул юк, ул рәшә генә, коры далада алдап-котыртып уйнаклаган эссе шәүлә генә". Ирнең үзендәге кыз бүләк иткән хисне түгел, кызның ни дәрәҗәдә "ышанычлы" булуын сынавы укучыда ямьсез хисләр уята. Маркизет күлмәклекне кабул итмәгән кызның яшәү тәртибен, Зөфәр сүзләренә кушылып, автор хакыйкать буларак яңгырата: "Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сыныкны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар – шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!" Кешелек горурлыгы – үзеңә салынган көчне юкка исраф итмичә, вакланмыйча яши белү. Иң мөһиме – ахырда үзеңне кызганырлырлык булмасын. Хикәяләүче Зөфәрнең ваклыгын аның янәшәсендә яшәгән "үз кадерен, үз дәрәҗәсен бик белә торган горур-һавалы" "әйттем-бетте" Хәмит Рәшидәдәге матурлыкны билгеләү кебек бәяли: "Ул синең токмач белән йокыдан башканы белмәгән тормышыңа шатлык, матурлык, җыр, музыка алып керер иде" .

Алдагы Зөфәр-Ушаков, Сабитов-Симаков вакыйгаларында ирнең горурлыкны ялган юлы белән әйләнеп үтүе тасвирлана. Кыйммәтле мебель шыплап тутырылган пространствода Рәшидә матурлыгы чынлап та рәшә генә. Зөфәргә Рәшидә әйткән сүзләр шул турыда: " син вәгъдә иткән бәхетле тормыш ул минем өчен далада уйнаклап югалган кайнар рәшәгә әйләнер иде" Зөфәр табынган чынбарлык – "кешенең нигезсез, булмас өмете", ди автор һәм, төш эчтәлеген дәвам итеп, исәп-хисапка корылган тормышны, аңарга ачулы Сабитовны бәяли. Кешелек горурлыгын әйләнеп үткәннәргә – яшәеш тәртибен курку хисенә көйләгәннәргә тормыш-яшәеш төзәлү мөмкинлеге бирми, ди Ә.Еники.

***А.Гыйләҗев "Өч аршын җир" (октябрь-ноябрь, 1962)*** повестенда курку хисен тормышка, кешеләргә, сөйгән ярга мәхәббәтне тану гына җиңә ала, дип раслый.

Әсәр тексты поезд детален тәкъдим итү белән башлана. Символик укылышта язмыш, тәкъдир, үсеш мәгънәсендә килгән әлеге образ текстта хәрәкәтнең башлангычын белдереп килүче буларак төгәлләшә. Поездның Ерак Көнчыгыштан килүче, унсигезенче номерлы дип

тәкъдим ителүе дә эчтәлеккә кереп урнаша. Хәрәкәт әлеге поездның дүртенче вагонында бара: “Ерак Көнчыгыштан килүче унсигезенче номерлы поездның дүртенче вагонында ниндидер хәвефле, мөшкел хәл булуын пассажирлар барысы берьюлы белделәр”. Дүрт саны бөтенлекне, камил ритмны, гаделлек Алласын белдереп килеп, төп герой тормышының бөтен, камил оештырылачагын, гаделлек юнәлешенә борылганлыгын хәбәр итә. Әлеге юнәлешне – башка берәүгә ярдәм кирәклекне поезд радисты “хәбәр итә”: “... гомере буе саргайган кәгазьләрдән кагыйдәләр, боерыклар ише чит кеше сүзләрен укып, үзе әйткәнне үзе ишетмәс хәлгә килгән радист, ниһаять, бер тапкыр кешелекле һәм тормышчан нәрсә турында сөйләвенә шатланып, хәбәрне аерым бер тантана белән, һәрбер сүзенә сөенечле басым ясап әйтеп салган иде”. Әсәрдә төп каршылык булып торган чит/үз бинар оппозициясе радист сүзләренә бәйле кертелә. Шул рәвешле, әсәрдә “бәйрәмчә тавышы шөбһәле сүзләргә ятышмаган” каршылыклы хис-кичерешләр турында барачак. “Кешелекле һәм тормышчан” хисләр кешене үзгә юлга алып чыга (“аның тавышы шөбһәгә әйләнде”), дөрес юлга көйли. Радистның оппозицияне үтү юлы “медицинага берәр төрле мөнәсәбәте бар булган кешене” ашыктыру ” белән башлана.

Пассажирлар образларының үз-үзен тотышлары хәбәр ителү төп геройның шәхесе һәм аның тормышка карашын символлаштыра. Пассажирларны билгеле бер кичерешләр дулкынына радист көйли. Кешеләрне аптырашта калдырган “тантаналы” хәбәр (“кешеләр берни дә аңламый калдылар” ) шөбһәле тавыш белән кабатланганнан соң кызыксыну уята: “Купе, коридорларда гәп кузгалды: барысы да мәж килделәр”. Кешеләрнең сөйләшүендә аерып куелган прокурор һәм табиб кешелеклелеккә мөнәсәбәт кебек тамгалана:

“ – Сезнең теге озын, кәпрәйгән кешегез врач түгелме соң?

– Түгел лә, прокурор гына бит ул!.”

Врач (башкаларга ярдәм итүче) һәм “озын, кәпрәйгән прокурор гына” (тикшерүче, башкаларга гаеп салучы) булган кешеләргә мөнәсәбәт автор карашының белдерелеше кебек укыла: “Хәвефле сүз, чытырдап янган камыл кебек, җиңел генә сикерә-сикерә дүртенче вагоннан чыгып китеп, йөкле хатынга, прокурорларга, юлда очраган төрле маҗараларга күчте”. Димәк, яшәеш “юлында очраган төрле маҗаралар”да үз-үзеңне тоту тормышка карашыңның нинди булуына бәйле.

Сүзне тормышка табиб күзлегеннән караучы кешенең дәвам итүе –авторның укучыны яңарырга – үзгәрергә тиешле чынбарлыкка алып керү омтылышы: “Медицинага мөнәсәбәте булган” бердәнбер кеше, шактый өлкән яшьләрдәге фельдшер хатын, поездның нәкъ койрыгында – унөченче вагонда Сочига бер айлык ялга китеп бара иде”. Борынгыларда уникe саны050 бербөтенне аңлатып килә, унөч саны яңа циклның башлангычы – үлем символы кебек укыла. Шул ук вакытта унөч саны яңару эчтәлеген дә аңлата. Табибә ханымның карашы символик укылышта табигатьнең яңаруы, ел фасылларының алышынуы кебек аңланган “тәрәзә артында тезелешеп калган яшь, купшы наратларга” юнәлтелүе бу эчтәлекне көчәйтә. Авторның укучыда табибә образына ихтирам тәрбияләве аңа ханым дип эндәшүдә үк башлана, ханымның үз гамәленә мөнәсәбәтен һәрбер хәрәкәтен бөртекләп тасвирлау аша дәвам иттерелә. Хәбәрне ишетүгә ярдәмгә ашыккан табибә (“ханым аякларын төреп утырган җәймәне шактый җитез бер якка алып ташлады, җәлт итеп идәнгә сикереп төште”) аның җылысына мохтаҗ кеше белән очрашуга кабаланмыйча сак кына әзерләнә (“элгечтән ап-ак яулыгын алып бәйләде, көзгегә күз салды, ашыкмыйча гына изүен рәтләде”). Тормыш юлына атлаган кызның омтылышы аша автор үз карашын әйтеп бирә, табибә образында кешелеклелек идеалын тасвирлавын һәм башкаларның мондый кешеләргә карашын белдерә: “Урта мәктәп бетереп, Казанга укырга керергә баручы кыз бик кызыксынып һәм сокланып аңа иярмәкче булган иде, юлдашлары аны туктаттылар”.

Шул урында әсәргә “кыен чакларда да үзеннән түбәннәргә аны-моны сиздермәскә күнеккән” поезд бригадиры образы килеп керә, автор аңа төп герой Мирвәли образын алып керүне йөкли – ул иргә сүз ката. Символик укылышта бригадир (контролер) гаделлек булдыручы, күңел тынычлыгын тәэмин итүче кебек аңлана. Шәмсегаянны төшереп калдырырырга күндерү вакыйгасында бригадирның бу ир алдында физик көчсезлеге әйтелә (“буйлары бер чама булса да, бригадир бу сәер кеше янында чебештәй зәгыйфь, көчсез кеше икәнлеген тойды”). Ләкин “нык тәнле, каты куллы” Мирвәлине гаделлек ягына алып чыгу бурычы әлеге персонажга йөкләнә.

Шунда ук коткы таратучы, мәгънәсез киеренкелек тудыручы проводник образы җәмгыятьтә куркып-куркытып, ярашып-буйсындырып, яла ягып көн итәргә күнекккән радист, пассажирлар

образларын кабатлый: “Барыннан да бигрәк дүртенче вагон проводнигы – туп кебек түгәрәк юан хатын кызган иде” .

Автор әсәргә “туры юлдагыларның әмир-хөкемдарын” ир дип олылып кертеп җибәрә. Шул рәвешле Мирвәлигә алдан ук сак карарга – аның гамәлләрен кабаланмыйча бәяләргә чакыра кебек. Хикәяләүче аның исемен укучыга ихтирам белән җиткерә: “Ирнең исеме Мирвәли иде”, бригадирның аның белән сөйләшергә теләве укучы өчен юлын югалтканнарга мөнәсәбәт өлгесе булып тора. Повестьның мифопоэтик структурасын Чура батыр дастаны белән бәйләп өйрәнгән галимә М.Хабутдинова хаклы: “А.Гыйләҗев әхлакый нигезләр какшый башлауның тамырларын геройның характерына, ул яшәгән дәвердәге вакыйгаларга түгел, ә халыкның иреге, мөстәкыйльлеге юкка чыгарылган 1552 елгы вакыйгаларга бәйли. Герой язмышын автор Мәңгелек контекстына куя” .

Мирвәлинең башкаларга нәфрәтле, ачулы булуы, читләшүе (“җыелганнарның чыр-чуын зәһәр мыскыллау белән иреннәрен чалышайтып тыңлый, артык якын килеп кычкыра башласалар, сул кулы белән колагын томалый иде”) – асылда аның дөреслек эзләве, кимсенеп яшәргә теләмәве ул. Автор табибә ханым, бригадир, Шәмсегаян, яшь Мирвәли образлары ярдәмендә кимсенергә гадәтләнгән, ләкин һич тә алай яшәргә теләмәгән үзең кебек кешеләр арасында алардан читләшү мәгънәсезлек, киресенчә, бер-береңә сак, игътибарлы булу тиешрәк дип гел кабатлап тора. Мирвәли башкалар дөньясында үзен алдан ук чит позициягә куя, асылда гаепләүләрдән шулай саклана. Хатынына – үзе өчен күпмедер якын булган кешегә мөнәсәбәте бу читләшүнең никадәр көчле икәнлеген раслый: “Ул “хатыны” дигән кешегә борылып карады, аның куерып кушылган кашлары хәрәкәтләнделәр, аз гына бөдрәләнеп торган ап-ак чигә сакалларына ут капкан кебек сыек зәңгәр төтен белән капланды”. Билгеле, Мирвәлигә болай яшәү әлегә уңайлы, аны бу хәлдә дә үз итеп торучы кеше бар бит. Автор Шәмсегаянның Мирвәлине аңлавы, кабул итүе, сак кына үзгәртергә тырышуы белән укучысына түземлелек сорап эндәшә.

Шәмсегаянны әсәргә табибә ханым алып керә. Мирвәлигә мөрәҗәгать итеп, “кирәкле җавапны ала алмаслыгына төшенгән ханым көч белән ишекне тартып ачты” – автор укучысын “бер халәттән икенчесенә – үзгәргән яңа чынбарлыкка” шул рәвешле кертеп җибәрә. Әлеге чынбарлык сурәте – Шәмсегаянның портреты татар кешесенең

җуела башлаган асылы, үлемгә хөкем ителгән якты “кояшлы-шәмсегаянлы” әхлагы кебек укыла: “Аның чаларган юка чәчләре мендәр өстенә чәбәләнеп таралганнар”. Кешенең игелекле, якты ягын символлаштыручы чәч детале әсәр текстында кабатланып килә. “Шау-шулы, авыр һавалы купе”– тормыш-яшәеш татар кешесенең шәмсегаянлы ягын күптән какшаткан (“димәк, ул күптән авырый”), хәзер татарның якты ягы “дөнья өчен ачылырга тели” (“тәрәзәне ачасы иде”]), тик бүгенге яшәештә дә иркен сулыш алырга - ачылып китәргә мөмкинлек чамалы (“ачарлык түгел шул, паровозы бик әшәке төти”). Әйтергә кирәк, аның исеме соңрак әйтелә, автор проблемага гомумәһәмиятлелек өсти.

Әлеге иҗтимагый хәлдә – поездда кинәт “тормозга басу” да көткән нәтиҗәне бирмәячәк: “Кемдер тормозга бастымы, шәп кенә барган поезд бер секундка гына тартылып алды. Авыру һуштан язган иде. Тамыр “менә туктыйм, менә туктыйм” дигән кебек өзек-өзек кенә тибә иде”. Иң куркынычы – моннан соң нидер үзгәртергә теләү нәтиҗәле булмаячак (“Тәрәзәне ачтым, барыбер хушына килмәгән”). Бу иҗтимагый яшәештә “өске полкадан зур салам эшләпә генә идәнгә тәгәрәгән”) кебек әллә ни мәгънәгә ия түгел омтылыш, болай эшләү рухи киеренкелек тудырачак (“...бригадир аптырап калган тирә-яктагыларга карады, нидер әйтергә теләгәндәй, тәрәзәгә, тәрәзә артында бер-берсен кочаклашып авып калган агачларга ымлады”).

Шәмсегаянны “Кыек Урман” станциясендә калдырырга мәҗбүрилекне әйткән табибә ханым Мирвәлинең карышуын “кыргыйлык” дип бәяли. Кыргыйлык – “туры юл/кыек юл оппозициясен” үткәндә сайлаган юлның автор тарафыннан бәяләнүе. Кыек Урман тукталышына – билгеле бер юлның соңына килеп җитүен сизгән Мирвәли ихтыярсыз бәргәләнә, чөнки кыек бит, чынлап та бу юлны сайлау кыргыйлык булган ләбаса. Багаж – юлның соңына алып килгән тормыш итү рәвеше, тупланган тәҗрибә. “Күңел капкасын ачып, кешеләргә үзен күрсәтергә яратмый торган” Мирвәлине биредә туктарга мәҗбүрилек уңайсызлый – асылда үзе сайлаган юлның соңы аңа кирәксез: “Кемнәрдер Мирвәлинең багажын – ике дәү чемоданны, Шәмсегаянның сумкасын һәм зур гына төенне алып чыгып арбага куйдылар”. Мирвәлинең багажының дәү булуы – күңелендә йөрткән кирәкмәс йөк кебек укыла.

Мирвәли аң төпкеленнән килгән юлның соңы белән бәйле чарасызлык хисенә әзер түгел, аңы бу чынбарлык белән килешүне, аны

кабул итүне тыя: “Фельдшер исә Мирвәлигә әллә никадәр киңәшләр бирде. Аның сүзләре Мирвәлинең бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга торсалар да, ул ризалашкан төс белән ым кагып, башын селкеп торды”.

Символик укылышта хисләрне йөгәнләү, үзеңне кулга алу мәгънәсендә килгән ат образы (бу өлештә җирән бия) Мирвәлине яңа чынбарлыкка – үзгә рухи халәткә алып китә: “Поезд белән ат бер вакытта диярлек кузгалдылар, һәм күпмедер янәшә бардылар”. Хәрәкәтнең башлангыч халәтенә нокта куела (“менә поезд үтеп китте, соңгы тапкыр яңгыратып гудок бирде, үргә менеп сулга борылды”) “тимер юл буена киң тасма итеп каен катыш сәрви агачлары утыртылган чуар кишәрлек” – хәсрәт белән билгеләнгән рухи яңарыш юлы үтелде, алда ирне сызланулар, әрнү-сыкраулар көтә (“рельслар озак кына гүелдәп, сызланып тордылар”). Юл дәвамында ирнең хисләре, аларның нигезе бәян ителәчәк, Мирвәли шул хисләрне тәртипкә салу өчен үз-үзе белән очрашуга бара. “Кая кайтасың?” – бу сорауны ир үзенә беренче тапкыр куя.

“Әхлакый чистарыну кебек аңлашылучы рухи юл” башы итеп иң тәүдә арыш басуы – Мирвәлинең авылда яшәгәндәге рухи халәтен искә төшерер өчен сайлана: “Җирне кадерләп, төпченеп, юлга кадәр үк китереп чәчкәннәр. Кырга нык куллы кешеләр хуҗа икәне күренеп тора” . Мирвәлинең хәзерге халәте – “күзгә күренерлек хата эзләү”– элеккечә үз юлын акларга омтылыш кебек аңлана: “Тирән уелган куш эзләрне, вакытсыз саргайган, юкарган башакларны күреп Мирвәли вагондагы төсле итеп зәһәр генә көлемсерәде. Әһә!”. “Аксыл кашлы, кызыл киң битле, зур күзле авыл егете” [1:144] олаучы – бу өлештә автор карашын җиткерүче кебек тамгалана. Юлның тарлыгын – теләгәнчә яши алмауны сылтау иткән “көтеп торганчы таптап китүне кулай күргән” ярсу Мирвәлигә олаучы (автор сүзе) “киң урыннары да җитәрлек, юл сап” дип җавап бирә. Димәк, Мирвәли танырга теләмәгән яшәеш тәртибенең тәүгесе – түземлелек, үткәреп җибәрә белү, юл кую икән.

Автор биредә тавыш образын уйната башлый. Иң тәүдә укучысын бер мәлгә тын калырга – күңел төпкелендә урнашкан шул яшәеш тәртибе турында уйланырга чакыра: “Басуга кергәннән бирле Мирвәлинең колак төбендә бер чың тора иде. Озак кына интегеп баргач, үзенең тирә-ягында тынлык чыңлавын аңлады”. Кешене “тилмереп үзенә авазлар, шау-гөр эзләү” – шау-гөр эчендә онытылырга

теләү халәтеннән тын калып уйлану дөрес юлга чыгара, ди автор. Автор проблеманы иҗтимагый ("ыжгырып барган поезд" тавышы) һәм милли ("бик ерактан – тегеннән" килгән өн) мотивлаштыра.

Мирвәлине үз-үзен аклый алмавы берөзлексез борчып тора, гадәтләнгәнчә ир бу хистән качып котылмакчы ("Юл туп-туры, кыр тип-тигез иде. Әнә шул тигезлек, турылык Мирвәлинең теңкәсенә тиеп, ялыктырып , борчып тора иде").

Шәмсегаянның "рәхәт итеп, күкрәк тавышы белән көлеп җибәрүе" тургай тавышы белән янәшә куелып, символик укылышта Илаһияткә сөенеп мөрәҗәгать итү кебек шәрехләнә. Әлеге тавышны Мирвәлинең дә ишетүе – Илаһият юлына борылуы ул ("Сайрый икән, берәү генә түгел, икәү, өчәү, бик күп!.." Олаучы – автор бу хакыйкатьне раслап куя ("Тургайлар мыж"). Символик укылышта яшәеш хәрәкәте турындагы фикерне белдерүче арба тәгәрмәче шыгырдавы тавышы – Шәмсегаян теле белән Мирвәли күңелендә хис-хәрәкәт кузгалуны тамгалап кую ("Тимә, шыгырдасын!"). Тавыш образы аша аңланган эчтәлекне арыш исе детале ныгыта ("Сулавы ук рәхәт!"), назлылыкны белдерүче күккүзләр йомгаклап куя. Шул рәвешле, "сюжет нигезен кайту ситуациясе хасил итә"– Шәмсегаян ихтыяры белән олаучы-автор Мирвәлине сөенеп яши торган, иркен сулышлы, назлы дөньяга алып кайтып бара. Мирвәлинең күңеле бу чынбарлыкны ярата, үз итә, ләкин "колагы тонганлык" әлегә аңын тоткарлый. "Яргаланган кулларын аксыл кашлары өстенә куеп, ялгыз олаучы" (автор) шул "ят, чит ис тараткан" Мирвәли чынбарлыгына моңая.

Автор проблеманы фәлсәфи яссылыкка күчерә, Мирвәли образы яшәү/үлем оппозициясендә калдырыла. Тәгәрмәч шиннары ашарып шомарган аксыл машина – үлем, Шәмсегаян караган тәрәзәләр исә яшәүне символлаштыра. Үлем башкалар дөньясыннан аерылып китүне белдерсә (хатыннар комачауламас өчен тәрәзәләрен ныклап ябалар), яшәү – шул аерылып киткән мәлдә кешеләр күңелендә уелып калырга тиешле сурәт (Шәмсегянның әледән-әле тәрәзәләргә каравы). Автор шул хәрәкәтсез мизгелнең сурәтен тасвирлап, алда китерелгән тын калып уйлану детален кабатлый. Шул мизгелдә юанырлык җай тапмаган Мирвәли (тәмәкесе беткәненә ачулана) "бик таныш, бик тәмле" ис сизеп "күзләрен чытырдатып йома": "Тегеякта түтәл-түтәл итеп, бакча тутырып төн миләүшәләре утыртканнар иде. Кояштан оялып керфекләрен йома торган бу гаҗәеп чәчәкләр әле ачылып

бетмәгәннәр, лапас ягындагылары, күләгәгә эләгеп, шыпырт кына ачылып маташалар һәм үзләренең куе, тәмле исләрен таратып та өлгергәннәр”. Миләүшә-гөл, миләүшә-бала образы  Мирвәли белән бәйле рәвештә символик укылышта бакчада, күлдә үсеп утыручы чәчәк образы мәгънәсенә – чынга ашкан эчке мөмкинлекләргә туры килә. Мирвәлидә тәүге тапкыр хатыны белән сөйләшү теләге уяна, ул үзенең чынга ашарга тиешле булган ягын тоеп сөенә дә, елый да, тик янына кергәч сүз таба алмый – “карый да ката”. Шәмсегаянга сүзе күнегелгән тормышка кайту белән бәйле. Мирвәлине куркытачак, уйга салачак хәл бер генә – Шәмсегаянның үлеме, автор вакыйгаларны шул якка бора, укучыга аның үләргә ятуын кабатлап, шулай булырга тиешлеген асызыклый: “Кинәт аның башына саллы имән күсәк белән суккан кебек булдылар, ул берьюлы исәнгерәп, миңгерәүләнеп калды: Шәмсегаян үлсә?!” Бу хәбәрне Мирвәлигә “чынаяк тәлинкәсе кебек зуп-зур күзле” кыз сиздерә, идән шыгыдаган тавыш хәвеф булачагын искәртә. Ярым караңгы, салкынча коридор, тар ишек, кечкенә бүлмә, бердәнбер караватъ, иңнәре тар, җиңнәре курач  ак халат Мирвәлинең үзе курыккан чынбарлыкка аяк атлавын белдерә.

Шәмсегаян шул урында яшь табибка сөйләгән кебек Мирвәлигә соңгы сүзен – васыятен әйтә, автор биредә җир, сабан тургае, Сабан туе образларын янәшә куеп укучысы белән сөйләшә: “Безнең халыкның боры-борыннан җир инде аның!.. Үзем дә яшь чагымда кыр эше өчен үлә идем!.. Яз җитсә, өйгә керәсе дә килми иде. Кыен бит үзе, авыр... Урак өстендә унсигезешәр көн оекны салырга вакыт булмый иде... Эштән кайтасың да авасың! Барыбер күңелле иде... Ул сабан уракларын әйтәсеңме?.. Юкка гына безнең бабайлар иң яраткан кошларын сабан тургае дип, иң кадерле, күңеле бәйрәмнәрен Сабан туе дип атамаганнар шул... Һай, күңелле үза торган иде шул Сабан туйлары!” Җир мифопоэтик укылышта  ана мәгънәсендә килә,  җир – яңадан туу, рухи үсеш – яңарыш, үз асылыңа кайтуны символлаштыра. Сабан туе – үзәк бәйрәм, танышу-кавышу, очрашу көне, күңелнең ачылган мәле. Васыять – яшәү/үлем чиген үткән бәхәссез хакыйкать. Шул рәвешле, кеше тормышының мәгънәсе – рухи камиллекә омтылу, гамәлләреңнен нигезен шул омтылыш белән үлчәү, үлем ноктасыннан бәяләү. А.Гыйләҗевның Шәмсегаяны шул васыятьне җиткерү вазифасын башкара. Мирвәли исә – үз асылына кайту юлына баскан татар ире-әмире. Мирвәли өч аршин җир сорап авылдашларына

мөрәҗәгать итә, ир үз асылына кайтырга теләп, кардәшләреннән таяныч сорый.

Мирвәлигә үләчәген Шәмсегаян үзе әйтә: “Сакалың бик җиткән, әйбәтләп кырын... Яшел чемоданда яңа чалбарың... Буй-буй күлмәгең белән шуны киярсең... Каткан өс белән йөрмә... Кумәчләр искергәндер инде... Читкә ташлама, синең андый гадәтсезлегең бар... Атлары бардыр әле... Үзең карарсың тагын...” Яшел чемодан – тормышның тыныч, көйле мәле, яңа чалбар – шул яшәештә урын алу, буй-буй күлмәк – туры-тигез холык кебек аңлана. Шәмсегаян үткәндәге ризык-тормышка ихтирамлы булырга, “читкә ташламаска” өнди, якыннарга – ярдәм итәрдәй кардәшләргә таянырга куша (“атлары бардыр әле”). Тормыш-яшәештә кешене тыныч-сабыр холкы, башкаларга ихтирамлы карашы гына бәхетле итә. Автор “туган җир, тамырлар, нигез” турындагы хакыйкатьнең укучысы күңеленә барып ирешүенә өметләнә (Шәмсегаян Мирвәлидән авылдашларга үзе турында күп сөйләвен, ташка язган исеменең дә кеше күзенә күренеп торырлык булуын сорый, пәрдәне – яшерелгән хисләрне ачуны үтенә).

Мирвәли япа-ялгыз яңа дөньяга “канатлары талган карт бөркет” кебек өметләре киселгән, хисләре таралган ярым үле хәлдә аяк баса. Мифологик укылышта “теләсә кемгә баш бирмәс, кешеләрчә сөйләшә белә, үзенең хуҗасына акыллы киңәшләр бирә торган” Акбүз ат Мирвәлигә тапшырыла. Галәм сулышы – җил, илаһи башлангыч белдерелеше – төн миләүшәләре ярдәмендә автор укчысына Мирвәлинең юлын асылына кайту юлы кебек тамгалый (“Ишегалдын иңләп искән җил, миләүшә чәчәкләрен кочаклап, аларның хуш исләрен урамга таратырга чыга” ). Сипкелле битле малай, борчак чәчәге төшкән бизәкле күлмәк кигән кыз елавы капка төбендә – сынаулар алдында калган Мирвәли кичерәчәк хисләрне – ирнең үзен тапкач елаячагын алдан укырга ярдәм итә. Әлегә Мирвәлинең ялгышлары, эгоистлыгы (күләгә образы), аның киләчәкле булуына өметен томалый (ап-ак казлар детале ): “Ямь-яшел чирәмдә тезелешкән ап-ак казлар өстеннән Мирвәлинең дәү, кап-кара күләгәсе үтеп китә...”

А.Гыйләҗев алдан ук укучысын юлның тәмамы белән таныштыра. Мирвәли күңелендә иң элек бәхетле, бөтен булырга тиешле тормышка керергә кыймау-куркып тору югалачак ( “Иң элек урам-тыкрыклар ясап тигезле-тигезсез дә, аркылы-торкылы да сузылган киртә-корталар, башларына балчык чүлмәкләр, бала чүпрәкләре, иске ураклар эленгән, колмаклар сарылган читәннәр

күздән югалдылар”), аннары җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә тулысынча бәйлелек кимиячәк ( “аннан уңган кызыл флаг эленгән, муртайган такталы янгын каланчасы һәм эше юклыктан моңаеп, терсәкләре белән яңагына таянып торучы пожарник күренмәс булды”), иң соңыннан – курку беткәч үз асылың белән очрашу – илаһи башлангычыңны табу көтелә ( “иң соңыннан гына авылның төрле почмакларында – буа ярларында, күпер төпләрендә уйдык-уйдык утырган эре сөякле, юан кәүсәле тупыллар кичке дымсу рәшәгә уралып беттеләр”). Тупыл – дөнья үзәге, Күк һәм Җирне тоташтыручы, илаһи асылыңа омтылу кебек шәрехләнә. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина Мирвәли күңелендәге курку хисен “әйләнеп кайтудан курку һәм үз-үзеңнән курку” икәнлеген әйтә. Әсәрдә бик эзлекле рәвештә шул ике төрле курку хисенең янәшә баруы бирелә.

Мирвәли “кемдер, көчле рухлы берәүнең” “дерелдәп торган җанын” [1:162] борчуыннан курка. Тик ирдән “Кем син?” – дип сораучы юк. Димәк, Мирвәли үзе уйлап тапкан үзеннән көчлерәк башка берәүнең барлыгыннан курка. Автор илле сигез санының символик белдерелешенә Мирвәлидәге бу куркуның нигезен күрсәтә: “Бу сан күңелдәге бар уйларны, хисләрне кысрыклап чыгарды. Башын калкытты исә ул күз алдында уйнаган бишле һәм сигезле цифрларны гына күрде...” Символик укылышта бишле саны – Аллаһ һәм Галәм арасында торган кешене белдерә, бишле – кешенең физик асылы (биш хис, биш бармак, тәннең биш тигез өлешкә бүленүе). Сигезле – мисырлыларда космик тәртип саны, Кытайда дөнья корылышының нигезе һ.б., илаһи башлангычыңны табу өчен үз өстеңдә эшләүне дә символлаштыра. Димәк, күңелдәге курку хисен җиңү өчен кеше үзенең һәм физик, һәм рухи асылын җигәргә тиеш. Курку хисен җиңү – үзеңнең башкаларга охшамаган хасиятеңне табу, тәртипкә – гармониягә ирешү ул, ди автор.

Мирвәли образына салып А.Гыйләҗев кабаланмыйча курку хисе белән көрәшү юлын өйрәтә кебек. Иң элек бу хисне тану белән аның сәбәбе, башлангычы турында уйлану зарурлыгы туа: “Нигә артына борылып карарга шүрли соң ул? Кем сагалый аны?.. Нәрсә?.. Кайчан башланды соң бу курку?” Әтисе аны шайтани хистән куркырга өйрәтә – иң беренче булып нигез булырлык шул вакыйга искә төшерелә.

“Үз-үзе белән беренче тапкыр очрашудан курыккан” Мирвәли эчке рухи таянычына – Шәмсегаянга – үзенең шәмсегаянлы-кояшлы асылына эндәшә һәм “үз тавышын үзе танымый”.Биредә Мирвәли

икегә бүленә: Шәмсегаянны яратып, иң бәхетле хатын-кыз иткән ир һәм Шәмсегаянны иң бәхетсез итеп яшәткән исерек, азгын. Башкаларга “Мирвәлинең беркемнән дә курыкмавынрасларга ашыккан ирдә бу хиснең оялавы гайре табигый кебек (өйләнүе, өеннән чыгып китүе, Таифә йортын тәртипкә китереп яшәп китүләре). Бу вакыта автор Мирвәли белән Шәмсегаянның тулы гармониядә яшәүләрен – бернидән курыкмыйча матур гамәлләр кылып яшәүләрен тасвирлый: “Иң элек карчыкның өен сипләделәр. Чуал буеннанбәрмәнчекле тал чыбыгы ташып өйалды үрделәр, аны кызыл балчык сылап җылыттылыр” .Бу истәлекләр куркудан өстен чынбарлык, чөнки аларда башка хис – якты мәхәббәт хисе яши. Шул рәвешле автор бередә кешенең рухын җимерә алырлык көчкә – курку хисенә каршы торырлык икенче бер хисне – мәхәббәтне кеше табынырга тиешле кәгъбә дип раслап куя. Сөю хисе – “Карачураның иң сылу кызы, авыл егетләренең генә түгел, тирә-як егетләренең дә күңелләрен тартып торган кәгъбә” Шәмсегаян күңеленең илаһилыгы. Яраткан кеше сөйгәнен үзе артыннан илаһи чынбарлыкка дәшә (Өч кое янында ал читле яулык бирүе), “чит дөньядан саклый” (шәлен бирү вакыйгасы), “һәрвакыт бердәй ягымлы, кече күңелле, мөлаем гына елмаеп, сабыр гына көтеп тора”.

Мирвәлине чит чынбарлыкка алып кергән “шайтани тәкәбберлек һәм женләнеп акылдан язу” аның тегермәнгә эшкә урнашуы вакыйгасында да кабатлана (символик укылышта тегермән – шайтани башлангыч). Мәхәббәттән баш тарту кешенең шайтани хасиятен ача (тегермәнгә кемлеге белән кызыксынучы булмаганга урнаша), шул ук вакытта мәхәббәт – иң олы көч – һәрвакыт барлыгын сиздереп, ымсындырып торучы чынбарлык торучы : “Кыр исе килә иде бодайдан! Ындыр исе! Арбалар исе, ат исе!.. Көлтәләр, иген тузаны исе, көзге келәтләр исе аңкый иде аннан”. Мәхәббәт хисен искә төшерү Мирвәлинең “сагыш тәбесендә тыпырчынган йөрәгеен парә-парә телә”– иманга китерә. Курку хисен иманга килү – тормышка, кешеләргә, сөйгән ярга мәхәббәтне тану гына җиңә ала, ди автор. Әтисе өйрәтеп калдырган хакыйкать шул икән (шунда Мирвәли шайтан җылысын куа, Шәмсегаян җырын-хисен искә төшереп беренче мәртәбә үрсәләнеп елый, сугышка алынмавына үкенә). Мирвәли өчен туган яңа көн – яңа хисләр Шәмсегаянның Карачура турында әйткәннәрен искә төшерү белән бәйле. Мирвәли һәм Шәмсегаян исеменнән автор аларның утыз еллык тормышын сукбайлыкта үткән гомер буларак

бәяләтә. “Кеше күңеленең йомшак, әйбәт яртысында калу” (Шәмсегаян) “бер мәртәбә “кода” дип әйттерер өчен дөнья малын, дуңгыз канын бирергә әзер Мирвәли” – әшәке сукбайлык халәтеннән коткаручы хакыйкать. Димәк, туган җирдән, якын кешеләреннән баш тарткан, югалган кеше – сукбай гомере буе шул җылылыкны эзләп тилмерә икән. Алар сукбайлыкка юл алган төнне “япан кыр уртасында, буран эчендә баш очында” калыккан Җидегән йолдыз – Җирнең үзәге, көч чыганагы турында искәртә . Мирвәлинең куркуын онытып Карачурага кайтып килергә ниятләве – югалткан көчне эзләү, игелекне явызлыктан аерырга омтылуы. (Мирвәли белән Шәмсегаянның аяк астындагы ак ташка карап торулары). Мирвәлинең рухи таянычны югалтып кайтып егылуы – аның Шәмсегаян белән бергә яшәгән гомеренең дәвамы – “әшәке сукбайлык”, дәвере, “яман шешле” чор. Урманда йомшак җирне казуы, кырмыскалар оясын кузгатуы, агач тамырларын тоюы – киресенчә, Мирвәлине үзендәге сукбайлык халәтеннән баш тартырга омтылыш – уйлану мәле. Уйлану аның куркуын тагын да көчәйтә, Мирвәли елый. Атның кузгалмавын – бер мәлгә тукталып торган хәрәкәтнең яңадан көч алып китәргә тиешлеге ул. Мирвәлине елаткан чынбарлык – аның кемлеген белешү. Димәк, кеше һәрвакыт бер-берсен булган җылылыкка сусап яши, ярату кеше күңелен баета, иркен сулышлы итә, ди А.Гыйләҗев. Автор җизни түгел, кода түгел – беркем түгел Мирвәлине “үз гаебенең зурлыгын миенә җиткерү өчен” тагын бер кат капка-сынау алдында калдыра. Хөкем сәгате – Мирвәлине тану сәгате якынлаша. Шул рәвешле, автор атын җибәргән Мирвәлигә үз асылыңны табу – өч аршин җиреңә лаек булу – синең Җир белән Күк арасындагы урыныңны тамгалау бары кешеләрне ярату көче белән генә чынга аша, ди.

XX гасырның 60 нчы елларындагы әлеге юнәлеш гасыр ахыры прозасында фәлсәфи катламлы текстларның катлаулы формаларын нигезли. З.Хәким, М.Кәбиров прозасында фәлсәфи шартлылык әлеге дәвердә тәкъдим ителгән милли яшәеш фәлсәфәсенең тәнкыйди башлангычына тоташа.

Әдәбият

1. Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2004.– Б.136-209.

2. Еники Ә. Әсәрләр. 5 томда. 2 том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – Б.269-446.

3. Жюльен Н. Словарь символов / Н.Жюльен.– Челябинск: Урал LTD, 1999.– 498 с.

4. Заһидуллина Д.Ф. Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. – Казан: Мәгариф, 2006.– 191 б.

5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева.– Казан: Мәгариф, 2005.– 111 б.

6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов.– Казан: Мәгариф, 2007.– 112 б.

7. Миңнуллин Ф. Намус эше / Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (Т.Галиуллин кереш сүзе).– Казан: Татар.кит.нәшр., 1994.– 231-243б.

8. Мустафин Р. “Плюсы” и “минусы” // Литературная газета.– 1964.– 21 января.

9. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А – Г) .– Казан: Мәгариф, 2008.– 303 б.

10. Фасеев К. Кояшлы язны рәшә капламасын // Социалистик Татарстан.– 1963. – 28 июль.

11. Фасеев К. Полемизировать без “приписок”! // “Литературная газета”.– 1964.– 2 апреля.

12. Хабутдинова М. Драгоценный камень А.Гилязова /Гилязов А.М. Повести: Три аршина земли; В пятницу, вечером. – Казань: Магариф, 2008. – С.233-258.

## ***XX гасырның 70-80 нче еллар татар прозасында милли яшәеш фәлсәфәсен тәкъдим иткән лирик-эмоциональ юнәлеш***

Әдәбият галиме Д.Ф.Заһидуллина үткән гасырның 60-80 нче елларында татар прозасында алга таба үзгәрешләргә китерәчәк стиль тенденцияләренннән бер юнәлеш буларак лирик-эмоциональ башлангычны аерып куя. Лирик-эмоциональ башлангыч, бер яктан,

әсәр тукымасында субъектив катламның зур урын били башлавын, икенче яктан, хикәяләүче яки автор образының, вакыйгаларны күзәтүче генә булып калмыйча, аларда катнашучы герой халәтенә күтәрелүен тәэмин итә. Әсәр чынбарлыгын сөйләүче-күрсәтүче генә түгел, ә бәлки шушы чынбарлыкка мөнәсәбәтен үсеш-үзгәрештә, хәрәкәттә сурәтләүче автор «мин»е, шуның тирәсенә тупланган лирик-субъектив катлам вакыйгалар (сюжет) катламыннан да зураеп китә, мозаика кебек чәчелгән вакыйга күренешләрне үз янына – бер үзәк тирәсенә туплый. Нәтиҗәдә әсәрдәге төп каһарман булган «мин»нең рухи дөньясы, аңы укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә ала. Әсәрнең иҗатчысы, язучы-автор белән янәшә әсәр тукымасында тагын бер автор образы пәйда була. Язучы-автор уңай герой ярдәмендә белдерергә мөмкин булган фикерләр, идеал нәкъ менә автор образы аша укучыга ирештерелә. Автор образы уңай геройга хас булырга мөмкин барлык сыйфатларга ия: вакыйгаларны, кешеләрнең эш- гамәлләрен бәяләүдә гадел, нечкә һәм саф күңелле, күзәтүчән, туган җирне туфракны яратучы, хезмәт кешесе, тормыштагы күңелсез моментларны авы кичерүче һ. б. шундый яклары белән укучы күз алдында бербөтен булып калка. М.Мәһдиев, Р.Төхфәтуллин, Ф.Хөсни, Ә.Баяновның аерым әсәрләрендә без шушы күренеш белән очрашабыз, ди галимә.

Татар тәнкыйте М.Мәһдиев-язучыны (1930-1995) үткәнен сагынучы, татар авылының тарихта калган кичәге көнен җырлаучы дип исемләде. Әдәбият тарихы фәне әдәби әсәрдә геройларның балачак хатирәләреннән алып хәзергенең үткен каршылыклы күренешләренә кадәрге язмышын хис һәм мөнәсәбәт тарихы кебек гәүдәләндергән, үткәндәге якты-бәхетле яшәү рәвешен хәтердә тергезү мотивларын импрессионистик алымнар баеткан әсәрләрне сентименталь реализм агымына нисбәтләде. “Торналар төшкән җирдә”, “Бәхилләшү” әсәрләрендә үткәндәге тормыш аерым кешеләр өчен бүгенгедән әһәмиятлерәк яссылыкка куела, лирик геройларның эчке дөньяларына заман үтеп керә, хис-мөнәсәбәтләр чор, иҗтимагый тәртипләр тәэсирендә хасил булалар, вакыт агыннан тәртипле оешканлык, ретроспекция алымы үткәндәге психологик вакытка алып китә.

***М.Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә” (1979, август-сентябрь)*** повестенда автор 1970 нче еллар ахыры әдәбияты өчен актуаль булган иҗтимагый проблемалар – татар авылының үткәне,

бүгенгесе, буыннар арасында бәйләнешләр өзелү, туган нигезне оныту кебек мәсьәләләрне алга ала. Көчле позициягә – повестьның исеменә, беренче эпиграф һәм кереш сүзгә вакытка бәйле бинар оппозиция чыгарыла. XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүче галимә Д.Заһидуллина вакытка бәйле бинар оппозицияләрнең үткән/бүгенге кебек ике чиккә аерылуы гомумиләштерүләргә омтылу тенденциясе белән бәйле булуын билгеләли: "Киңәю күренеше татар әдәбиятында вакытны аерым кеше гомеренә нисбәтле түгел, бәлки кешелекнең гадәти вәкиле булган шәхес тормышы һәм яшәеше кысаларында тергезү аша хасил була".

XX гасыр башының мәдәни, әдәби, милли тарихын өйрәнеп, иң кызыклы һәм иң кызганыч, гаҗәпләндерә һәм сөендерә алырлык сәхифәләрен татар укучысына җиткерә алган галим. М.Мәһдиев татар прозасының фәлсәфи канатына караган әсәрләреннән юнәлеш алган дип билгеләргә тулы нигез бар. Д.Заһидуллина күрсәтеп үткәнчә, "аның фәнни хезмәтләрендә үткәннәргә, яшәп киткән олы шәхесләргә, аларның бәяләп бетергесез эш-гамәлләренә соклану, шуларны бүгенге чынбарлыктан эзләп үкенү хисләре ярылып ята". Димәк, "үзе дә Тукай-Әмирханнар буынының бер вәкиле кебек тоелган" әдип әсәрләрендә XX гасыр башы әдәбиятындагы дөнья сурәтен – вакытны кешелекнең гадәти вәкиле булган шәхес тормышы һәм яшәеше кысаларында тергезү алымын үз итә, сюжет структурасына сала.

"Торналар төшкән җирдә" повестена кереш сүз хикәяләүчене җитди, тормышның моңлы якларына күбрәк игътибар бирүче, яшәешкә фәлсәфи карашлы хикәяләүче-геройны тәкъдим итү белән башланып китә: "Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә академик та чыкмаган. Гап-гади, иң гадәти бер авыл. Анда зур сулар, таулар иркен болыннар юк, кыялар юк. Тагын бик күп нәрсә юк".

Эпиграфта сүз туган җирне сагыну турында бара. Автор-хикәяләүченең сагышы кешенең үзе өчен кадерле булган кыйммәтләрнең кадерен (туган ил, газиз кешеләр) югалткач кына аңлавы белән бәйле: "1976 нчы елның октябрендә мин Франциянең Париж, Марсель, Авиньон шәһәрләрендә йөрдем. ... Баш әйләнгән, тәэсирләр шундый көчле, нинди дер бер мизгелдә үзеңне онытып, югалып торасың. Ләкин нәкъ шул хәлдә – табигыйлекне югалткан бер хәлдә, нигәдер минем йөрәгем сулыгып-сулыгып алды..." Үткән/бүгенге оппозициясендә әдип үткәннең билгеләрен тергезә. Бу билгеләр үзара оппозиция хасил итәләр: "безнең авылда гасырлар буе

үстерелеп, тукылып, эрләнеп, сугылып килгән киндерне” бүген джинсы диләр, ат итенең файдасы турындагы гыйльми ачыш “безнең авыл тегүчесе Хөснетдин абзыйга” күптән мәгълүм, арыш капчыгының да бүгенге исеме башка, хәзер иң югары культура билгесе саналган безнең авылның бурабзары башкача атала. Кереш сүз өлешендә образларны детальләштерү урын ала. Үткән – алтын куллы буяучы, калайчы, тимерче; кызылга каккан кайры тун, сагыз, арыш капчыгы, күтүмкә, чутсыз катык. Бүгенге – джинсы, жвачка, озын чәчле егет, йоклар алдыннан бер стакан катык. Үткән/бүгенге оппозициясендә мотивлар да катнаша: Чуриле урыслары манып биргән киндер “кешеләрне матур итәм, кешеләргә матурлык бирәм дигән төшенчә белән бер”, ә бүген “без аны тырышып-тырышып онытып ятабыз”; “эшнең көйле, ритмлы җайга салынган икәнлеген” белдерүче сагызны чәйнәүче Сан-Мартин төзек наратларның жвачка ясау өчен ясалган сырының елап утыруын ишетми. Шул рәвешле, кабатланган образ, детальләр, мотивлар аша “дөньядагы барлык халыклар өчен уртак гадәт, уртак гамәл, холык-фигыль, эш-гамәлләр” булырга тиешле хакыйкать атала – эшең көйле, ритмлы җайга салынган булсын дисәң, кешеләрне матур итәм, кешеләргә матурлык бирәм, дип яшәү дөрес. Әсәр шул турыда: “Бу әсәр – безнең авылда яшәгән, бүгенге буынга юньле әхлак-гадәтләр тапшырып дөньядан киткән кешеләр турында”. Кереш сүзгә өстәмә өлешендә үткәне бүгенге белән бәйләүче таш, елга образлары автор фикерен ныгытып куя. Көчле позициядә укучы табачак әлеге хакыйкатьнең гомумәһәмиятлелеге иҗади гомумиләштерелгән таш образы аша искәртелә. Таш – мәдәни һәм дини күзаллау белән бәйле конструктив архитектура элементы. Ул – био- һәм семиосфераны, табигать һәм мәдәниятне, органик һәм органик булмаганны, яшәү һәм үлемне бәйләүче символ. Бу мотивны куллану нәселнең йомшак, хатын-кыз белән бәйле “борынгы хәтеренә” мөрәҗәгать төсен ала. Ташлар – телсез, алар сөйләме “өнсез”. Дәшмәүләре борынгы заманнарның мифологик асылына тәңгәл килә. “Бәлки ата-бабалар баскан таш”ка бүгенгедәге “тимер рәшәткәле капка ” – ике дөнья арасындагы чикне белдерүче образ каршы куела. Профсоюз җитәкчесе Нәкыйп абый белән тимер ишекле капка янында очрашу, иңенә авыр туган җир ташын сыйдырган капчык кигертү – яшәп килүче идеология шартларына җайлашкан үз асылына кайта алмый газапланган татар кешесе образын тәкъдим итү. Текстның башлам өлешендә автор укучысы образын шул рәвешле урнаштырса,

хикәяләүче образын “кешеләрнең эш-гамәлләрен бәяләүдә гадел, нечкә һәм саф күңелле, күзәтүчән, туган туфракны яратучы, хезмәт кешесе, тормыштагы күңелсез моментларны авыр кичерүче” автор образы дип идеаллаштырып кертеп җибәрә. Лирик-эмоциональ башлангычлы автобиографик повесть тукымасында тәкъдим ителгән әсәр чынбарлыгына карата мөнәсәбәтен үсеш-үзгәрештә, хәрәкәттә сурәтләүче автор “мин”е тирәсенә җыелган лирик-субъектив катлам вакыйга-күренешләрне бер үзәк тирәсенә туплый. “Нәтиҗәдә, әсәрдәге төп каһарман булган “мин”нең рухи дөньясы, аңы, укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә ала. Әсәрнең иҗатчысы, язучы-автор белән янәшә, әсәр тукымасында тагын бер автор образы пәйда була. Язучы-автор уңай герой ярдәмендә белдерергә мөмкин булган фикерләр, идеал нәкъ менә автор образы аша укучыга ирештерелә. Автор образы уңай геройга хас булырга мөмкин барлык сыйфатларга ия”.

М.Мәһдиев повестьларында үткән/хәзерге оппозициясе әсәрләрне оештыру вазифасын үти. Авторның кереш сүзендә структура билгеләп үтелә: “... Фәрваз Миңнуллин сөйли: бу иптәшнең, ди, бөтен иҗаты – яшьлекне сагыну. Яшьлекне сагыну? Бу – минем өчен ачыш. Бәлки бу әсәргә исемне шулай кушаргадыр?”

Шул рәвешле, көчле позициядә әсәрнең сюжет структурасын оештырган мотив, образлар, хис-мөнәсәбәт сызыгы гомумиләштерелә.

“Төлке уйный торган орлар” дип исемләнгән беренче бүлеккә борынгы йола җырыннан алынган эпиграф (“Җиләк җыям, как коям Падишага бүләккә...) һәм исем сайланышы М.Мәһдиевнең XX йөз башы әдәбиятында колач алган мифлаштыру – мәгълүм мифларны файдалану яки яңа миф тудыру күренешенә мөрәҗәгать итүен раслап килә. Бу урында галим М.Мәһдиевнең җыр жанрына караган фәнни эзләнүләре барлыгын да күрсәтеп үтү урынлы булыр. Әдәбият галиме А.Г.Яхин белән бергә эшләнгән “Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү” дип исемләнгән хезмәттә бик борынгы заманнарда җырның ничек барлыкка килүе хакында сүз алып барыла, иҗат процессына табигатьнең тәэсире, ихтыяҗ булып туган-үскән йола фольклоры, ритм һәм состав өлешләре кебек тәкъдим ителә. 1960-1980 еллар прозасында мифны үзенең әсәрләрендә сюжет структурасына төреп тәкъдим иткән әдипләр арасында М.Мәһдиевнең беренче урында торуы гаҗәп түгел.

Мифның тормышны концептуальләштерү чарасы булуы гомумбилгеле. Ул әдәбияттагы аерым, үзенчәлекле, конкрет күренешләрдән – гомумиләштерелгән, модельләштерелгән бәягә, типиклыктан архетипиклыкка хәрәкәт итәргә юл ача. Әдәбият, аерым кеше яки гаилә, авыл яки гадәттән тыш вакыйга-хәл тарихы белән канәгатьләнмичә, милли тарих, гасырлар төпкеленә китә торган төрки-татар тарихы, кешелек тарихы хакында сөйли башлый. Мәгълүм мифологик материалга мөрәҗәгать иткән әсәрләрдә иң әһәмиятлесе – авторның шәрехләве, субъектив фикер катламы.

Беренче бүлектә җире рәтсез булу әхлакый югарылык белән янәшә куела: "Җире рәтсез якта халык һөнәрле була". "Агач, юкә төшерү, мунчала чыгару, такта яру, утын әзерләү белән шөгыльләнгән төбәкләрдә гасырлар буе алга китә алмаганнар. Аларның бердәнбер табышы – әхлакый югарылык". Дөнья мәдәниятләре өчен уртак кыйммәт дип исәпләнгән Җир образы мифопоэтик укылышта ана мәгънәсендә килә, яңадан туу, рухи үсеш, яңарыш, үз асылыңа кайтуны символлаштыра. Эллин акыл ияләре Җирне Яшәешне барлыкка китергән ана буларак илаһилаштыралар. Афиналылырның барлык серле Элевсин мистерияләре Җир культы – уңыш җыю, орлыкны саклау, җир эшкәртү белән бәйле була. Җир-Ана тудыручы, саклаучы, нәселне дәвам итүче буларак сакральләштерелә. Рус халкында «Алдама, җир ишетер", "Җир яраткан кадәр ярат" дигән мәкальләр Русь дәүләтеннән үк килә. Бөек сәяхәтче Ибн Фадлан болгарлар илаһилаштырган уникe исем арасында җир барлыгын теркәп калдыра. Әлеге образ дөнья фольклорында зур урын били, ут, су, һава белән беррәттән, борынгы натурфилософик дүрт стихиянең берсе буларак милли дөньяларны һәм акылларны сурәтләүче метател сыйфатында, дөньяның тулы картинасын тергезергә мөмкинлек бирүче кебек тамгалана. Галәмдәге яшәешнең башлангычында торган Җир-Күк пары – барлык мәдәниятләр өчен уртак мифологик сюжет.

Автор-хикәяләүче укучыны символик укылышта сынаулар аша үтү юлы кебек шәрехләнгән урман юлына алып керә: "Безнең халыкның бөтен рухи дөньясы урман белән бәйле". Шул урында эпиграфта билгеләнгән, мифологик катламда яшерелгән тормыш гаделсезлеге, үкенү хисе эчтәлеккә кереп урнаша. "Үзәгенә үткән, бәгырендә яман төер, кара кайрак булып калган, ахыр чиктә гомерен кыскарткан утызынчы елларга Мәһдиев иҗатында аерым урын, үзгә мөнәсәбәт яши,"– дип яза әдәбият галиме Т.Галиуллин. Тормыш-

сынауның башлангычы – күңелдә урнашкан шом, куркуның әдип һәм аның замандашлары өчен шул елларга барып тоташуы аның һәр әсәрендә искә алына: “Безнең урманның бер почмагы минем гел күз алдымда тора. ... Телефонлы олы юл (бездә чыбыклы юл) кырыендагы дүрт квартал почмагы ул. Анда юан баганалар утыртылган. ... Әлеге баганалар нәкъ кеше сыман утыралар, алар нәрсәдер әйтергә телиләр, сөйләшергә омтылалар. Кешеләрнең аларга ихтирамы шулкадәр зур, утыз өченче елларда утыртылган баганалар илленче елларда төптән череп, өзелеп аудылар, әмма бер генә кеше дә аларны утын итеп өенә алып кайтмады”.

Урман-сынау образына бәйле пейзаж, тышкы дөнья сурәтләнеше җир табигатенә хас образларга илаһи серлелек өсти. М.Мәһдиев үткән / бүгенге оппозициясен сакраль /профан оппозициясе белән көчәйтә. Бу оппозициянең сакраль ягын миф формалаштырса, профан ягы авторның мөнәсәбәте, фикере кебек хасил була: “Урманга беренче баруымны хәтерлим: дүрт яшьләрдә булганмындыр. Аңарчы урман безнең басу түрендә могҗизалы стена, серле әкият булып торды. Ул басу түренең бер почмагыннан башланып ике чакрым ераклыкта ярым божра ясап авылны әйләнеп уза. ... Менә, ниһаять, шул сихри дөньяның бер почмагына алып кереп мине бастырдылар. Күзгә ташланган иң беренче нәрсә күч-күч булып утырган абагалар иде. Аннан миңа карт имән ботагында утырган бер кошны күрсәтеләр. Ул, ахрысы, миннән бик аз гына кечкенәрәк иде. Мәче башлы ябалак. Аның бите миңа кеше бите булып күренде. Мифлардан килгән символик укылышта абага чәчәгенең ике мәгънәсе бар: “Беренчедән, аның халык ышануларындагы могҗазалы-романтик рухы саклanса, икенчедән, үзенең реаль эчтәлеген саклап, “дөньяда юк әйбер”, “беркайчан да булмаячак” мәгънәсендә кулланыла”. Серле дә, куркыныч та тоелган билгесез хыял чынлап та булмастай чынбарык, аны мәче башлы ябалактай кануннар богаулый, әмма тормыш дәвам итә, аның кануннары кырысрак: “Ахырдан, берничә еллар узгач, мин “уф алла” арбасы белән бу урманнан утын ташыдым. Абагалар беткән, мәче башлы ябалаклар да хәзер күренми иде”. Илаһи серлелекне Торна елгасы образы дәвам итерә. Көчле позициягә – исемгә чыгарылган, текстта кабатланган әлеге образ символик укылышта зирәклек, саклык, уяу булу һәм чисталык мәгънәсен белдереп килә. Төрки-татар әкиятләрендә геройның тугрылыклы һәм ышанычлы ярдәмчесе итеп сурәтләнгән бөркет образы белән янәшәлектә бирелү – сынаулар

үткәндәге яшәеш кагыйдәсенең тәкъдим ителүе ул. Тугрылыклы, ышанычлы булу күңел чисталыгын саклый, үзең булып калырга, сынаулар килгәндә югалып калмаска ярдәм итә, ди автор: “Торна елгасы дигән урында язын торналар туктап бала чыгара иде. Урманнан бөркет китү үзе бер зур вакыйга була иде”. Мифологик укылышта Аполлон образы белән тәңгәл бүре яктылык, ана мәгънәсендә килә. Мисырлыларда бүренең җимергеч көч буларак символлаштырылуы мәгълүм. М.Мәһдиев прозасында бүре символы ике мәгънәдә дә кулланыла. Бөркет образы белән янәшә килгәндә бүре куркыныч янавын белдереп кулланыла: “Авылга килгән бөркетне авылның бөтен кош-кортлары сизә иде. Бүрене дә шулай”. Идеологиянең вәхшилеген тасвирлау максаты белән унбиш яшьлек малайның бүре күрү вакыйгасын, ана бүренең аны исән калдыруын сөйләп, автор-хикәяләүче М.Җәлилнең “Бүреләр” шигырен стильләштереп, әлеге образның беренче мәгънәсен куллана: “Юк, ни генә әйтмәсеннәр – бүреләр кешеләр кебек үк яман түгелләр. Мәсәлән, НКВД кешеләре кебек...”.

Үткән / бүгенгене тоташтыручы кичерешләр сызыгы чыбыклы юл әдәби деталенә салына: “Әмма гомер буе минем йөрәгемне телеп-телеп сагыш кайнады, бала вакытта шул юкә төпләрендә чыбыклы юл буенда ятканда уйлаган уйларым миңа гомер тынгылык бирмәде, гел каядыр чакырып торды”. Шул рәвешле, кеше тормышының беренче кагыйдәсе атала: “Безнең урманның матурлыгын, мәгънәлелеген, акылын беләсегез килсә, аның эчен көзге вак яңгыр яуганда керегез. Керегез...” Импрессионистик алымнар белән баетылган пейзаж өлешендә хакыйкать тамчысы дип укылган яңгыр символы ярдәмендә автор тормышның мәгънәсен заман шаукымына уяу булып, буыннар арасындагы бәйләнешне саклау дип төгәлләштерә: “Вак кына аланнарда икешәр, өчәр булып моңаеп утырган печән кибәнәре. Аларны киртә белән әйләндереп алганнар, ул киртәләрнең кайрысын поши килеп каезлаган. Карт юкәләр вак яңгыр тамчыларын өсләренә җыеп акрын гына шыбырдашып утыралар, әле яфрак бар, әмма инде соңгы атналар. Каен инде саргаеп яфрак коя, яфрагын койган каен чыбыклары күксел шәмәхә слива төсен керә бара. ... Юеш киртәле печән кибәннәре җиләк исе, шипр исе бәреп торган коры ылыс түшәлгән чыршы төпләре – барысы да калыгып, көзне көтеп уйга калган. Шулар янында көз килгәнне тыңлап тору рәхәт тә, сагышлы да... Киләсе елда да шулай күрешә алырбызмы? Без исән булырбызмы?

Урманчы кләймә сугып сезне утынга ыргытмасмы? Ә сез, печән кибәннәре, киртә буена килгән биек аяклы, кара ахак күзле беркатлы поши малайларына, кызларына бездән сәлам әйтегез. Ә сез, чыбыклы юл юл буендагы чокырлар, орлар! Сезнең иңкүлектә төлкеләр уйнаганда Сез аларга әйтегез: сак булсыннар, аучы килгәнен сизми калмасыннар!” Автор шул рәвешле сакраль/профан чиген үткән геройны идеаллаштыра, аны тормышның мәгънәсен аңлаган, аны башкаларга өйтеп бирергә теләүче итеп таныта.

Икенче бүлектә автор-хикәяләүче хакыйкатьне күңелгә үткәргән укучыны аңа таныш булган бәхетле чынбарлыкка алып керә – Сабантуй, түгәрәк уеннарның татар кешесе тормышындагы урынын мөнәсәбәт тарихы итеп урнаштыра. Бу бүлектә илаһи серлелек җыр, моң образына салып тәкъдим ителә: “Бу инде кеше генә түгел, бу инде гармун гына түгел, бу – татар халкының гасырлар буена килгән моңы, рухи куәте, музыкаль потенциясе, бу – татар халкының оркестры, филармониясе, консерваториясе”. Сабантуй – татарны туплый, җыйный торган бәйрәм, йола: “Сабантуй көне авылга күрше- тирә авыллардан нәсел-нәсеп җыела”. Сабантуй мифологик мотивына татар халкының көнитеше, бәхеткә юлы дигән мәгънә салына. Түгәрәк уенны тасвирлау, җыр образы аша автор халыкның рухи тәҗрибәсенә универсальлек һәм гомумәһәмиятлелек өсти, иҗади гомумиләштерә: “Монда – үзенә бер дөнья. Үзенә бер закон. Син инде йөрәгең җитеп түгәрәк уенга керденме, рәхим итеп аның кануннарына буйсын. Бу – язылмаган закон”. Автор татар кешесенә хас булган сыйфатларны берсүзсез үтәлергә тиеш язылмаган закон дип белдерә. Татар кешесен бәхетле итә торган сыйфат – битараф булмау, гаделлекне яклау һәм сер бирмәү. Һәр җыр ситуациясе шул хакта. Экзистенциаль башлангычлы , яшерен сагыш белән өретелгән һәр вакыйга һәрчак яшерен өмет ноктасында төгәлләнә.

Хикәяләүче укучыны татар кешесенә ят булган гадәтләр белән таныштыру ноктасына җитә: “Безнең авылда “ят” сүзенең эчке мәгънәсе коточкыч иде,.. “Ят” – синең иң газизеңә, иң кадерлеңә кул сузучы, күз салучы икән”. Татар кешесе өчен хәсрәт китерүче, газиз кешеңә, кадерле хисләреңә, кыйммәтен билгеләп бетергесез гадәтләреңә кул сузучы ят, чит:

Алма биреп ашатырлар,
Ашама, бәгыркәем,
Аштырлар, ташлатырлар,

Ташлама, бәгырькәем.

Бу – “авыл йоклаганда да яшәүче рухи тормыш”. Шул рәвешле, татар кешесенә тугрылыклылык, ышанычлы булу, уяу, сак булу хас, дип автор миф кертелгән эчтәлектән хис-мөнәсәбәтләр тарихы катламына күчереп кабатлый. Татарның иң кыйммәтле ягы – бердәмлеге. Борынгыдыан килгән һәр йола кешедә бердәмлек, ярдәмчеллек гадәте тәрбияләү максатына буйсындырыла. Татар тормышында һәр кешенең үз урыны, гамәле бар. Символик эчтәлектә кечке уен, җыр образына төреп автор-хикәяләүче бердәмлекне серле, илаһи хис дип бәяли: “Бу хорда һәркемнең үз роле бар. Моны берәү дә белми. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга: берәү җырны башлый. Икенчесе җырның билгеле бер урынында катышып китә. Өченчесе җырның билгеле бер урынында болай гына тавыш биреп куя. ... Дүртенче берсе билгеле бер урында сызгырып җибәрә”. Халык тормышының үзе булып торган җырлар турындагы сөйләм өметсезлек ноктасында төгәлләнә: “Уен җырлары һәм урам җырлары исә яшьләрдә үз авылына, үз туфрагына мәхәббәт тәрбияләү буенча озак кына файдалы хезмәт иттеләр дә тарих сәхнәсеннән төштеләр”.

Яшерен сагыш белән өретелгән хикәяләү “Алай да чишмә бар әле...” бүлегендә дәвам итә. Автор эпиграф итеп С. Хәкимнең дүртьюллыгын кертә.

Чишмәләр үзләре минем
Учларыма су салды.
Су салды алар яшәргә
Көчәйтеп тик сусауны.

Чишмә образы яшәүгә дәрт бирүче шул ук вакытта сусауны – яшәүгә омтылышны ныгытучы чыганак мәгънәсендә килә. Биредә әлеге яшәешне күзәтүче вазифасын башкаручы Сафый абзый тарихы сөйләнелә. Хикәяләүче укучыны “су буена таба бүлтәеп чыккан тау битенә” алып менә, урам тормышына читтән карарга чакыра: “Ул – бөтен бала-чагасы белән урам тормышыннан читтә”. Зирәк карт архетипик моделе (“кызгылт бит, зәңгәр күз, очлы ияк, сирәк сакал, өстә – кызыл сатин күлмәк”) бакчачы карт Сафый абзыйның төп гамәле – яшәешнең башлангычы символы булган чишмәне саклау: “Чишмәне ул карап тора, өстен яба, тамагын чүп-чардан чистарта, әйләнә-тирәдәге чүп үләнне йолка, үзенең хикмәтле, кирәмәтле бакчасына кереп югалганчы чишмәне бер әйләнә”. Су, агымсу – кешенең чиксезлеккә төбәлгән соравына җавап бирүче: “Су – бик

борынгыдан килгән яшәү символы. Тормышның килеп чыгышы хакындагы барлык легендаларда су – беренчел элемент". Сафый абзый – "уракчы хатыннарның яулыкларын артка чөеп, бит юганнан соң, көлтә бавы чылатулары, өстикәгә су тутырулары, "ат караучы Әхмәт абзыйның башта чишмәдән агып чыккан ерганакка алып килеп, йөгән сабагын ычкындырып, аркалыгын бушатып, сызгыра-сызгыра ат сугаруы, аннан озын агач саплы кара тимер чиләк белән мичкәгә чишмә суын тутыра башлавы", кичкә таба вак-төяк кыз баланың бәрәңге юу, бүген суйган тавыкны юу, ит юу – ризык, тормыш итү өчен җаваплы: "Сафый абзый шунда бик бәхетле була, керт-керт атлап таудан чишмә өстенә үк төшә дә бәрхет чирәмгә җайлап кына утырып кәеф-сафа кора. Ул караган чишмәнең суын бүген колхозның җитмешләгән аты рәхәтләнеп эчәчәк. Сафый абзый шатлыктан кызгылт-сары тар сакалын сыпырса, аның вак зәңгәр күзләренә очкын йөгерә һәм ул бәхете ташыган кыяфәттә болай ди: "Алай да чишмә бар әле, име, Әхмәт!" Шул көе ул елмаеп кала.

Буыннарда туплана торган хис-кичерешләр өчен җаваплы Сафый абзый янәшәсендә бирелгән "сөйләшергә яратмый, эш кенә эшли торган, әмма Сафый абзыйның бу чишмәсенең кеше тормышындагы әһәмиятен югары бәяләүче Әхмәт абзый" образы – М.Мәһдиевнең көтелгән укучысы, югары әхлаклы камил татар кешесе образын гомумиләштерә: " ...һәм сүзгә гадәттән тыш юмартланып Сафый абзыйның әлеге лирик чакыруына ул да җавап бирә: "А-а..." Бу инде туган телгә тәрҗемә иткәндә менә нәрсә дигән сүз: әйе, ы-ы, Сафый туган, синең бу чишмәң безнең барыбыз өчен дә кирәк, син дөрес әйтәсең, сиңа рәхмәт. ... Әхмәт абзый да бүген үзенең артыграк сөйләшеп ташлавыннан кыенсынып калган сыман һаман әле чишмә инешенә үрелеп яткан атын ачулана: аты чишмәгә суга төшкән бер кызның чиләгенә үрелеп, авызлыклары белән зыңгырдап, төкле кара иреннәре белән чиләк бавын кыймылдатып ята икән".

М.Мәһдиевтә яшәешне анализлау өчен кулланылган бакча, чишмә образлары – гомумиләштерелгән образлар. Автор-хикәяләүченең өмете кебек формалаштырылган соңгы өлеш М.Мәһдиевнең милли йөзен үзе теләп җуйган татар кешесе иртәме-соңмы бер үз асылына кайтып, чишмәдә бит-кулын юар, җанын сафландырыр дигән теләге ул: " Бу чишмә әле дә шулай чурлап ага, безнең авылдан читкә киткән кешеләр авылга кайткач әле дә булса беренче чиратта шул чишмәгә төшеп битләрен, кулларын юалар,

рәхәтләнеп суын эчәләр". "Дөньяның дүрт ягыннан нәкъ җиде юл кайтып төшкән җирдә урнашкан безнең авыл" – кешенең изге асылы, рухы, камиллеге.

Әсәрдә укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә алган автор-хикәяләүче буыннардан килә торган яшәеш тәртибен – эшең көйле, ритмлы җайга салынган булсын дисәң, кешеләргә матурлык бирәм, дигән максатны алга кую бурычын урман-сынауны үткәндәге төп канун буларак билгели, Хозыр Ильяснық генотибы, зирәк карт архетипик моделе Сафый абзый образы ярдәмендә беркетә, ышандыра, иң кадерле кешесе – әтисе образы аша ныгытып куя. "Әти... Минем дә әтием бар иде, солдат булган, мәдрәсә шәкерте булган, Риза Фәхретдинов имзасы куелган зур документы – "имам-хатиб-мөдәррис" дигән дипломы булган, Тукай, Ф.Әмирхан иҗатын күңелдән белгән әтием бар иде", – дип яза М.Мәһдиев үзен фәнгә китергән сәбәпләрнең берсе хакында. "Дүрт тополь" дип исемләнгән бүлектә әтисенең солдатка алыну тарихы белән таныштыра: "Гаиләдә ул төпчек малай булган, әтисез үскәннәр. Әбинең бу малайга өмете зур булган һәм аны ерактагы Сатыш мәдрәсәсенә җибәреп ун ел укыткан. Мәдрәсәне тәмамлауга әти наборга эләккән". Тормыш тәртибе турында ата улына өйрәткән кагыйдәләрдән укучыга өчесе тәкъдим ителә: "Тәрбия өлкәсендә әтинең берничә таләбе бар иде. Моның өч пункты хәтердә калган. Ул таләпләрдән мин файда да күп күрдем, зыян да аз күрмәдем". Шул рәвешле, буыннардан килә торган яшәеш тәртибен автор-хикәяләүче "Ялганлама.Тик дөресен генә сөйлә. Урлама. Кеше малына, дәүләт милкенә кагылма. Укытучы алдында белгәнеңне яшермә. Бераз белсәң кул күтәр. Укытучы үзе ярдәм итәр" кебек өч кагыйдәгә утырта. Димәк, кешеләргә мөнәсәбәттә гадел булу, белгән гамәлеңне кылу – иң камил һәм гади яшәеш тәртибе дип билгеләнә, гадел кешегә тормыш-укытучы үзе ярдәм итә, өйрәтә, алга этәрә, ди автор. Дүрт саны бөтенлекне, камил ритмны, гаделлек Алласын белдереп килә. Төп геройның әтисе тормышының бөтен, камил оештырылганын, гаделлек юнәлешендә икәнлеген хәбәр итү өчен автор-хикәяләүче дүрт тополь детален куллана. Тополь – биш серле агачның берсе, ел фасылларын символлаштыра: " Нигә инде әти аларны тугыз-ун төп утыртмады икән?"

"Елларга иминлек бирсен" бүлеген автор-хикәяләүче үзенең "кечкенә вакытта тыңлаган догаларының берсе"ннән алынган сүзләр белән атый: "Тынычлык, иминлек шулай бик кадерле, ул безнең

халыкның рухына сеңгән иде”. Бирeдә хикәяләүче “ата-бабадан килгән матур омтылыш – бердәмлек рухы”ның “авыл педагогикасының нигезендә” ятуын сөйли. Димәк, бәхетле булырга ата-ана аерым өйрәтми, “авыл” җәмгыятендәге һәркем башка берәү өчен үзен җаваплылык тоя: “Олылар сөйләшеп утырганда да гел әдәп-әхлак кагыйдәләре, иминлек теләкләре белдерелә иде”. Бу өлештә Әсхадулла абзыйның сүзсез, елатмыйча гына алты малаен тыю өчен биш тапкыр тал чыбыгы сызгыртуы, Хәсән абзыйларда сөйләшмичә ашау әдәбенең үрнәк итеп алынуы, кош балаларын үтерүче Миңниислам исемле ташбаш малай мисалында “начарлык ягына адым атлаган кеше тормышта җәзасын таба” дип белдерү, “бөтен бер төбәкне беркетеп торган” Камәр түти мунчасы, өч-дүрт сәгать чыкмый юынып-сыйланып утыра торган Гыйльмениса мунчасы, ял итү – “таянып алу” өчен көйләнгән “дөньядагы иң тыныч урын” булган “Бүре Әскый сәкесе” , “дөньядагы иң тыныч кеше”, “гомер буе бер кеше белән дә конфликтка кермәгән” Бүре Әскый үзе – имин яшәү рәвешенең аталышы. Шул рәвешле, лирик-эмоциональ башлангычлы автобиографик повесть тукымасында автор “мин”е тирәсенә җыелган лирик-субъектив катлам вакыйга-күренешләрне бер үзәк тирәсенә туплый. Үткәндәге тормыш автор-хикәяләүче өчен бүгенгедән әһәмиятлерәк яссылыкка куела, хис-мөнәсәбәтләр чор, иҗтимагый тәртипләр тәэсирендә хасил булалар. “Җирдә икмәк үстерүче, урман кисүче, юкәдән – чабата, агачыннан башмак ясаучы, мунчаласыннан бау ишүче, чиста, әдәпле, ипле кеше” Әскый-Әсхәдулла образы ашы үткән/бүгенге кебек ике чиккә аерылган як татар кешесенең бәхетле яшәү рәвешен гомумиләштерергә омтылу: “Андый кеше юктыр, юктыр...” Дога белән башланган бүлекне Әскый картның үлем алдыннан әйткән азан белән тәмамлап, автор аның яшәешен сакраль/профан оппозициясен үтү юлы кебек тамгалап куя.

Татар кешесенең көйле, ритмлы, җайга салынган тормышы, кешеләрне матур итәм, кешеләргә матурлык бирәм, дигән максаты хәсрәтле чынбарлыкны яратып, рәхмәт әйтеп кабул итә белүе белән бәйле, ди автор әсәрдә гомумиләштерелгән Сафый, Сөнгат, Әсхадулла абзый образлары ярдәмендә.

“Әйа агач, яшең күпме?” бүлегендә Беренче Бөтендөнья сугышында тол калып үстергән өч малаен Икенче Бөтендөнья сугышына озатып, аларның үлем хәбәре белән бер-бер артлы өч кәгазь килгәч, “халык алдына чыгып елап йөрмәгән, хәлен сорашкан

кешеләргә: “Шөкер, хәсрәтне күп күрдем”, – дип җавап биргән авыл табибәсе Мәрфугатти язмышы шулай ук авторның татар кешесенең тагын бер ягын изгеләштереп куюы. Шәфкатьлелек идеалын символлаштырган 99 яшьлек карчыкның үлем алдыннан әйткән соңгы рәхмәте – татар кешесенең хәсрәтле чынбарлыкны рәхмәтле булып кабул итүе – тормышның көе, ритмы, җае ул, ди М.Мәһдиев. Ике малае сугышта эзсез югалган балаларны шатландыра белүче “Йосыф-Зөләйха” поэмасының бер нөсхәсе иясе рухи ана Хәдичәтти теле белән әйтелгән Г.Кандалый сүзләре – татар кешеснең рухи көчен аның рәхмәтле, сабыр булуына бәйләп фикерне ныгытып кую өлеше.

Яшәешне аңлату өчен сайланган алдагы образ “гомер буе кеше матурлаган”, “Тукайның үзенә тужурка тегеп биргән, Габдулла Кариевны, Мортаза байны, Камил Мотыйгыйны, Мотыйгулла хәзрәтне күреп-белеп сөйләүче ак тегүче” Гатият абзый, шулай ук Тукайга берничә тапкыр чалбар, күлмәк теккән икенче ак тегүче Хәмит абзый сюжет структурасына кереп урнаша, төп мотивны кабатлыйлар. “Кешене матур итәм” мотивын кабатлаучы кендек әбиләре образлары – яшәеш фәлсәфәсен әйтеп бирүчеләр. “Берәү – улдан, берәү – кыздан” бүлегендә һәркем белән исәнләшеп, һәр бала янында туктап, үзе таптырган балаларны башыннан сыйпап елап җибәрә торган кендек әбисе Газзәтти, ике бүрек киеп йөрүче кендек әби Гайшәтти игелеклелек идеалы буларак тәкъдим ителә.

Әсәр төзелешенә урнаштырылган борынгы йола-гадәтләр дә яшәешне анализлау өчен сайланган детальләр кебек кабул ителә. Шәл бәйләү, аулак өйләр – “тормыш-көнитештәге “күп мәсьәләләрне хәл итү урыны”: “ Монда кызлар бер-берсеннән хезмәткә өйрәнәләр (шәл үрнәкләре, чигү, бәйләү һ.б.), монда егет сайлыйлар, танышалар, аңлашалар, җыр-көй өйрәнәләр, уен уйныйлар”.

Әсәрдә вакыйгалар үткәннең бәхетен сагынып, балачакны хәтердә тергезү ноктасында төгәлләнми. Кабер детале яшәештәге ата-бала арасындагы арасындагы дәвамчанлыкның, тормышның өзелмәс-тукталмаслыгын, яшәүнең ниндидер олы, шушы дәвамчанлык белән бәйле мәгънәсен беренче планга чыгара, кешенең үз эш-гамәлләре белән шушы олы кыйммәткә лаек булырга тиешлегенә басым ясала: “Хәдичәттинең кабере безнең авыл зиратының иң матур урыны – кояшлы, җиләкле тау кырында. Аның кабере очында бик көяз каен агачы бар. Җәйнең тын, эссе көннәрендә дә вак, затлы-пөхтә яфракларын дерелдәтеп, һава дулкыны белән серләшеп утыра ул каен.

Мин шул каберлеккә киләм дә (Хәдичәтти янында үз әнием дә ята) каен башына текәлеп торам". "Арчин" бүлегенә көчле позициягә – эпиграфка чыгарылган Р.Гамзатовтан алынган текст яшәү мәгънәсен раслап куя: "Кешеләрнең кадерле җырлары өч төрле. Бу җырларга халыкның бөтен кайгысы һәм шатлыгы тупланган. Шуларның берсе бик якты: ул җырны бишек янында ана җырлый. Җырның икенчесе дә анык: табутта яткан улының боз кебек салкын яңакларын сыйпап җырлый ул аны. Ә өченче төрлесе? Калган барлык җырлар өченчесенә керә..." Яшәеш кагыйдәсе – сабырлык Шәйхи алмазы, "Арчин" бүлегендә бирелгән Гатият Әсмасы фаҗигасе аша шул мотив кабатланып килә.

Алдагы бүлекләр – автор-хикәяләүченең – "малайлыктан егетлеккә аяк атлаган" яшүсмернең беренче тапкыр символик укылышта зирәклек, саклык, уяу булу һәм чисталык мәгънәсендә килгән торналар белән хушлашуыннан туган экзистенциаль сагыш мотивы кабатланган өлеш: "Торналар хушлашуын ишетеп иңрәп калган бу авыл мине үз баласы күк итеп ямансылап озатып калды. Сау бул, яшьлек!" Әтисе фаҗигасе, әнисе үлеме турында сөйләгәннән соң автор-хикәяләүче көчле позициядә – соңгы сүз өлешендә моң, хәсрәт нигезләнә: "Торналар шунда минем тормышымнан нәрсәнедер алып киттеләр. Мин үкенечле караш белән күккә күз юнәлтеп авызымны ачып тордым. Их, нигә ашыктым соң? Нигә тыныч кына карап тормадым?" "Мәңгелек матурлык, шигърият чыганагы" торналар, "сабырлык, акыл чәчә торган Масра юлы" – автор-хикәяләүченең теләге, үкенеч-сагышлары да.

Күренгәнчә, автор-хикәяләүче сюжет структурасын көчле позициядә бирелгән мотив-образларны кабатлауга кора. Еш кына интертекстуальлеккә мөрәҗәгать итү дә төп оппозицияне көчәйтүгә хезмәт итә. "Акрын искел, сәбах җиле!" бүлегенә исем итеп алынган Дәрдемәнд сүзләре сюжеттагы сагыш мотивын көчәйтә. Горур холыклы тегүче Хөснетдин белән Гыйльменисаттиләрдән автор-хикәяләүче меңъеллык тарихлы татарның өстәл китабы "Йосыф-Зөләйханы" әйттерә: "Йосыф-Зөләйха" кыйссасы турында мин күпме генә фәнни хезмәт укымадым! Бу турыда ничә генә лекция тыңламадым! Әмма алсу эре чәчәкле шәлъяулыгы белән бөтен аркасын-җилкәсен каплаган Гыйльменисаттинең урындык яртысын гына алып "ы-ы" килеп Йосыф кыйссасын укыгандагы кебек көчле тәэсирне бер җирдә дә алмадым". Биредә XX гасыр башы "татар

әдәбиятына үзенчәлекле метафизик күзаллау алып килгән" Дәрдемәнднең шигъри тезмәсен көчле позициягә чыгару аның шигырьләре белән аваздашлыкны табарга мөмкинлек бирә. Дәрдемәнднең "яшәешне анализлау чагылыш тапкан шигырьләрендә дөнья сурәте гомумиләштерелгән образ хасил итә. Яшәешне аңларга омтылучы лирик герой аны ике: реаль / трансцендентал якларга аера. Хакыйкатьне шушы ике чик тоташкан урында табарга, теге яки бу оппозициянең билге-символлары аша белдерергә тели. Ул – кешелекнең бер вәкиле, гомумән, кеше аңының тирәлекне-яшәешне танып белү омтылышын үзендә йөртүче". М.Мәһдиевнең сюжет структурасына хас булган реальлек / трансценденталлек оппозициясе XX гасыр башы әдәбиятына тоташа икәнлеге раслана да. Дәрдемәндтә дә "лирик герой сагышының сәбәбен яшәешнең билгесезлеге тәшкил итә". М.Мәһдиев исә тормышта гармония, сафлык сакланырмы, киләчәккә җитәрме, дип моңая, уйлана. "Бәхилләшү әсәрендә моңа җавап та бирә.

Әдәбият


1. Жюльен Н. Словарь символов. – Челябинск: Урал LTD. – 1999. – 498 с.

2.Заһидуллина Д.Ф. Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы (1930-1995). – Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшрияты. – 2003.-45 б.

3. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2:XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

4. Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 3 тода. I том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – Б.135-356.

5. Мифы народов мира. Энциклопедия (в 2 томах). Гл. ред. С.А.Токарев. - М. "Советская Энциклопедия" 1998. – Т.1. А-К. – С.70.

5. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А-Г). – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

6. Яхин А., Мәһдиев М. Халык иҗатын әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе (Мәкаль, табышмак, җырлар). – Казан: Казандәүләт ун.-ты нәшр., 1982. – 112 б.

## *XX гасырның 70-80 нче еллар татар прозасында милли яшәеш фәлсәфәсен билгеләгән буыннар өчен җаваплы булу турындагы хакыйкать белдерелеше*

“Әгәр язучы татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән – ул инде татар әдәбияты түгел”, – дип яза “әдәбиятның нигезендә миллилек ята” дип инанган әдипләрнең берсе Аяз Гыйләҗев. XX гасырның 70-80 нче елларында калыплашкан икенче юнәлешне милли рухның асылын, аның буыннардан килгән эчтәлеген сөйләп биргән әсәрләр тәшкил итә. Әмирхан Еникинең “Әйтелмәгән васыять”, “Гөләндәм туташ хатирәсе”, А.Гыйләҗевның “Җомга көн, кич белән...” әсәрләре татар кешесенә васыять сүзе кебек яңгыраган текстлар.

Татар кешесен үз асылына кайтырга чакырган ***Әмирхан Еникинең “Әйтелмәгән васыять” (1965)*** хикәясе язылу вакытыннан башлап бүгенге көнгәчә татар укучысының иң яраткан әсәрләреннән берсе булып кала килә. Ике бүлектән торган әсәр тексты гүяки татар кешесенең иң тирәндә яшерелгән эчке дөньясын ача, аның үзенә дә әйтергә кыймаган серен – матурлыкка мөнәсәбәтен сөйләп бирә.

Әмирхан Еникинең “Әйтелмәгән васыять” хикәясе шәркый укылышта галәм сулышы, Аллаһ илчесе кебек кабул ителгән җил образының хикәяләүче тарафыннан тәкъдим ителүе белән башланып китә. Укучы йомшак, җәйге дип сурәтләнгән илаһи чынбарлыкны тоя, ул иркен сулышлы яңа халәткә чакырыла. Кылганнарның “акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерүендә” укучы үзенең даими халәтен танып ала. Хикәяләүче тарафыннан авторның укучыга әйтер сүзе барлыгы җиткерелә: “Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә”. “Буш, киң, тын, моңсу” дала пространствосы – автор күзаллаган укучының күңел халәтенең билгеләнеше. Хикәяләүче әңгәмәдәшнең башкорт кешесе булуын да әйтә, авторны башкорт кешесе күңелендәге аңлап-бәяләп бетерелмәгән каршылыклы хисләрнең борчуы укыла: “йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында”. Алга таба укучы пространствосында (“көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында”) барлыкка килгән персонаж галәм сулышын җиткерүче вазифасын башкара. “Ак яулык бөркәнгән, альяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына әби”

гүяки ике дөньяны – фани һәм бакыйны тоташтыручы. Аның яшәештәге төп бурычы атала: нәсел-ыру турында кайгырту, аны киләчәкле – ризыклы итү (казан астына ягарга кирәккә кизәк җыю, балалары кайтуына өметләнеп маен-күкәен җыю, итен-казылыгын каклау, шомыртын, эремчеген, корытын киптерү). Хикәяләүче укучыга акрын гына кайнап пешкәнгә чирәм исе кергән ашның тәмен әйтеп, әлеге чынбарлыктагы гармониянең серен ача. Тормышның яме – илаһи башлангыч белән билгеләнгән гамәлеңне үз көенә, кабаланмыйча башкаруда. Илаһи югарылыкта калу өчен таяныч турында мәгълүмат портрет деталенә туплана: "Сул беләгендә аның иске чиләк, уң кулында нечкә таяк". Таяк детале Миңлебай карт образына бәйле дә кабатлана. Хикәяләүче укучыга әхлакый таяныч турында искәртми микән? Иске чиләк детале, тормыш дәвамында гел кирәк буыннардан килгән яшәү тәртибе, озак гасырлар буе эзләнгән, җыела-туплана килгән тәҗрибә, бәхетле яшәү юлы хакындагы мәгълүмат дигән тәэсир кала: "Шул таягы белән ул кизәкне чирәмнән куптарып әйләндерә дә аннары иелеп алып чиләгенә сала. Тагын як-ягына карап эзләп китә. Тагын кизәкне, чирәмнән куптарып, чиләгенә алып сала..." Казан астында утны сүндермәс өчен кирәк булган кизәк детале киләчәк турында кайгыртып яшәргә бурычлы һәркем белергә тиешле яшәү кагыйдәләренең белдерелеше кебек аңлана. Димәк, буыннар тәҗрибәсен кабул итми торып, илаһи башлангыч белән билгеләнгән гамәлеңне башкару мөмкин түгел.

Төенләнештә әбинең хәле авыраю турында хәбәр итү аша хикәяләүчегә гармониянең юкка чыга баруын әйтү вазифасы йөкләнә. Бу турыда алда "авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла"дип искәртелә: "... колхоз терлекләре монда йөрмиләр, ә бәләкәй генә авылның үз бозаулары салып калдырган "беленнәр" күпме генә соң ул!" Димәк, матур гадәтләргә корылган тормышны бер төркем кешеләр генә тотып тора алмый, идеология корган яңа тәртипләр артыннан баручылар гармониягә хилафлык китерә дип укучыга гаеп ташлана. Әбинең хәле тәфсилләп тасвирланган урында хикәяләүче белән укучы бер булып сөйләшергә тиешлеге күздә тотыла. Чынбарлыкның яшәү/үлем чигенә җитүе белән бәйле укучы күңеленә моң кереп урнаша.

Күңеленә моң булып кереп урнашкан персонаж белән укучы янәшә атлый: "читән буйларында котырып кычыткан үскән тар тыкрыктан узып, бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыга".

Биредә очраган Миңлебай карт коткаручы, юатучы, үзгә юл тәкъдим итүче кебек кабул ителә. Галимнәр белән килешеп,  ап-ак кылдай сирәк сакаллы Миңлебайның Зирәк карт архетибы вазифасын башкаруын әйтеп була.

“Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабай” әбине функциональ яктан кабатлый да кебек. Укучы авылның иң карт кешесе белән инде беркадәр әзерлекле килеш очраша, тик ул әле хакыйкатьне кабул итәргә әзер микән? Хакыйкатьнең “ничә яшьтә икәнен үзе дә белми торган” карт тарафыннан белдереләчәге укучыга алдан искәртелә. Хәзер укучы ниндидер эчке борчылу, ә бәлки каядыр шом белән сүз көтә. Хикәяләүче укучының игътибарын җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә (исемнәр үзгәрү, фән-техника алгарышына) бора. Аларның  карт тарафыннан табигый кабул ителүе укучыга күрсәтелгән юнәлеш түгелме? Югыйсә, Ә.Еники ни өчен картның самолеттан бүре атып йөрүләренә мөнәсәбәтен тасвирлый. Укучыга хакыйкый үзгәрешләр кеше күңелендәге үзгәрешләр генә ул дигән мәгълүмат җиткерелә. “Кешенең үз йөрәге, үз кулы”  башкара торган гамәл генә аның хисенә үтеп керә. Үз йөрәгең белән чит әдәпне кабул итү хис-кичерешләрдә каршылык уята түгелме? Шул рәвешле, авторны борчуга салган буыннар тәҗрибәсенннән читләшкән укучы асылда үзенең каршылыклы хисләренә аңлатылыш таба.

Шул урында автор укучыны башка юнәлешкә бора. Хикәяләүче картның бу дөньяда гамәле юк икәнен әйтә. “Ул какланып беткән тәнендә бары җан асрый. Алдына куйганны утырып ашый, ястыгын тәгәрәтә дә ятып йоклый, шулай итеп гомерен суза да суза”. Димәк, карт үлем ягына борылган, укучы аны шулай кабул итәргә тиешме? Шул урында автор картның “ялан таптарга яратуын” сурәтләп, аның бу яшәештәге вазифасын тамгалый: “Һәр көнне иртәнге чәйдән соң ул, озын карагай таягын тотып, торнаныкыдай нечкә аякларын сыгылдырып кына буш урамнан уза, кырга чыга һәм күзе караган якка таба китеп бара. Берәр түбә җиргә менгәч, озын таягын ике учлап, ерак кырларга тик кенә һәм озак кына карап тора”. Укучы карт образына салынган яшәешнең бөтенлеген  саклап торучы беркайчан да югалмаячак әхлакый кануннарны укый. Еникинең Миңлебай карты кешенең гармониягә омтылышын, юлын күзәтеп торырга, бәяләргә тиешле укучы күңелендә гасырлар дәвамында уелган мәгълүмат-кануннар, буыннардан килгән ныклы нигез ул. Укучы үзендәге

“Миңлебай карт”ны табарга, аның белән килешеп гомер итәргә, ниһаять, учагындагы утны сакларга бурычлы икәнлеген таный.

Акъәби-Миңлебай картның үзара хәл белешүен укучы гармониягә омтылу кебек укый: “Юлында очраган һәр кешегә үзе башлап дәшми, ә берәрсе: “Саумы, Миңлебай бабай?” – дип дәшсә, “Ару әле” яки “Шөкер!” дип кенә узып китә”. Кеше барлык гамәлләрен әхлакый кануннар ноктасыннан бәяләп, башлап үз күңеле белән киңәшеп яшәсә генә гармониягә ирешә, хәле ару була, ди автор. Үз йөзеңне югалтмыйча гомер итү генә кешегә үзен бәхетле тоярга, җан тынычлыгына ирешергә мөмкинлек бирә. Карчыкның кыз вакыттагы сафлык-оялчанлыгын җуймавы (авызын учы белән генә каплый төшеп сөйләшүе), текстта аны Акбикә һәм килен дип атау шул мәгънәне укырга ярдәм итә: “Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап, аңа:

– Нихәл, арумы, Миңлебай агай? – диде, авызын учы белән генә каплый төшеп.

– Ә, синмени әле бу, Акбикә килен? Шөкер! – диде карт, тукталып. Җитмештән узган карчык аның өчен һаман да килен иде әле, һәм Акбикә дип тә бары ул гына дәшә, югыйсә авыл халкы карчыкны күптән инде Акъәби дип кенә йөртәләр”. Биредә А.Гыйләҗевның Бибинуры белән уртак якны билгеләп үтәргә кирәк: авыл кешесе – тирәлек Акъәби, Бибинурларга үткән заманга нисбәтле үлә баручы чынбарлык дип карый. Кешенең эчке дөньясының камиллегенә тирәлек тискәре йогынты ясый алмый, бары кеше үзе теләп үзгәрә, асылыннан китә, ди 60-80-еллар прозаиклары.

Ниһаять, укучы үзе көткән сүзне укый. Карт теле белән буыннар өчен җаваплы булу турындагы хакыйкать әйттерелә һәм текстта кайма хасил итә: “Казан астында утның өзелмәве яхшы”. Димәк, татар кешесенең әдәп-әхлагы шул бизмәнгә салына. Бу өлештә исә буыннар тәҗрибәсенннән читләшкән укучы үзендәге “Миңлебай карт”ны укып, каршылыклы хисләрен җиңү өчен җавап та таба: “Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек, – диде карт, ияк очында гына ябышып торган берничә бөртек ап-ак кылдай сакалын селкетеп. – Ярый, кортка, юлыңда бул! – Һәм карт, озын аякларын сыга биреп, китеп тә барды”. Бик күпне үткәреп җибәрә белү – җаваплылык хисен алга куеп үз юлыңның дөреслегенә ышанычны җуймау ул, ди 60-80-елларның йөзен билгеләүче әдипләр.

Хикәяләүче укучыны Акъәбинең күңел дөньясына алачык детале (йорт пространствосы) аша алып керә: “Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде”. Бу – әбинең гомер итү дәвамында үзгәрмәгән яшәү тәртибе, рухы гәүдәләнеше. Димәк, заманалар үзгәрсә дә, рух, җан үзгәрми. Ләкин хикәяләү башка якка борыла. Сынмас-какшамас кануннарны йөртүче Акъәби “урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә, бисмилласын әйтеп, сырган юрган белән ябынып, бөгәрләнеп кенә ятты”. Кешенең дөнья өчен ачыклыгын белдерү символы булган тәрәзә образына салынган эчтәлек аша укучы бу рухны билгеләүче кануннарның бетүгә дучар ителгәнлеген укый. Димәк, кешенең илаһи башлангычтан ерагаю дәвере якынлашу котылгысыз.Укучы әбинең авыруы турында тетрәнеп укый. Хикәяләүче белән укучының хисләре уртак: әлеге “утлы көл өстендә генә пешергән карлыган кагы салган куе чәйле учак” таралыр микәнни? Әбинең ябык куллары, калтыранган иреннәре шул турыда искәртәләр түгелме?

Хикәяләүче укучыны Акъәби пространствосына алып кергәннән соң, ә бәлки, шул җылыга, нурга төргәнннән соң, аның яшәү тәртибе белән таныштыра. Биредә карчык текстта хәрәкәт вазифасын башкаручы актор буларак катнаша, үз тарихын сөйли. Ул идеаллаштырган чынбарлык, аны бәхетле иткән матур дөнья болай тасвирлана: “Шушы Юлкотлыда туган ул, үскән ул, шушы Каһарман карт өенә килен булып төшкән, шушында илле биш ел яшәгән, уллар-кызлар үстергән”. Башка матурлык аңа ят. Туган җир темасына төреп автор кешенең хәтта ялгыз калса да үз асылыннан баш тарта алмаячагы турында искәртә. Димәк, иң куркыныч җимергеч көч ул – үз йөзеңне югалту диләр әлеге дәвер прозаиклары (А.Гыйләҗевның Мирвәлие, Х.Сарьянның Раббание һ.б.). Ялгыз калганнан соң карчыкның тормышы үзгәрә, рухы үзгәрми. Ул яңа чынбарлыкны идеал итә: “ асылда җәйнең бер атна-ун көне өчен генә яши ул һәм ел буе диярлек шуңа әзерләнә” .

Укучы хикәяләүче сөйләме аша карчык тудырган чынбарлыкның асылда ялган икәнлеген белә, тетрәнә. Ана яшәгән яңа чынбарлыкта газиз балалары да, оныклары да гел башка идеалларга табыналар. Полковник улының туган авылына керергә вакыты юк, аның улы Суфиян исә “бабушкасын” аңламый. Шул рәвешле автор хикәяләүче

белән укучыны тагын да якынайта. Хикәяләүченең бригадир Сәетгали турында әбинең үз балалары, шулай ук шәһәрдә аны караган докторлар белән чагыштырып әйтүе укучыны уйга сала. Сәетгалинең кайгыртучанлыгы Гөлбикәнең ясалмалыгына бәя бирү өчен кирәк: “Үтә күрсен! – диде Сәетгали, карчыкка тагын да сынабрак карап. Юк, шулай да карчыкның хәле бер дә шәпкә охшамый, йөзе лимон кебек сары, күзләре тоныкланып тора”. Хикәяләүче тарафыннан мотоциклның тавышы “бөтенләйгә тынды” дип хәбәр итү дә очраклы түгел, карчык соң мәртәбә ихлас кайгыртучанлык белән очраша. Купшы киенгән Гөлбикә кызының һәм мәһабәт гәүдәле киявенең үз-үзен тотышы укучыда чиркану хисе уята. Машинаның кара эзе асылларын үзгә идеалга алыштырган кешеләрнең үзләреннән соң калдырган кара көче кебек укыла.

Хикәяләүче сөйләмен Акъәби халәтен тасвирлау белән үреп бара. Тәрәзә капкачлары ачылу – карчыкның бу чынбарлыкка җавабы, карашы кебек аңлана. Юк, карчык балалары яшәгән чынбарлыкка күз йоммый, бары шул чынбарлыкны үз пространствосы яктылыгына күмәргә тырыша – тәрәзә капкачларын ача. Тик кәфенлеген онытып калдыруга кызының битарафлыгы аның бөтен өметләрен сызып ташлый.

Хикәяләү акрынлап карчыкның өметләре җимерелү ноктасына таба хәрәкәт итә. Карчыкның үз сөйләме белән аның чарасызлыкта калуы белдерелә: “Юк, аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына – карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде”. Яшәү һәм үлемне билгеләгән пространстволарның кечкенә дип аталышы якын, кадерле, үз дигән мәгънәне көчәйтеп килә. Бу урында Гарифә образына салынган эчтәлекне дә билгеләп үтик. Әбине ихлас кадерләгән саф күңелле кыз гүя укучыга “ияреп йөри.” Ул берөзлексез хәрәкәттә, тиешле гамәлне җиренә җиткереп башкара, Миңлебай картның ахырда аңа эндәшүе очраклы түгел. Гарифә Акъәбинең рухын саклый, аңа атап әйтелгән реплика (Аккилен кайтмадымы әле?) авторның текст ахырында укучыга “Аккиленнең исәнлеген кайгыртасыңмы?” дип мөрәҗәгать итүе ул. Акъәбине озатып калган авылдашлары, малайлар образлары кешеләрнең һәрдаим шул рухи яктылыкка сусап яшәүләре, аны югалтмаска тырышырга тиешлеге турында искәртә.

Алга таба икенче бүлектә хикәяләүче әлеге рухның юкка чыгарылу фаҗигасе турында сөйли. Кечкенә бүлмә пространствосы,

тар карават, ак түшәм детальләре, өйдәге ясалма чисталык, авыру кешегә аерым савыт-саба, балаларының аерым игътибары, докторлар китүгә кызының бик җитдиләнеп китүе – барысы да кешенең үлемгә дучар ителгәнен искәртеп торалар. Бу очракта үлемнең котылгысызлыгы куркытырга, шомланырга мәҗбүр итәргә тиеш. Укучыны шул хисләр били дә. Хикәяләүче укучыга беткәнче хәрби кеше Суфиян, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна турында сарказм белән хәбәр итә. Автор чит әдәпне үз чынбарлыгына урнаштырган Суфиянның, аларның уллары Геннадийның көлке хәлдә булуларын күрсәтә. Хикәяләүче сөйләменең актор персонажлар Татьяна, Светлана, Рита, Борис сөйләме белән аралаштырылуы яңа чынбарлыкка шул ук ноктадан бәя бирү максатыннан: "Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә киң җилкәле әкәмәт күлмәк кигән, башына вак кына чәчәкле сары яулык бәйләгән, в общем, типичная башкирка икән". Балаларның әбинең Пермьдагы зур кызын эше күп булганга чакыртмаулары, Казакъстандагы кече улын борчымаулары турында хәбәр итү әлеге чынбарыкның асылына бәя бирү өлеше дә, шул ук вакытта укучы күңелендә бу күренешкә протест тудыру омтылышы да.

Алда фаҗигане көткән укучы өчен беркадәр үзгә сурәт тудырыла. Әби "түм-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгы Гүзәл" дөньясы белән очраша, аның абыйсы Равилне дә якын итә. Алар хикәядәге аклыкны яңадан тергезергә ярдәм итә, уйга чумган укучыга яңа сулыш өрә кебек. Шул дулкын белән килеп кергән Шагыйрь образы әсәрдә авторның укучы белән сөйләшүендә яңа юл табуы кебек кабул ителә. Бу уйчан, сәер кеше авторның укучы кабул итәргә тиешле фикерен җиткерә, рухи ныклыкның нигезен ача. Аның белән әңгәмәдә Аксылу, Акҗиңгә образлары берләштерелә: "Димәк, син гомерең буе ак кеше булгансың икән… Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде". Шагыйрьнең "әсәй сакалы агарган кешегә дә кирәк икән" дигән репликасы буыннар дәвамында тупланган әхлакый кануннар, рух, аклык кешене гомере буе саклап, яклап торырга сәләтле көч дигән автор карашы кебек укыла. Иң мөһиме – саф күңеллелек кешенең бәхетле яшәешен тәэмин итүче бердәнбер көч тә. Көчле рухлы карчык бүгенгесен ничек бар шулай кабул итә, әйбәт саный, чөнки, ничек кенә булмасын, үзенә хыянәт итмәде бит. Сөйләшү иң киеренке ноктага җитә. Бәхетле булыр өчен бабайлардан килгән бөтен

яшәү рәвешен үзгәртмичә кабул итү мөмкин хәл түгел ул дип автор белән бәхәсләшкән укучыга сүз әйтелә: “... яңа заман яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәктер ләбаса!” – дип әрни автор карашын җиткерүче шагыйрь. Акъәби җавабында исә галәм сулышын җиткерүче вазифасы укыла: “Халыкныкы халыкта саклана, югалмас, Алла бирсә!” Димәк, Ә.Еники укучыга Аклыкны “рәсүлнең тырнагыдай” саклау бурычын йөкли, ышаныч белдерә. Бу ышаныч укучыны канатландыра. Текстта шагыйрьнең җырлап җибәрүе, Әнкәй куллары турындагы җылы рух тирәсендә автор белән укучы бер дулкынга көйләнә. Бу урында Тукайның “Туган тел”е искә алыну шагыйрьне, Акъәбине, автор һәм укучыны берләштерә, якынайта. Укучы күңеле әлеге бердәмлекне тоюдан яктыра, яңа эчтәлек белән байый.

Шул халәттә автор укучысына буыннардан килгән сүз-васыятьне җиткерә. Васыять – яшәү/үлем чиген үткән бәхәссез хакыйкать мәгънәсендә укучы күңелендә уелган образ. Автор белән укучы арасында мөнәсәбәтләр урнашкан очракта васыять әйтелә – укучы чынбарлыгының хис катламына үтеп керә. Бу сүзне Гөлбикә, Суфияннарның яшәү тәртибен үз иткәннәр ишетә алмый,  ди текстта хикәяләүче. Васыять, ниһаять, укучыга ышанып, өмет баглап, аңа бәхетле гомер теләп сызылган юл. Иркен сулышлы, рәхәт тормыш өчен сөттәй йомшак, саф сулы Аслы күлдә коену кирәк. Су һәм җил янәшә – яшәештәге гармонияне белдереп килүче символлар, Зыятүләк белән Сусылу турындагы миф тормышны табигый агымында тоткан буыннардан килгән мәгълүмат,  Нора тавы – хакыйкатьнең үзе кебек аңлана. Ахыр килеп, татар, башкорт кешесенә буыннар сызган юл нидән гыйбарәт соң? Бәхетле булыр өчен сине үз иткән пространствоны (туган җирне, торган җирне) якын итү кирәк. Сине чынбарлык белән таныштырган кешене – атаны хөрмәтләү кирәк. Сиңа ышаныч белдергән ананы олылау кирәк. Сине олылап торган кешеләргә рәхмәтле булу кирәк. Юлың котлы булсын дип башкаларга теләү кирәк, бәхетле булу юлын буыннарга тапшыру кирәк. Иң мөһиме – дөньяны аналарча кайгыртучанлык һәм җаваплылык тоеп ярату кирәк.

Хикәяләүдә бу өлеш Акъәби- Гүзәл сөйләшүе белән төгәлләнә. Укучы Акъәбинең Гүзәлгә әйтергә кыймаган сүзен ишетә, тагын бер кат йөрәгеннән үткәрә. Гүзәл шулай ук – авторның көтелгән укучысы. Әбинең күзләре Гүзәлнеме, зур кызын, кече улын көтеп

йомылмаганмы – ачык кала. Һәрхәлдә, автор гүяки васыять ишетелерме, саф рух югалмасмы дип борчылган ана күзләрен тасвирлый.

Хикәяләүче тарафыннан кеше соңарып булса да үз асылына кайтачагы ананы җирләү һәм сандык белән очрашу вакыйгаларында кабатлана. Ак балчык өеме янында сызланып әйтелгән шагыйрь сүзләрен автор һәркем үзенә әйтергә тиешле сүз буларак яңгырата: үз җаныгыз, рухыгыз турында ни беләсез, күңелегез сыкрамыймы? Һәркем үз намусы алдында, буыннар алдында җавап тотачак. Матурлыкны, игелекне, сафлыкны бәяли беләбезме (тәңкәле кара җилән, хәтфә камзул, тәңкәләр, муенса, чулпылар детальләре) үз рухыбызга хуҗа була алабызмы (чуклы камчы детале)? Әллә күңел төпкелендә тирән яшерелгән сафлык, игелеклелек, сабырлык кебек яшәү кагыйдәләре тормыш ваклыклары арасында югалдымы, үткәннәргә бәйле хакыйкать кенә булып калдымы? Татар укучысы күңелендә Миңлебай карт йөзъяшәр хакыйкать бизмәне булып торыр дигән автор теләге текст ахырында хикәяләүче белән укучы арасындагы күперне ныгыта, җуелмаслык итә.

Әдип иҗатында буыннарга әйтеләсе хакыйкать татар халкының йөзек кашы – рухи ныклыгы үрнәге булган тарихи шәхесләр белән бәйле эчтәлеккә дә салынып җиткерелә.

***Ә.Еникинең “Гөләндәм туташ хатирәсе” (февраль, 1975)*** повестенда “тарихи материал психологик эчтәлекле мәхәббәт турында сөйләүдә эретелә”. Әсәр эчтәлегенә субъектив образ – Гөләндәм исемле туташ алып керә, әсәр автор хикәяләве белән тәмам ителә. Хикәяләүченең мәхәббәт тарихын сөйләүгә корылган повесть XX гасырның 70-80 нче елларында милли яшәеш фәлсәфәсен үз асылыңны табу, буыннарга тапшыра алу турындагы эчтәлекне сөйләп бирә.

Әсәргә алып керү өчен хикәяләүче чит/үз бинар оппозициясе оештыра, аны үз дөньясына яшеренергә мәҗбүр ителгән кызның кичерешләр тарихы кебек алып бара. Кичерешләр сызыгы уйланулар вакыты кебек аңланган кич вакытын һәм моңсу шомлы көз фасылын символлаштыру аша башланып китә. Мифологиядә дулкынлану, рухи таяныч тоймау кебек укылган җил образы яңгыр образы (хакыйкать тамчысы мәгънәсендә) белән янәшәлектә тормыш-яшәеш тәртибенә төшенергә теләгән кешенең эзләнүләре турындагы эчтәлеккә алып керә. “Сәер тавышлар” – “дөберди, кыштырдый, ыңгыраша” –

Гөләндәмнең бу чынбарлыктан куркуын көчәйтеп күрсәтү юлы кебек укыла: “Мин, куркынып, укый торган китабымнан аерылып, колак салып тора башлыйм”. Кичерешләр рухи ныклыкка ирешә алмаган очракта (“хәерсез усал җил”) һичшиксез кайгы булачагын (“тыштагы каен ыңгыраша”) искәртү белән дәвам итә. Күңел кичерешләре таяныч тоймаганга  курку кебек тамгалана (өйнең стенасына шәрә ботаклар бәрелә-сугыла тырнаша). Интертекстуальлек (С.Җәләлнең “Дим буенда”, “На заре туманной юности”, “Яз да була”, “Туган тел”, Хәмдия”, “Казан сөлгесе, “Эрбет”, “Тәфтиләү”, “Агыйдел каты ага”, “Сибелә чәчәк” җырлары, К.Тинчуринның “Соңгы сәлам” драмасы, “Сакмар” көе, “Тукай маршы, “Мәдинәкәй” җыры, “Аккош маршы” ) әсәрнең буеннан-буена укучыны шул эчтәлек дулкынына көйләү юлы булып тора.

Кыз үзе өчен өр-яңа чынбарлык белән танышканда (“күзгә күренмәс диварга килеп бәрелгәндә”) самими бала хисләре белән яши (“өстендә гади генә ситсы күлмәк, йомшак чүәк”), үзен уңайсыз хис итә (“битләре кинәт , ут капкандай , кызыша башлый”, “чәч толымнары тизрәк артка күчерә”). Вакыйгалар барышында Салихның Гөләндәмне әлеге чынбарлыкка алып керүе тасвирлана (тар баскычтан залга төшә), кичерешләр сызыгы беренче саф хисләр тарихын сөйләү кебек алып барыла. “Зәңгәр күзле, мәрмәрдәй ак маңгайлы” ачык йөзле, “акыл сатарга, күп сөйләргә яратмый торган” Салих Сәйдәшев образы камил рухлы, җитди карашлы татар егете кичерешләрен тергезә (аның җомга көнне изге эшләр белән шөгыльләнүе). Иң элек кыз белән танышу укучыны шул рух дөньясына алып керү максатына хезмәт итә. Беренче романсны уйнаган кызга егет бәясе тормыш-яшәешкә дөрес караш тәрбияләнмәгән  кешегә илаһи чынбарлык бәясе кебек кабул ителә. Әсәр кызның гармониягә ирешү юлы кебек укыла.

Гармониягә ирешү өчен үз рухыңнан үз телеңне эзләп табу таләп ителә (Салих кыздан татарча уйнавын сорый). Телнең иҗтимагый вазифасын алга куеп, татарча сөйләшүне кирәксенмәгән укучыга иң тәүдә шул хакыйкать җиткерелә. Беренче бүлектә гашыйк кызның кичерешләренә “нәфислеккә омтылыш” теләге салына. Татар кешесенең гармониягә юлы “нәфислеккә омтылыштан”  башлана, нәфислек кешенең ана телендә уйлау, сөйләшү әдәбендә чагылыш таба, ди автор: “ ...кулың белән уйнаганны күңелең белән ишетергә генә кирәк”.  “Ак, нәфис, җыйнак куллы”  Салихның уйнап күрсәткән беренче көе “Туган тел” булу (беренче исеме “Анам кабере янында”

икәнлеге махсус искәртелә) очраклы түгел. Ифрат әдәпле, ихлас күңелле кыз Салих эшкәртүендәге “гади дә, таныш та бу көйне бозмыйча-нитмичә уйнап чыга”. Кыз үз рухына хас нәфислекне “гаҗәпләнеп, сокланып, сөенеп”ача, соңрак йөрәктә туган табигыйлеккә сихерләнә, кодрәтле моң көчен – халык зарын, ачы язмышын тоя].

Беренче “учлап карарга теләгән мамыктай, коры, таралып торган кар” – кызның үз рухын эзләве, ләкин әле “үзең теләгәнчә, тойганча уйнау” –әлеге рухның гадәткә кергән гамәлләр белән ныгытылмаганлыгы (карның укмашмавы), ягъни чит/үз бинар оппозициясенең юкка чыга башлавы турында хәбәр итә (шәл деталенә салынган эчтәлек).

Салихның үз хисләрен әйтеп бирү өлеше (”Агыйдел каты ага” тексты) яңа чынбарлыкка керер өчен кызда кыюлык, сайлаган юлга ышаныч тәрбияләү кирәклеге турында сөйли: “Сез каты аккан Агыйделне дә җиңел кичәрсез”. Көрешүгә чакыруы – кыз өчен гайре табигый вакыйга – гашыйк Гөләндәмнең хисләрен киеренкеләндерә, асылда кыюлык һәм ышаныч өсти.

Кыздагы яңа халәт – сер көтү – яңа чынбарлыкка керүне тагын да ашыктыра. Автор Салих сөйләгән сурәтләр аша кешедәге уй-гамәл гармониясе сурәтен ясый. Татар кешесендә туган гармония – аның бәхетле-тигез тормышының матур гадәтләре, эчке моңы, ди автор. Гамәлдә шуны тергезмичә торып татар кешесе рухи ныклыкка ирешә алмый. Шул моң татарның хөрлеге, аның җыры (“Сибелә чәчәк” тексты), даими күңел халәте.

Кызларның театрга киенүләре үзләрендә яшәгән эти-әниләре тәрбияләгән тарлыктан милли рух табылган хөрлеккә чыгу юлына басулары кебек укыла.

Гөләндәмнең эчке, күңел пространствосы, сюжет ситуацияләрендә ачыла торган холык сыйфатлары белән иске тормышның реаль урын контурлары бәрелешә. Кызның “гарип булса да, кызгану хисе уятмый торган, мескенлектән бик өстен булган” Ф.Әмирхан белән очрашуы кешелек горурлыгы турында искәртүче тагын бер вакыйга. Татар яшьләре оештырган кичәдә катнашу кызның кыюсыз, куркак чынбарлыгына яңа эчтәлек өсти. Салихка мәхәббәте аша Гөләндәм тагын да ачыла, ектыра төшә, “Соңгы сәлам” спектаклен тоюы шул хакта сөйли: “Ольга барысын да этиләре белән уйлашып, киңәшеп эшли! Нинди мәхәббәт була соң инде бу?!” Укучы эти-әнисе

тозагында яшәргә күнеккән Гөләндәм күңелендә туган хис үзгәрешен тоя, ләкин автор Вахит-Ольга язмышының кабатланачагын Салих сүзләре белән искәртә: "Бигрәк тә дин һәм милләт аермасы гашыйкларны әнә шундый фаҗигагә китерә дә... Әйе, авыр фаҗига, тамыры бик тирән әле".

Кызның ябык пространстводан ачык просранствога омтылышын пейзаж бирелеше хасил итә: "Тышта галәмәт буран икән ләбаса! Шул дөньяга сыя алмыйча котырына, имеш! Буран гаепле моңа, буран шулай саташтыра, буран җөтен нәрсәне йә бик якынайта, йә бик еракка алып китә. Менә буран басылгач, барысы да үз урынына кайтыр, һәм мин дә бәлки бервакыт чын дөресен генә белермен. Чын дөресен?! Әмма кирәкме соң ул "чын дөресен генә"? белү, кирәкме? Нәрсә китерер ул миңа – сөенечме, әллә көенечме?" Үзе яраткан "Сакмар" көен уйнаганда кызның әтисенә эчке эндәшүендә дә шул укыла: "Зифа талдай үсеп җиткән кызыңның үз бәхетен үзе сайларга хакы юкмыни, әти, җаным, бәгърем?!" Кызның елавы – героиняның иркенлеккә таба хәрәкәте, хис үзгәреше, җан сызлавы ул. "Буранлы көн" кызга юл ачучы Сабираның "бик кадерле, бик яшерен серен фаш итү" белән төгәлләнә.

Салихның алдагы уйнаган көе беренче хәлфәсе З.Яруллинның "Тукай маршы" булу очраклы түгел. Салихның хәлфәсе турында "бернинди ясалу-кыланусыз сөйләп чыгуы" кызны сокландыра, башка дулкынга көйли, Гөләндәм Салихның Тукайны күрү-күрмәве белән кызыксына. Шул урында Салих исеменнән автор кеше күңеле омтылырга тиеш үзгә халәт – "халык күңелендә мәңге яши башлау" омтылышы турында әйтә: "Күпме уй-хис бу музыкада! Олы хәсрәттән тирән әрнү бар, хәтта тәкатьсез үксү дә ишетелеп кала, әмма шул ук вакытта ул кешенең рухын төшерми, өметсезләндерми, киресенчә, аны үстерә, дәртләндерә, гүя зур-зур эшләргә канатландыра!.. Ихлас!Ә менә бу җирендә – тыңлагыз әле, тыңлагыз" Нindидер бер тантаналы горурлык яңгырый түгелме соң?! Тукай өчен, Тукайны тудырган халык өчен горурлык – ишетәсезме зез шуны?" Димәк, үз халкы белән горурлану хисләре һәр кешенең күңел таләбе, үз асылын табуга, тануга юлы икән.

Милли проблематиканы иҗтимагый мотивлаштыру әсәрдә пейзаж бирелешенә салына, "чыкылдап торган татар оясы Печән базарында" – "Евангилистовский белән Захарьевский чатында зур гына ак чиркәү, вак кына мәчетләр" шул эчтәлекне укырга әзерли.

Салихның чиркәү янына җыелган гарип-гораба саилчеләргә карап торуы авторның укучысы ярдәмендә чынбарлыкка бәясе кебек кебек укыла. Кыз белән егет барган Болак күпере – авторның Салих ярдәмендә укучысын яңа милли чынбарлыкка таба алып бару юлы. Кеше гармониягә омтылганда билгеле бер көй дулкынына көйләнә, шул көй аның үз-үзе белән гармониягә ирешүен көчәйтә, ныгыта, ди автор: "Тик безнең мәчетләр генә музыкадан мәхрүм. Шәригать дигән нәрсә мәчеткә курай белән сорнайны гына керткән булса да, дин әһелләре музыкага бу кадәр тискәрпе карамаслар иде. Ә шуның аркасында без күпме артта калдык". Азан көенең мәгънәсен бирү аша автор кешенең бу дөньядагы тормышына әһәмият бирергә тиешлеген тамгалый кебек: "Гаҗәп сагышлы, моңлы ишетелә шул чакта кичке азан! Гүя фани дөньядан аера ул сине, уйлар, өметләр – барысы да бик кечерәеп кала. Тик соңыннан гына бик ямансу булып китә, тизрәк үзебезнең шул гөнаһлы дөньяга әйләнеп кайтасы килә... Дөнья кызыклырак бит, Гөләндәм!"

Гөләндәмнең Фәйзи Биккинин, Мансур Мозаффаров, Солтан Габәши, Кәрим Тинчуриннар белән танышуы – Салих чакырган хөр рухлы, матур чынбарлыкка аяк атлавы ул. "Шәрык кичәсенә әзерләнү, кичәдәге чыгышлар кызга бу рухны бик кын итәргә, яратырга мөмкинлек тудыралар. Салих белән башкарган "Мәдинәкәй" җыры – мәхәббәт көче, аның башкаларга тәэсире турында сөйли. Шул вакыйгадан соң Салихның Гөләндәмгә "иң саф, иң мөкатдәс" хисләре әйтелүе очраклы түгел.

Чит/үз каршылыгын үтә баручы кызның курку белән тулы дөньясы ачыла, эчке калтырану аркасында тән авыруы кичергәннән соң, кыз башка чынбарлыкка күчкәнлеген аңлый: "Инде менә күзләрем ачылуга гаҗәеп дөнья үзенең кояшы, тәрәзә башында гөрләгән күгәрченнәре, әллә каян гына килгән серле өннәре, гел алышынып торган төс-бизәкләре, онытылмаган хатирәләре, сүнмәс өметләре белән әкрен генә миңа да кайта башлады". Укучы кызның "офыкта кабынган бердәнбер йолдызын" табуын – үзен, үз нәфислеген, матурлыгын тануын тоеп ала.

"Көтү, ышанып, сагынып көтүне кызлар эше" дип инанган Гөләндәм әнисе тәкъдим иткән чынбарлыкка – утарга "затлы күлмәкләренең берсен дә алмаска" – яңа затлы чынбарлыгына хыянәт итмәскә карар кыла. Идел-чикне кичкәндә кыз шул яңа чынбарлык алдында сынала. Салих белән очрашу, шул көйләр серенә уралу,

мәхәббәтнең көчен тою – Гөләндәм-Гөлгенәне бәхетле итә, ышандыра. Ләкин горур-сабыр Салихның эчке рухи ныклыгы (утарга барудан баш тартуы) Гөләндәмгә аңлашылмый, ягъни кызда ачылган гүзәллек әле үзен сакларлык булып нығымаган, горур-сабыр рух гамәлләр белән гадәткә кермәгән. Салих аерылганда уйнаган "Аккош маршы" укучыга шул эчтәлекне әйтеп бирә.

Гөләндәмнең Газизгә кияүгә чыгарга каршылык күрсәтергә тырышуы – беренче зур сыналуы. Салихның моңа каршы җавабында "мәхәббәт кенә түгел, уртак теләкләр дә бәйләргә тиешлеге" автор карашы кебек тамгалана. Ә.Еники "бәхеткә илтергә тиешле юл" – кешенең үз көен, рухын, ахыр килеп, матурлык тудыра ала торган гамәлен табу дип күрсәтә.

"Европачарак киенергә ярата торган, Сембердә туып үскән" сабыр гына, ярашырга күнеккән Гөләндәмнең әнисе һәм "күп очракта әнисе белән килешергә мәҗбүр" әтисе "хатын-кызның мәхәббәте ул күп вакытта ир-ат мәхәббәтенә җавап рәвешендә туа" дип буйсынуга көйләнгән чынбарлыкны яклаучылар итеп тәкъдим ителә. Шул чынбарлыкта тәрбия алган, шул дулкынга көйләнгән Гөләндәмгә, билгеле, зур сынаулар үтәсе әле, Салихка китәргә җыенган кызның "әти-әнием ишетеп-күреп яталар кебек тоелды өзгәләнеп торуымны" дип автор аны куркуын, кире уйлавын нигезли. "Рухы сынган, тәкъдиренә буйсынган, язмышы белән килешкән" чит дөньяга кайтып утырган кызны гомерлек үкенеч көтә. Эпилогка урнаштырылган автор сүзләре шул хакта. Ә Еники, кеше бары үз хисләрен яклый алса, үз рухына туры килмәгән чынбарлыкка каршы төшә алса гына, гармониягә ирешә, үзен бу дөньяда хөр һәм бәхетле хис итә, ди.

Һәр татар кешесенә бәхетле, хөр, иркен яңа тормыш кору өчен буыннар хәтерен – аң төпкелендә тупланган горур-сабыр яшәү тәртибен табу зарур, ди А.Гыйләҗев (1928-202) буыннар хәтерен үзендә туплаган Бибинур аша.

***А.Гыйләҗевның "Җомга көн, кич белән..." (март-октябрь, 1979)*** повесте – әдипнең әдәби васыяте. Автор укучыны әсәрне кабул итүгә көчле позиция – исемгә чыгарылган мәгънә белән көйли. "Күкләрдә бәйрәм ителүче, Адәм г.с. туган, җәннәткә кергән, шулай ук кыямәт көне булачак" җомга көне – җыелу көне, атна дәвамында кылынган гамәлләргә хисап бирү вакыты кебек уйланылган. Татар-мөселман рухына автор шул вакытны исемгә чыгару белән үк алып

керә. Повестьның исемен укуга, укучы бер мәлгә уйланып куя, әсәр текстыннан түземсезләнеп фани дөньядагы гамәлләргә бәя булып яңгырар дәрәҗәдә яңа сүз – дога көтә башлый. А.Гыйләҗев алдан ук татар рухына һәр татар кешесенең табигатенә салынган, димәк, үзенә бәйсез яши торган сыйфаты – Илаһи көчкә үз язмышыңны тапшыру хисе аша эндәшә. Көн дәвамында булган хисләр бер бәйләмгә тупланган кичке вакыт – уйлану мәле. Шул рәвешле, автор дога укыгандагы халәткә – тын калып уйланырга чакыра.

Алдагы көчле позициядә – эпиграфларда автор укучысы белән һәркем өчен кадерле, газиз кыйммәтләр ярдәмендә сөйләшә. Беренче – авторның үз сүзләре дип тамгаланган эпиграф махсус рәвештә татар кешесе өчен ят булган Вальпараиса, Галлопогос, Титикака, Куала-Лумпур кебек атамаларны яңгырату белән башлана. Бу атамалар никадәр ят булса, "Аксыргак авылы, Ташлыяр елгасы" шулкадәр үз тоела. Билгеле, укучы авторның "кадерле булганга күрә шәбрәк яңгырый" дигән сүзләре белән килешә. Әдип татарның үзенә бәйсез яши торган тагын бер ягын – нәселне туплап торган урынга изге (сакраль) дип каравын ача һәм укучыдагы шул хисне кузгатып куя.

Икенче эпиграфта автор бу хакыйкатьне Габдулла абый Юсупов сүзләре белән раслап куя. Татар кешесенең аң төпкелендә үзеннән өлкән кешегә ихтирам, аның сүзенә колак салу тиешлеге урнашкан. Автор Габдулла абый Юсупов образын "тәҗрибәле кешенең" ышанычлы сүзе буларак кертеп җибәрә, олы кеше "җылавының" сәбәбен укучыдан эзләтә: " Бу тарихны ишеткәч, мин ул әбинең болдырына утырып озак кына җыладым..." Бусага (болдыр) мифологиядә кешенең үз дөньясы белән аңа чит-ят дөньяның чиге буларак кабул ителә. Димәк, "җылатырлык" тарихның эчтәлеге башкалар дөньясында үз асылына урын таба алмаган кешенең хисләре белән бәйле булачагы искәртелә. Бу кешенең эчке, рухи дөньясы - йорты япа-ялгыз, аның күңеле башка дөнья өчен ябык – тәрәзәләре "томаланган". Әбинең бу яман халәте күптәннән үзгәрешсез: "ихатада башка корылмалар күптән ишелеп беткән". Кеше һәм дөньяның трагик каршылыгын символик белдерүче көзге үтә шомлы төн вакыты образы укучы күңелендә шөбһәле көтү хисе урнаштыра: "Көзге үтә шомлы төн иде".Укучы игътибары каен бастырмалар деталенә юнәлтелә. Татар һәм башкорт мифологиясендә киң таралган каен-кайгы укылышы аша автор сак кына әби язмышын милләт язмышы кебек гомумиләштерә: "Караңгы булса да, череп укмашкан саламны

әрсез җил иркенә бирмичә түбә өстенә рәт-рәт тезелешеп яткан каен бастырмалар аермачык күренеп тора иде”. Татар хәсрәтенең нигезе – аның аң төпкеленә укмашкан дәшми тору сыйфаты (череп укмашкан салам) ул. Шул ук вакытта аның йортының түбәсен саклаучы да шул (каен бастырма), ягъни аның рухи нигезен түземлелек кенә әрсез җил иркенә бирмичә - “коточкыч юкка чыгудан” саклап тора. Бу – караңгыда да күренә торган көн кебек ачык парадоксаль хакыйкать, ди әдип. Татар кешесенең табигатенә салынган түземлелек иҗтимагый шартларда (башкалар дөньясында) аны бәхетсез итә, ләкин, үзе булып калырга теләсә, татар башкача була алмый. Укучы олы кеше “җылавының” сәбәбен табуга якынлаша. Автор ничек үзгәртергә мөмкин соң алайса, дип өзгәләнгән укучыны бөек рухның җимерек нигезе белән саубуллашканчы борылып карарга чакыра: “Карчыкның бөек рухы, җимерек йорты белән саубуллашып китә башлагач, борылып карадым...” Татар кешесен чиксез – серле, без белмәгән мәңгелеккә илтүче як – бик иртә өзелгән өметләргә (сабый бала беләге юанлыгы иртә киселгән ап-ак каен кәүсәләре) бәйле моң. Мәңгелек хәтерендә татар кешесенең сәҗдәгә китеп уйга чумган халәтеннән бер хис уелып кала – татар аны моң, ди. Үзен кем дип атаса да, татар каны булган кешедә шул хис үзенә бәйсез рәвештә яши, аны кабат-кабат “сәҗдәгә китеп” үз асылы турында уйланырга – “җыларга” мәҗбүр итә, ди язучы: “...сәҗдәгә чүккән өй дә, аның ак төшкән йомык тәрәзәләре дә юк иде, әнә шул, сабый бала беләге юанлыгы, иртә киселгән ап-ак каен кәүсәләре генә караңгылык елгасында мыштым гына, каядыр, серле, без белмәгән мәңгелек елгасына таба йөзәләр төсле тоелды”.

Соңгы сүз татар халкының үзеннән әйттерелә. Өченче эпиграфны автор “татар халкының яраткан җыры” дип билгели:

“Уф, йөрәгем!..” димәс идем,

Янулары басылса...”

Моң халәте татар кешесенең даими эчке халәте, ахыр килеп, аны олы сабырлык юлына алып чыгучы хакыйкать, ди әдип.

Беренче бүлектә автор укучыны вакыйгаларга шул рухи югарылыктан – “өстән, тауның иң биек ноктасыннан карарга” чакыра. Аксыргак авылына җитәрәк Ташлыяр елгасының икеләнеп калуы укучыны шул урында туктап уйланырга өндәү кебек укыла. Тормыш-яшәештә туктап уйланырга – кодрәт белән сызып куелган Ташлыяр елгасына килергә – буыннар кодрәте белән сызылган хакыйкатьне

барларга тиешле “аксыргаклы – “әчкелтем” “чиккә урнашкан” мизгелләр бар: “нәкъ көнчыгыштан көнбатышка таба шактый җәенке төпле үзәнне урталайга бүлеп телеп ага-ага да, Аксыргак авылына җитәрәк, икеләнеп кала; боргалана башлый, алай гынамы сиңа, ындыр артларына сырышып, куе кучкылланып үскән таллар арасына кергәч, беразга күздән югалып та тора”. Уй-кичерешләр гавәмында (“куе кучкылланып үскән таллар арасында”) калган кешенең шактый җәенке төпле тормыш үзәнендә беразга күздән югалып торган мәле бу, ди әдип. Гомернең нәкъ менә шул мәле кешене рухи югарылыктан – таудан бәреп чыккан якты юлга – барлык хисләр бәйләме – биш чишмә ачылган хакыйкый яшәешкә алып чыга да инде: “Авылның Түбән очына җиткәндә, Аксыргакның таудан бәреп чыккан биш чишмәсен дә үзенә алып, тагын ачыла Ташлыяр”.Тормышны якты дулкынга көйләп җибәрү өчен вакыт-вакыт күңелне юк-бар ямьсез хисләрдән арулап тору кирәк, шул очракта кеше матур уйлар белән тулы яңа яшәеш – тугай ясый, әлеге яшәеш кешене иркен, көр тавышлы итә, ашыктыра, көтмәгәндә юлын башка уңайга бора – өч өй – өч пуҗум иясез кала: “Түбән очта нигәдер үксезләр, толлар һәм фәкыйрьрәк хуҗалыклар яши, ярдагы талларны кышлыкта утынга кисеп бетерәләр, елга ишәеп кала, киңәеп бер урында иркен сулыш ала – тугай ясый, аннан кинәт тарая, ярлары текәләнә, агымы шәбәя, ярга бассаң, аккан тавышы ишетелә башлый, һәм ашыккан агым, авылның Зәйгә чыга торган очында өч өйне аръякта калдырып, кинәт көньякка юл ала”.

Милли проблематика бу урында иҗтимагый мотивлаша. Зәйдә салынган ГРЭС һ.б. “гигант төзелешләр” “чуар йөрәкләрне” – нәсел-ыруны башка максат белән туплый: “моңарчы йөрүне яратмаган, үз авылыннан кыз алып, үз авылына кыз биреп яшәгән Аксыргактан да бик күпләрне үзенә суырып алды, авыл уртасындагы дәрәҗәле урыннарда да буш ихаталар ешайды, йорт хакы шалкан бәясенә төште”. Шалкан бәясенә төшкән борынгыдан килгән яшәеш тәртибенең нигезендә тора-бара үлем – кәлтә еланнар арка җылыта башлый: “Зәй юлы өстендәге өч пуҗум байтак елларга иясез калды; анда-санда тырпаеп калган усак баганалар череп ауды, баз урыннары ишелде; ишегалды, мунча урыннарын кычыткан, ак әрем һәм алабута басты. Нигез ташларында җәй буе кәлтә еланнар арка җылыттылыр”. Димәк, бушап калган дөнья – кичерешләр кешене үзгә дулкынга көйли. Әлеге дулкынны үз кулына яңа хуҗа ала: “...җир, мөгаен генә,

шактый еллар шулай буш килеш ятар да иде, колхозга яңа председатель килде” .

Автор укучыга алдан ук “Аксыргакка беренче тапкыр читтән килгән” председатель матур уйлы, якты күңелле, “ачык тәрәзәләрне ярата торган” Җиһангир Сәфәргалинның “чит” кеше түгел икәнлеген искәртә, раслап та куя. Җиһангир Сәфәргалин “урман артында озын бау булып сузылган бер генә урамлы Тегәрҗеп авылыннан” “район читендә, чиккә урнашкан, төньягында юаш таулар тезмәсе, тау өстендә кара урман” булган Аксыргакка килә. Әдип түземлелеге, моңлылыгы белән юаш табигатьле (юаш тау-рухлы), ышанучан, буйсынырга, яраклашырга әзер торган татар кешесенә ярык тагарак алдында (өмет белән өметсезлекнең әче чигендә) калмас өчен урман-тормыш артында озын бау булып сузылган бердәнбер хакыйкатьне буыннар аша җеп итеп сузу бурычын Җиһангирга – “җиһанны яулар” иргә тапшыра. Сәфәргалин яңа идеология сөреме агулаганга (ике район колхозы аерып торганга) чынбарлыкны тоймаучы “аксыргаклы” татар аңын үзгәртер өчен сәфәр чыга, “гали” буларак вакыты җиткәч көтмәгәндә күздән югала.

Алдагы өлештә автор яңа хуҗаның гамәлләрен бөртекләп санап, рухи кыйблага – “тау ягындагы алачыкка, тау өстендәге урманга” юлның моделен кора, ягъни татар аңын үзгәртү юлын тәкъдим итә. Юл башын уй- кичерешләрне тәртипкә салудан – “иң әүвәл урам-тыкрыкларны рәткә китерүдән” ярган Җиһангир Сәфәргалин яңа заман (70 нче еллар) казанышларыннан урынлы-урынсыз файдалануны тыя: “...тракторларның эресен-вагын ел әйләнәсендә урамга керүдән катгый тыйды”. Уй-кичерешләрне тәртиптә тотар өчен чик-чама белү, күңелеңне саф килеш саклау (“урам як коймаларын, өй түбәләрен тиешле тәртиптә тотуны таләп итә башлады”), ният-гамәлләреңнең мәңгелек хәтерендә язылачагын тоеп, вак-төяк мәкерле-ямьсез уйларны якты дулкынга көйләп бору, үзгәртү тиешле (“ермакларны, вак-төяк мәкерле коры сызаларны күмдереп, бик күп җирләргә агач утырттырды”). Инде яңара башлаган хуҗалыкларга – уй-кичерешләренә хуҗа булып, матур уйларны – үсентеләрне, аларның тамырларының ныклыгын-тирәнлеген кеше үзе һәрдаим бер дә иренмичә, вакчылланып, бәби белгән төсле тәрбияләп торырга бурычлы: “агач орлыкларын, үсентеләрне юллар үзе тапты; бер дә иренмичә агач чокырларының тирәнлеген, киңлеген көрәк сабы белән вакчылланып тикшереп йөрде; тамырлары имгәнмәсен өчен нәзек,

зифа каеннарны бәби биләгән төсле генә күтәреп йөртүләрен үтенде, тәртип бозучыларга каршы шәфкатьсез дә була белде. Һәр татар кешесенә – “югары очына да, түбән очына да” бәхетле, көр, иркен яңа тормыш кору – “тау ягындагы алачыкка, тау өстендәге урманга выж да да выж җәен-кышын үтеп йөрү өчен” кодрәт белән сызылган буыннар хәтерен – “Ташлыяр аша тимер култыксалы таш күпер күпер койдыру” тиешле, ягъни аң төпкелендә тупланган горур-сабыр яшәү тәртибен гомерлеккә кою-урнаштыру зарур. “Җимерек күпер –холык иясе булганлыктан” – ярашырга әзер торганлыктан, “яз саен “менә китәм, менә китәм!” дип куркытып дер калтыратып торган” горур-сабыр татар рухын саклап калу өчен сынмас рухлы-култыксалы таш күперне татар тарихында – “Аксыргак тарихында беренче буларак” салу вакыты җитте, ди әдип.

Зират коймасын ныгыту, урам чатларына лампочкалар элдертү – шул рухны дәвам итү, буыннарга үзгәртмичә тапшыру эчтәлеге: “утлар кич саен янып тормаса, монтерга бик нык эләгә иде”.

П.Дьель күрсәтүенчә, “ихлас теләкләрнең иң югары дәрәҗәгә җитүен – игелек кылу омтылышын символлаштыручы су образы” әсәрдә үтәли образ булып тора. “Ике кулын көч белән як-якка селтәп йөрергә” күнеккән эшлекле Җиһангирның “соңгы мактаулы эше” “Ташлыяр кинәт тарайган урында елганы будырту” гамәле булу да очраклы түгел. “Казларга чумарлык, киленнәргә рәхәтләнеп кер чайкарлык, ә кайберәүләргә арык шавын тыңларлык булсын!” дип кылынган игелек җиһанда татар хәтерен яуларга, мәңгелеккә уярга килгән ир сәфәрен тәмам итә: “Диде дә моңлы күзләрен тутырып карап тынып калды...” Ф.Порталь билгеләвенчә, мисырлылар малай-ул сүзен язу өчен каз рәсеме ясалган иероглифны файдаланалар, каз Җир белән Күкне тоташтыручы, нәселне дәвам итүче мәгънәсендә укыла: “Казлар буага су тулганны да көтмәделәр, “как-как” – дип мең авазга куанышып буа өстенә кереп тулдылар. Башта сыеша алмыйча талашып, чукышып маташканнар иде, су җәелгән саен аларга урын киңәйде, казлар аерым-аерым ак утраулар булып куанышып йөзә башладылар”. Бибинурның казлар асрарга теләвендә дә шул эчтәлек табыла. Каз – татарның сый-хөрмәт ризыгы да, түшәк-ястыгы да, ди автор: “Җиһанда татар халкының уллары ак утраулар булып матур гаилә корсын өчен – чукышмасын, талашмасын өчен “су җәелүе” – горур-сабыр олпат рухны кайтару, үз фикерле, якты уйлы булу кирәк. Ахыр килеп, шундый милләт кенә “бәләкләре белән тукмап-тукмап кер

юарга килгәч, бер-берсенә куанычлы сәлам бирә торган киленле” гаиләләргә, шул киленнәр (Бибинурлар) тәрбия итә торган асыл улларга лаек.

А.Гыйләҗев Җиһангир тавышын автор тавышы кебек яңгырата, буыннардан килгән, ләкин әлегә ишетелми торган өн икәнлеген дә ямансулап күрсәтеп үтә: “Каз тавышы, бәләк тавышы яңгыраганда арыкның акрын гына тавышлана башлавын ишетмәделәр дә әле. Арык шавының кемгәдер, кайчандыр хәҗәт буласын, әлбәттә берәү дә уйлап карамады; Җиһангирның сүзен уен-көлке, мәзәк дип кенә кабул иткән кешеләр аны шунда ук онытты лар да...” Җиһангирның васыяте кебек укылган сүзләр аша автор укучысына якты өмет баглый, әлеге җан авазын тамаша дип кабул итмәскә өнди: “Тамаша карарга буа алдына байтак кеше җыелган иде.

– Баегач, мәңгелек итеп, тоташ бетоннан коярбыз буаны, - диде ул аларга карап. – Һәр буын авылга, аерым алганда колхозга, үзеннән ниндидер мөһим яңалык өстәргә тиеш. Шунсыз авыл кешесе үзен колхозда көзен бәрәңге алырга килгән студент-кунак итеп кенә тоячак! Әйдәгез, тамагыбыз туйды, без яшеллек турында, урамнарыбызның һәм күңелләребезнең яктылыгы турында, җыеп әйткәндә, матурлык турында үз буыныбызга хас рәвешчә кайгыртыйк. Байлыгыбыз бар, алда авыл халкы тагын да мулрак яшәячәк.Безнең буын байлыктан дошманлык, карунлык, мещанлык, күремсезлек түгел, нәкъ шуларның киресен, туганлык һәм матурлык тойгылары тәрбияләү юлын эзләп табарга тиеш. Байлыгыбыз бары тик яхшылыкка, иминлеккә һәм дуслыкка хезмәт итсен! Бүгенгә төп бурычыбыз шул. Байлыкка саклык аша барырга кирәк!” Хикәяләүче укучыга мөрәҗәгать итә: “Күрешүе идеме бу аның, хушлашуымы?” Бу сорауга укучы үзе җавап бирергә тиешле, Җиһангир-автор сүзләренең күңеленә үткән кадәрен укучы үзе генә әйтә ала. Автор тагын бер кат укучысына ышанычын теркәп куя. Сәфәргалинга карата анонимка әзерләп куйган Габдрахманов “буа буенда халыкка кушылып, уч төбе авыртканчы кул чапты да ашыга-ашыга кайтып җитеп, хатларын дөрләп торган утка тыкты һәм, гомердә булмаганны, күңеле нечкәреп, хатынын куенына алып тынычланып йоклады...”.

Ниһаять, бушап калган өч пуҗум урыны “койма белән әйләндереп алынып, бөтен кишәрлеккә каен аралаш яшь чыршы күчереп утыртылды. Биредә урын алган дүртпочмаклы мәрмәр һәйкәл, “тәрәзәләре буа өстенә караган” почта бүлекчәсе детальләре аша татар

кешесе үз асылын югалтмас өчен хәтерен-байлыгын сакларга, илаһига омтылышын – горурлыгын җуймаска тиеш, ди А.Гыйләҗев. Бу татар моңын-күңелен (каенын) мәңгелектә тамгалаучы (яшь чыршы) бердәнбер сакраль юл.

Шул урында А.Гыйләҗев автор тавышын ишетүче көтелгән укучысы образын кертә: “Буа тавышын шул чагында беренче тапкыр аерымачык ишетте Бибинур карчык”. Димәк, алдан ук укучысын рухи кыйблага көйләп, һәр татар кешесенең аң төпкелендә тирән яшерелгән шул “нур-яктылык хуҗасы” на сагынып эндәшә әдип. Шул рәвешле, Бибинур образы – татар күңеле, аның эчке, бик тирән урнашкан якты дөньясы, тирәлектә үз кирәген таба алмый сыкраган йомшак-нечкә күңеле ул. Бер сөйләшүдә А.Гыйләҗев: “Бибинур ул – мин үзем”, – ди. Автор әлеге образы аша һәркем күңеленең “орчык башы хәтле бәләкәй генә” якты ягы, нуры белән сөйләшә, аны кузгата-елата, эчке нурның тышкы гәүдәләнешенә өмет баглый, икенче - кешедә үзе тәрбияләгән ямьсез якның-гамьсезлекнең әлеге саф, якты нурны юкка чыгармаска тиешлеген сыкранып әйтә. Замана шаукымы нәтиҗәсендә никадәр генә тирән яшерелмәсен, кешенең якты асылы бер кузгалмый калмый, Галәм сулышы-җил аны кузгатыр җай таба: “Бибинур карчык, ямаулы оек үкчәләрен мәрхүмнең ике ягына тәбәнәк эскәмияләргә тезелешкән якыннарына күрсәтмәс өчен, озын күлмәк итәге белән аякларын туктаусыз төреп азапланса да, җил итәкне каерып ачты, туктаусыз исеп, көчәеп торды”.

Автор берөзлексез үзенең укучысын шул рухи кыйблага каратып тота: “Тау башына менеп туктагач, ул ирексездән аска, Аксыргак авылының күз күнеккән чуар нокталарына һәм зур булып, җәйрәп яткан буага карады”.

Галәм сулышы буларак мәхәббәт турындагы хакыйкать яктыртыла. Повестьның төп мотивы да шул – олы сабырлыкка китереп җиткерүче ярату. Бибинурның Җиһангирны күмгәндәге укыган догасы – “моңарчы барлыгы да беленмәгән гаҗәеп кадерле сүзләре” кеше күңеленең яраткан мәлдә ачылган нурлы ягы, көчле ягы кебек укыла. “Кичерешләрнең тирәнлеген, хисләрнең үткенлеген күз яшьләре белдерә”. Әсәрнең буеннан-буена Бибинур, укучы, ниһаять, автор үзе елый. Һәр елау бер хакыйкатьне ача, төгәлрәге, күңелендә мәхәббәт йөрткән кешедәге халәтне атый. Бибинурның (укучының) беренче елавы “ятимлектән” “тома ятимлеккә” күчү белән бәйле: “Ятим, япа-ялгыз, кем өчен еласын, байтактан күзләреннән яшь

чыкканы юк иде, бүген күз төпләре рәхәт кычытып дымланды”. Психологик портрет алымы белән кешенең асыл зат, бала-нәнә белән хушлашкандагы халәте теркәлә: “Хуш, Җиһангир, балам, хуш, асыл затым, хуш нәнәм! Мәңгегә хуш!” – дип, байтак үрсәләнде Бибинур”. Биредә автор “күз яше кибеп бетмәгән, җанында җылы калган” кешенең кадерлесен югалткан вакытта чарасызлыктан елавын тасвирлый. Мондый елау, кагыйдә буларак, кызганудан килә, бу вакытта эчке потенциал ачыла, тик кеше әлеге көчне тояр хәлдә түгел, аның кемгә булса да сыенасы килә: “Тик аны нигә бирәү дә дә күрмәде соң?” Бу – кешенең вакыт-урынга бәйсез чагы – асылда өмет-өметсезлек чигендә калган кешенең ачыла башлавы, яңа юлга басар алдыннан үрсәләнүе.

Бу урында автор укучыга төш психологик алымы белән мәхәббәт белән бәйле алдагы эчтәлекне әйтеп бирә. Мифологиядә илаһи бер зат буларак Җирдән Күккә иңгән саф, ихлас, гөнаһсыз җанның талпынышы дип укылган “ямь-яшел болында иртәнге томанда чабышып йөргән ак атлар” өстендәге куе ак томан Каф тавы артындагы колыннар турында – әлеге яктылыкның билгесез үткәнгә мөнәсәбәтле хакыйкать икәнлеге хакында хәбәр җиткерә. Бибинур исеменнән автор сыкрана, “иреннәре йомык, ачылмаса да, аларны Убырлы карчык (идеология) пичәтләп киткән булса да”, автор укучының зирәклегенә ышана, “күлмәге аркасына җилкән кебек киерелгән җиту чәчле малайның җирән айгырга менеп алып җилдерүе” аша әлеге хакыйкатьне чынбарлык сызыгына күчерә сыман. Бу урында автор күбәләк детале ярдәмендә Бибинур дөньясының башка үлчәмгә күчүе – рухның тәнне дәвалау юлына басуы турында хәбәр итә. Димәк, җан-рух үзенең эчке потенциалын тоя (шырпы кабында ясалган колынын иярткән ап-ак ат сурәте), ләкин әлегә тану дәрәҗәсенә җитәр өчен тагын елау көтелә: “Әллә җаным, чыннан да, күбәләк булып кына Җиһангир артыннан очып килдеме?”.

Башка үлчәмгә күчкән рух чистарыну сорый: “утны һәм җылыны ярата торган” Бибинур учак яга. Мифологиядә кояш нурларының җылысын үзендә туплаган, Аллаһның чагылышы кебек аңланган ут – “нәни генә җилфердәгән учак” яктысында илаһига омтылган җан “караңгылыктан сүз көтә”. Автор Сүзне Җиһангирның этисе Вәли карттан әйттерә. Татар мифологиясендәге ак сакаллы карт вазифасын башкаручы “кызыл сакаллы Вәли карт” [3:221] Бибинурны олылый, “ут иясе” дип атый, чәй эчәргә дәшә. Чәй өстәле татарның җылы,

түгәрәк дөньясын символлаштыра: “Карчык ике читеннән сак кына чеметеп сәкегә кызыл ашъуялык җәйде, уртага пыяла савыт белән акмай, агач капламыч белән бал китереп утыртты. Җиз самовар өстенә ак тастымал капланган булса да, Бибинур таныды, Тула самовары!” Җиз самоварлы, җылы сөтле, кунак-сыйлы дөньяны югалтканга ятим җан берөзлексез сыкрый: “Самоварны күргәч, аның хәле бетеп китте, чак кына сәкегә менә алды”. “Бибинур карчыкның сыеры да, җылы сөте дә күптән юк, җиз самоварсыз калганына да әллә ни гомер”. Шул рәвешле, татар тормышын бөтен иткән ак дөнья җан сафлыгының аерылгысыз юлдашы икән, бу чынбарлыктан җылы сөт кенә юкка чыкса да, яшәеш үзгә юл ала, никадәр генә саф-ихлас булма, әлеге самоварсыз-сөтсез чынбарлыкның башка кануннары кешене буйсындыра, әхлагын какшата икән. Автор татарның бәхетле булу юлын Вәли карт теле белән Җиһангирга бәйле кабатлый: “Җиһангирым борынгыны бик олылый иде. Өйдә җылан мөгезе генә юк. Стенада тәрәш тараклары, дага-кыңгыраулар, кутаз дисеңме, эшлея шөлдерләре, калтырчалар, киндер сосалары, балдаклы дуга тиклем бар! Ярма ташын әйткән дә юк. Аны да чыгарып ташлатмады...” Хәзер болай яшәү мөмкин түгел дигән укучы күңелендә туган уйга Җиһангир карашын автор алдарак җиткергән иде инде: “Беркем дә ата-бабалары кылганны механик рәвештә кабатлап кына яшәргә риза түгел, гәрчә ата-бабаларыбыздан кадерле мирас калган очракта да! Әгәр без һәр буынга лаеклы һәм җаваплы шундый эш йөкли алмыйбыз икән, яшьләребез авылда калмаячак!..”. Димәк, татар кешесенең бәхетле булу юлы борынгыны олылап, үз буының алдында лаеклы һәм җаваплы гамәл башкара алу.

Бибинурның төнгә каршы юлга чыгуы шул “ямау өстенә ямау эчке күлмәген” – түгелергә торган эчке хәсрәтен кешегә күрсәтергә теләмәүдән: “Ямаулы ыштан аркасында оятка каласы килмәде аның”.

Күлмәгенең ямаулы, тирән кесәсендә һәрчак ике кап шырпысы булган Бибинурның кайчагында берсен бүләк итеп тә калдыру гадәте бар. Хәсрәтеңне тирән яшереп, башкаларга игелек кылырга омтылыш эчке гүзәллекнең тышкы гәүдәләнеше, ди автор. Иң мөһиме – әлеге омтылыш кеше рухын яшь, сәламәт килеш саклый. Бибинурның озак итеп күлмәклек сайлавында шул эчтәлек укыла: “...яңа ситсы арасында уралганнан соң кулдан бик озакка кадәр тәмле ис китми, тәмле ис – яшьлек исе, ак киндер исе, җитен сөлгеләр исе өс-башка да сеңеп чыга, шулай итеп, кибеттә булганнан соң, иске киемең дә яңа кебек була

башлый...”  Димәк, кеше рухы һәрдаим тәрбиягә мохтаж,, җанны борынгыдан килгән “ак киндерле, җитен сөлгеле” чынбарлык иркәли, әлеге матурлык кешегә дәрт өсти, аны бәхетле итә. Шул чынбарлыкны җую кешене “таудан төшкән иске чиләк шылтыравы кебек” буш итә (Бибинур-Зөһрәбану сөйләшүе).

Кызыл комач яулык Бибинур белән Җиһангир дөньясын бер үзәккә җыеп тора. Яулыкны ирнең мәетенә япкан материалдан кисеп алу детале аша автор Бибинурның яңа рухи баскычка әзерләнүе турында хәбәр итә. Мифологиядә ике дөнья арасындагы чик мәгънәсендә укыла торган яулык образы бер яктан, гадәти укылышта әлеге якты рухның юкка чыга баруы кебек кабул ителсә, икенче яктан, киресенчә, Бибинур дөньясындагы ярату көче  тудырган яңа балкышны белдереп килүе ачыклана (Бибинурның Галикәйгә яулыгын күрсәтергә ашкынуы).

Ярату көче кешене көтмәгәндә таныш түгел, әмма сагынып теләгән,  тансык хисләр дөньясына  алып чыга: “Буа тавышын ул дөньядан Җиһангир киткәнгә генә генә ишетте! Оя таба алмыйча бүрәнә почмакларына туктаусыз бәргәләнгән  божанны Җиһангир өчен генә кызганды ул бүген! Күкне кыеп-кыеп, кисәкләргә бүлеп, җир кешеләренә бүләк итәргә ашкынган карлыгачларны ул бары тик Җиһангир булганга гына күрде”. Мәхәббәт кешедә буыннардан килгән омтылышны – карлыгач оясы кебек матур гаилә кору теләген ныгыта, оя кора алмаганнарның хәсрәтен көчәйтә, ди автор.

Сабантуй – “танышу, белешү, өйләнү, кияүгә чыгу бәйрәме” – нәсел-ыруны барлау көне, ел дәвамында җыела-туплана килгән хисләрне белдерү көне, хисап көне. Аның көне билгеле булмаган кебек, берләшү, кавышу көненең дә көне билгеле түгел. Гомернең һәр башка көне шул көнгә әзерлек көне кебек гомумиләштерелә. Сабантуй – кешенең бер-берсенә изге теләк теләү көне, күңелнең ачылган мәле. Димәк, А.Гыйләҗев кешенең дөнья өчен ачылган мәленә килүен – үзендә гармония табуга ирешү юлын тасвирый. Һәр көн – гармониягә омтылган кешенең бер хисенең аталышы кебек символлаштырыла.

Дүшәмбе – “зәңгәр тауларда Сабан туе табыннарында бәлеш, өчпочмак, пәрәмәч, тутырмалар булып утырасы симез-симез печкән бүлтерекләрне” көтү көе. “Сабан туе мунчаларын җылытасы сөяк-сөяк каен утыннары” кояшта кибеп яткан көн. Димәк, кеше әлегә үз юлын эзли, көтә. Ләкин “оннар иләнгән, чүпрәләр әзер... Аракы, шампан шешәләрен кар базларына төшереп тутырганнар”. Көтү озак еллар,

кайчак гомернең олы бер дәвере булырга да мөмкин. Бибинур бу көнне үткәндә калган гамьсез балачак истәлекләрен барлый. “Җиде кыз” әкиятенең уйнатылуы әсәргә хәсрәт сызыгын тагын да көчәйтә. Гыйльфан агай төпчекләре – игезәкләр мифологик мотивы хәсрәт сызыгын үзгә якка бора. “Тәмәке, аракы исе килеп торган” Габдуллаҗан абыйга балалар хакына йортка керергә карар кылуы – “гөнаһсыз уй, гөнаһсыз тән”ле Бибинурның җомга көнгә таба юл башы, чын кавышу көненә әзерләнә башлавы, мәхәббәтен көтү өчен “утын әзерләү” – тәүге олы игелек кылу мизгеле кебек укыла. Димәк, олы мәхәббәтенә кеше игелекләр аша әзерләнә, һәр олы игелек аны илаһи башлангычына – саф-ихлас хисләренә – мәхәббәтенә алып бара.

Зөһрәбану карашы – әсәрдә имгәк җәмгыятькә ярашкан, буйсынып, кешелеген җуйган күпчелек фикере кебек укыла. Куркып яшәү тәртибен үз иткәннәр Бибинур игелеген – мәхәббәткә юлын “җүләр картка, алдына куйганны түкмичә ашый да алмаган юбалгы җебегәнгә ябышып чыгу, хатынын яллап үтертү, үзеннән авыз иттерү” дип бәяли. Бибинурның тәүге эше – “күрше-тирә хатыннарны җыеп, өйне бик шәпләп юып чыгару, түшәмне аркылы пычак белән үзе кыруы, тәрәзәләр ачыкланып калуы” Җиһангирның Аксыргактагы тәүге гамәленең кабатланышы. Саф-ихлас мохит кешене үзгәртә, үз асылына кайтара, яратырга өйрәтә, укучы Габдуллаҗанның тормыш итүендәге үзгәрешне “өйгә ямь керү” нәтиҗәсе дип укый. Мәхәббәт килүен тәүге тапкыр тану (дүшәмбе көн) уйланырга мәҗбүр итә, томаланып яткан зиһенне кузгата: “Буа тавыш тавышы бер акрыная, бер көчәя. Бибинурга гына шулай тоеладыр ул, чөнки аның зиһене кинәт томаланып куя, аннан тагын ачыла”. Күңелгә саф хисләр иңгәнче кеше үзен ятим тоя, нидер эзли, көтә, тынычсызлана,курка, сагая, ди автор. Мәхәббәт килүен тану да зиһене башка дулкынга көйләнгән кешегә җиңел бирелми, бу халәт уңайсызлый, борчый, ләкин уйландыра.

Сишәмбе көн – мәхәббәтне танудан соң үзгәргән рух, дөнья: “Сишәмбе көн кичәгедән дә ягымлырак, ямьлерәк булып туды”. Сабан туена – Мәхәббәтле яңа чынбарлыкка, рухи халәткә аяк атлаганда, “табигать шулай чуклы-бизәкле була да инде. Капкалар җырлап кына ачыла, морҗалардан хуш ис кенә тарала, яшь кызларның сулышлары, адымнары үзгәрә. Аксыргак кызлары бер башка биегәеп китәләр”. Зөһрәбану белән сөйләшергә теләве – “яңа яулыгын бәйләгән”

Бибинурның табигый омтылышы. Үзен самоварсыз иткән балалары, Зөһрәбану белән Бибинур мөнәсәбәтләр җайларга ашыга.

Биредә саф-ихлас җанга кул сузган Ибрай, Хөснетдиновлар – җәмгыятьнең түбән җанлы вәкилләре буларак сурәтләнә. Ат образы – мифологик эчтәлектә - үз хисләреңне йөгәнләү мәгънәсендә уйнатыла: “Тормыш дилбегәсенең үз кулында түгеллеген әллә кайчаннан белә Бибинур, тик бу хәл белән аның һич килешәсе килми, төннәрен ул төшендә Хөснетдинов белән талашып уяна”. “Ат карагы” дип гаепләгәннән соң Габдуллаҗанның үлеме турында хәбәр ишетелү Бибинурның көчле рухын сынау, шулай да яңа – тагын да киңрәк юл башына чыгуы кебек аңлана. Иң мөһиме – мәхәббәтен таныган Бибинур тагын да кыюрак адымнар белән газизләрен – балаларын яклау юлына басуын искә төшерә: “Кызыл айгыр озак кына карда янына төшмәде, ул, Бибинурдан аерыла алмыйча, тып-тып юртып әллә ничә кат урамнан узды. Айгырның кешнәве кароа кан тулган йөрәккә ук булып кадалды... “Балакайларым, ятимнәрем минем!” Шуларны искә алган Бибинур алдагы икенче игелекле гамәлен башкару алдында: “Шаулый буа, арыктан су бәргәләнеп төшә, мең нурлы тамчы булып чәчри, күбекләнә, кайный, ярсый”.

Чәршәмбе “байтактан бирле үзеннән үзе качып ашагән” Бибинурны, “Галикәй кебек буа өстендә йөзгән казларны куркытып шаркылдап көлә алмаса да” “җиле дә таман гына, яшь каеннарның җирне чуарлаган юка күләгәләре йөгереп-йөгереп уйнаган” чынбарлыкка алып чыга. Галикәй – яңа чынбарлыкка ярашырга мәҗбүр ителгәннәрнең көлкеле сурәте. “Кызыл яулыклы, зәп-зәңгәр күзле” сафлык (Бибинур) янәшәсендә балаларының модадан чыккан яңа киемнәрен киеп йөрүче сунарчы Галикәй “мыеклары хәтәр тырпайган, каракошлы түшле” бабай клоунга әверелдерелгән буын хәсрәтен сөйли. Бибинур аның кысыр хәсрәтен аңлый, аны Зөһрәбануга тиң күрә. Автор карашынча, ярашып яшәргә күнеккән битараф-гамьсез чынбарлык асылда көлкеле һәм кызганыч, чөнки Зөһрәбану, Галикәйләр инде кармакка балык эләкмәсен белсәләр дә, көтеп яшиләр. Саф җанарда гына урнаша ала торган хис – Мәхәббәт көткәннәргә – игелек кылып үзгәргәннәргә килә, явызлык, гамьсезлек мәхәббәтне читләштерә, юкка чыгара, ди автор. Бибинур Явызлыкны игелек кылып җиңә. Зөһрәбануга ул Сабан туе бүләге – үзенә тиң яр алып килә. Галикәй Зөһрәбану белән бергәләп үзгәрәчәк (ирнең яулык бүләк итүе – икәүләп яңа чынбарлыкка чыгачакларын хәбәр итә).

Кавышу – аларның олы мәхәббәткә юл башы гына , Шул ук вакытта, бу – “елларның, айларның гына түгел, атналарның, көннәрнең тууын, яралуын белеп, тоеп яшәгән”, “кеше булуына, күпне күрә алуына, күргәнен аңлый, ярата алуына куанып яшәгән” Бибинурның икенче олы игелеге.

Атна кич – мәрхүмнәр рухына дога укый торган көнне кар ерып Гайшә каберенә баруын искә төшерүе мәхәббәтен күтеп яшәүче игелекле җанда туган табигый омтылыш – “бала, онык сөю теләге” белдерелеше. Автор Бибинурның “түбә саламын алып ташлауга” – “кеше күңеленең иң югары ноктасы – кешене ярату”га килүен сурәтли. “Ярата белгән йөрәкле” Бибинурга тиң яры “тән таушалган, күз нуры зәңгәрләнеп юыла башлаган, күз төпләренә күзнең күгелҗем тоҗымнары таралган, йөрәк яшь калган килеш” – өмет/өметсезлек чигендә очрый. Мәхәббәт – күңел сере кеше гомерен тулы түгәрәк итүче бердәнбер хакыйкать, ди автор. Бибинурның каз асрарга – гаиләле булырга, кер юарга – килен булырга теләге бары тик Җиһангир белән бәйләнә. Җиһангирны ул үзен белгәннән башлап көтә. “Табигатьнең барлык үзгәрешләренә дә сизгер” Бибинур численникларда – күңел төпкелендә үзендә булган һәр үзгәрешне язып теркәп бара. Мифологиядә Илаһияткә сөенечле дога җиткерүче кебек тамгаланган “тургайлар килгән көн – Бибинур дулкынланган чамасыз Олы көн”– мәхәббәт киләчәгенә өмет салынган Олы мизгел. Тик өмет туганнан соң мәхәббәт үзе бик озак – кайчак гомер буе көттерә: “Тургайлар кайтты, ә Габдуллаҗан кайтмады... Тургайлар һәммәсе кыр-болыннар өстенә таралды, ә аның балаларының берсе дә юк...” Бу вакыйгалар – Бибинур гомере, Җиһангирга кадәр булган чынбарлыгы. Өметләр тора-бара ярларыннан ташый, хисләр акылга хуҗа була башлый: “Бүген су ташый башлады, таң алдыннан гөрләп боз кузгалды”. Җәйгә кергәч, хисләр “танымаслык булып үзгәрә”:“Сабан туйлары җитә башласа, йокысы, ялы онытыла иде”. Мәхәббәт көтү белән бәйле өметләр “сап-сары итеп өйне юдырта, мич-морҗаны шомырт чәчәге төсен кереп агарттыра, җиз самоварны ачы катык, ком белән агартып, кояш көнләшерлек итеп ялтыраттыра, өстәлдә төрле-төрле тәкәләр, коймаклар, бавырсаклар, чәкчәкләр бизәлә”. Бибинурның иң яратканы – ат чабышы – хисләрне йөгәнләү омтылышы. Автор тирән һәм нечкә хисле татар кешесе яратуын сүзләр белән әйтеп бирүгә үтә дә сак карый, эчке ярсу хисләр гамәлләр булып чынга аша, шул сәбәпле татар кешесе армый-талмый хезмәт сала,

берөзлексез юа-чистарта, табын тутырып ризык хәзерли, асылда өзелепләр яратканын шулай белдерә, йөгәнли ди. Мәхәббәтне сагынып теләү "сине җиргә мәңгегә килгән кебек" бәхетле итә. Шул хисләр югалуга кеше үзен картаюга дучар итә, ди автор. Гайшә каберенә бару – үзен өметсезлек чигенә китереп җиткергән Бибинурның үз күңеленә чарасызлыктан юл сорап эндәшүе ул. Бибинур күңеле, мөгаен, иң олы игелеккә – үзе өзелеп яраткан балаларының, авылдашларының яратмавын кичерергә, гафу итәргә әзерләнә. Шул рәвешле, саф хисләр бервакытта да җавап хис таләп итми, җавап хис сорап өзгәләнү (балаларның кайтуларын, Зөһрәбану эндәшүен көтү) – хисләрнең сөйгән кешеләр өчен җаваплылык тою дәрәҗәсенә кадәр үсмәгәнлеген белдерә. Автор мәхәббәт кешенең үз халәте, ул аны гына бәхетле итә ала торган олы җаваплылык, һәр мизгелдә шуны тоеп, шул җаваплылык белән гамәлләр кылып яшәү ул, ди. Җомга көн алдыннан Бибинур беркайчан да беркемгә дә әйтергә ярамаган беренче саф һәм бердәнбер мәхәббәтен – Җиһангир Сәфәргалинны искә төшерә. Гомер буе көтеп тә белдерә алмаган хис укучыны елата, үкенечле булганга елата. Ләкин әдипнең осталыгы да шунда. А.Гыйләҗев Бибинурның сөюен мәңге җуелмас бәхет дип белдерә. Сөюне әйтә-белдерә алмау алмау һич кенә дә үкенеч түгеллекне, ничек кенә булмасын, "мәхәббәтле йөрәк юмарт, мәхәббәтле йөрәк гадел, мәхәббәтле йөрәк бәхетле" икәнлекне раслый: "Әйе, ул кеше. Яши ала, күрә ала, татый, иртәнге чык белән кичке шәфәкъ утлары аның җанына тәэсирсез узмый. Хәзер ул яшәреп китте, адымы үзгәрде. Ни булды бу Бибинурга? – диләр яшел сукмаклар. Ни булды бу Бибинурга? – дип, ак болытлар Аксыргак түбәсеннән китә алмыйча әйләнәләр... Ни булды безнең хуҗабызга? – диләр шау чәчәктә утырган яран гөлләре. Күңел сере бар кешенең генә гомере тулы, түгәрәк икән. Күңел сере бар чагында гына яшәү кызык. Күңел сере бар чагында гына яшәү җиңел. Күңел сере бар чагында гына яшәү ифрат авыр..." Күңел серен белдерергә теләп Бибинур Җиһангирдан каз асрарга җай сорый (гаиләле-уллы булу теләгенең белдерелеше), күлмәкләрен юа (килен булу теләгенең әйтелеше). Билгеле, Бибинур казлар да асрамый, аның юган киемнәрен ир кияргә өлгерми кала. Бибинур үзе дә – тулы тормышлы якшәмбегә – Сабантуйга җитә алмый.

Җомга – Бибинурның балаларыннан "гәҗит аша яулап алган мәхәббәт"нең ялгыш юл икәнлеген раслап юлга чыгуы һәм вафат булуы. Җомга – Җиһангирын-бердәнберен өзелепләр яратучы

Бибинурның өченче соңгы олы игелеген кылу омтылышы. Чынбарлыкка – “мәкерле, тавышсыз гына коела торган төнге яңгыр, бимазалап озата килгән черкиләр”гә каршы Бибинур ут кора. Төш – Бибинур хакыйкатенең мәңгелекккә күчерелүе ул. “Елгадан тарлавыкка күчкән” хакыйкать ул – Габдуллаҗан, Гайшә, балалар, Галикәйләргә карата кылган олы игелекләр. Олы җаваплылык тоеп, аларны кичерә алу игелеге.

Димәк, кешене мәңгелеккә илтүче уйландыра, “җылата” торган торган хакыйкать мәхәббәт – сабырлык белән кичереп яшәү – яратып яшәү ул. Татар кешесенең саф-ихлас дөньясы аны буйсындырып, юкка чыгарырга теләгән чынбарлыкка каршы көрәшә. Бу чынбарлыкта кешене горур-буйсынмас итүче мәхәббәт хисе генә тормышны тулы, түгәрәк итә, ди автор.

XX гасырның 70-80 нче еллары прозасы – татар прозасының яңа юлы билгеләнгән дәвер. Милли яшәеш фәлсәфәсенең Ә.Еники, А.Гыйләҗевләр тәкъдим иткән укылышы ике гасыр чиге прозасында Ф.Садриев прозасында кабатлана, көчәйтелә. Бүгенге прозада бу әсәрләр югарылыгында кабул ителгән, аңланган, хәтердә уелган текстлар булу турында әйтү иртәрәк булыр. Әлеге юнәлеш татарда милли үзаң үсешенең яңа дәверен көтә. Әдәби тәнкыйтьтә, әдәбият теориясендә кискен алгарыш, шулай ук хәзерге прозадагы интеллектуаль тенденция бу юнәлешнең дәвамы булачагына ышаныч тудыра.

Әдәбият

1. А.Гыйләҗев: Истәлекләр / Төз. И.Гыйләҗев.– Казан: Татар.кит.нәшр., 2006.– 271 б.

2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге.– Казан: Мәгариф, 2007.– 231 б.

3. Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2004.– Б.210-356.

4. Еники Ә. Әсәрләр. 5 томда. 3 том. Повестьлар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2002.

6. Жюльен Н. Словарь символов. – Челябинск: Урал LTD, 1999.– 498 с.

7. Заһидуллина Д. Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма /

Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов.– Казан: Мәгариф, 2007.– 112 б.

8. Ибрагимов М.И. Миф в татаркой литературе XX века: проблемы поэтики. – Казань: Gumanitarya, 2003.– 64 с.

8. Хабутдинова М.М. Художественная летопись татарской деревни в повести А.Гилязова “В пятницу, вечером”. Гилязов А.М. Повести: Три аршина земли; В пятницу, вечером. – Казань: Магариф, 2008. – С.258-278

9. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А – Г).– Казан: Мәгариф, 2008.– 303 б.

10. Урманче Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. – Казан: РИЦ “Школа”, 2002.– 260 б.

11.Яхин А.Г. Әдәбият: Татар гомуми белем мәкт. 11нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2003. – 383 б.

# ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

## ТЕКСТЛАР

Гыйләҗев А. Өч аршин җир / Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр.– Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2004.– Б.136-209.

Гыйләҗев А. Җомга көн, кич белән... / Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр . – Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2004.– Б.210-356.

Еники Ә. Бала / Ә.Еники. Әсәрләр, өч томда. III том: Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – Б.7-13

Еники Ә. Бер генә сәгатькә / Ә.Еники. Әсәрләр, өч томда. III том: Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – Б.25-44.

Еники Ә. Рәшә / Еники Ә. Әсәрләр. 5 томда. 2 том: Повестьлар. – Казан: Татр.кит.нәшр., 2001. – Б.269-446

Еники Ә. Әйтелмәгән васыять /Еники Ә. Әсәрләр. 5 томда. 3 том. Повестьлар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2002. – Б.7-44

Еники Ә. Гөләндәм туташ хатирәсе / Еники Ә. Әсәрләр. 5 томда. 3 том. Повестьлар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2002. – Б.237-399.

Мәһдиев М. Торналар төшкән җирдә / Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 3 томда. I том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – Б.135-356.

## ӘДӘБИЯТ

Аяз Гыйләҗев: Истәлекләр / Төз. И.Гыйләҗев.– Казан: Татар.кит.нәшр., 2006.– 271 б.

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге.– Казан: Мәгариф, 2007.– 231 б.

Әмирхан Еники һәм XX йөз татар әдәбияты. – Казан: РИЦ “Школа”, 2009. – 424 б.

*Бахтин М.* Формы времени и хронотопа в романе // Бахтин М.М. Вопросы литературы и эстетики . – М., 1975.

*Богданова О.* Современный литературный процесс (К вопросу о постмодернизме в руской литературе 70-90-х годов XX века). – СПб, 2001. –252 с.

*Бохонная Е.* Функции цветообозначения единиц с семантикой “одежда” в лирической песне (на метериале сибирского фольклора) .– library.krasu.ru

*Вәлиев М.* Күңелнең көткәне. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 180 б.

*Габдулхакова Г.* Гилязов (Гыйләҗев) Аяз Мирсаидович /Татарская энциклопедия: В 5 т. / Гл. ред. М. Х. Хасанов. – Т. 2.– Казань:Ин-т Тат. энцикл. АН РТ, 2005. – С. 111.

*Гилязов А.* «Я никогда свободно не дышал» // Татарский век глазами национальной элиты. 100 выдающихся татар. – С. 171-172.

*Гилязов М.* Уроки отца // Идель. – 2003.– № 1.– С.22-24.

*Гыйләҗева Н.* Өтергә тимәгез... // Мәдәни җомга. – 2001, 16 гыйнвар.

*Давлетшина Л.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI вв.. – Казань: РИЦ “Школа”, 2006.– 140 с.

*Егоров А.* Три интервью об Аязе Гилязове // Казанский альманах: литературно-художественное и культурно-просветительское издание. – Казань: Татар.кн.изд.-во, 2009. – С.131-148.

*Жюльен Н.* Словарь символов / Н.Жюльен.– Челябинск: Урал LTD, 1999. – 498 с.

*Заһидуллина Д.* Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы (1930-1995). – Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшрияты. – 2003.

*Заһидуллина Д.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004 .– 367 б.

*Заһидуллина Д.* Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева.– Казан: Мәгариф, 2005.– 111 б.

*Заһидуллина Д.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография .– Казан: Мәгариф, 2006.– 191 б.

*Заһидуллина Д.* Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма /

Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов.– Казан: Мәгариф, 2007.– 112 б.

*Заһидуллина Д.* XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү мәсьәләсе / Әмирхан Еники һәм XX йөз татар әдәбияты. – Казан: РИЦ “Школа”, 2009. – Б.13-18.

*Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

*Ибрагимов М.* Миф в татарской литературе XX в.: Проблемы полтики /М.Ибрагимов – Казань: Gumanitaria, 2003.

*Ибрагимов М.* Мифопоэтика повести А. Гилязова «Три аршина зсмли»// Проблемы филологии народов Поволжья.– Москва-Ярославль: Ремдер, 2007. – С.106-109.

*Искәндәров Х.* Саз чәчәге // Совет Татарстаны.– 1956. – 20 гыйнвар.

*Камалетдинова Р.* Милли рухыбыз җырчысы // Сөембикә. – 1999 – №2. 26-28 б.

*Лукашевич В.* Серьезнее, вдумчивее / В.Лукашевич // Лит. газ. – 1957.– 25 мая.

*Миңнегулов Х.* Гыйбрәтле язмыш сәхифәсе (Аяз Гыйлаҗев һәм аның «Өч аршын җир» әсәре турында) // Актуальные проблсмы естественных и гуманитарных наук. – Казан: КГУ, 2006. – С. 206-210.

*Миңнуллин Ф.* Намус эше / Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (Т.Галиуллин кереш сүзе)/.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – 344 б.

*Мотыйгуллина Ә.* Затлы язучы // Ватаным Татарстан. – 1999. – 18 июнь.

*Мусин Ф.* Тарих һәм заман (Соңгы еллар татар прозасы турында). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 197 б.

*Мустафин Р.* Карьера Зуфара Сабитова // Дружба народов.– 1963.– № 10. – С. 178-180.

*Мухаметшин А.* Мы слышим тебя, Амирхан ага! // Казанский альманах: литературно-художественное и культурно-просветительское издание. – Казань: Татар.кн.изд.-во, 2009. – С.91-93.

*Нигматуллина Ю.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур.– Казань: Фэн, 1997.– 192 с.

*Полухина Л.* Честь смолоду // Лит. Россия. – 1986. – № 39. – 26 сентября.

Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. - 544 б.

*Топоров В.* Миф. Ритуал. Символ. Образ: Исследования в области мифопоэтического: Избранное / В.Н.Топоров. – М., 1996.

*Урманче Ф.* Борынгы миф һәм бүгенге шигырь / Ф.Урманче. – Казан: РИЦ “Школа”, 2002.– 260 б.

*Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А – Г) / Фатих Урманче.– Казан: Мәгариф, 2008.– 303 б.

*Фаизова Р.* Принципиальность и издержки критического азарта / Р.Фаизова // Лит. газета.– 1964.– 9 апреля.

*Фасеев К.* Кояшлы язны рәшә капламасын // Социалистик Татарстан.– 1963.– 28 июль.

*Фасеев К.* Полемизировать без “приписок”! // “Литературная газета”.– 1964.– 2 апреля.

*Хабутдинова М.* Драгоценный камень А.Гилязова / Гилязов А.М. Повести: Три аршина земли; В пятницу, вечером. – Казань: Магариф, 2008. – С.233-258.

*Хабутдинова М.* Художественная летопись татарской деревни в повести А.Гилязова «В пятницу, вечером» /Гилязов А.М. Повести: Три аршина земли; В пятницу, вечером. – Казань: Магариф, 2008 .- 287- 295 с.

*Хакимов А.* Вина и ответственность // Лит. газета. – 1967.– 22 декабря.

*Хатипов Ф., Сверигин Р.* Рәшәле дөнья // Мирас. – 1999. – № 3.– Б. 45-60 ; № 4 – Б.42-53.

*Юныс М.* Акъэбинең кабере янында /М.Юныс // Казан утлары. – 1998.– №9.–163-172 б.

*Яхин А.* Әдәбият: Татар гомуми белем мәкт. 11нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2003. – 383 б.